www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 26 (1442) 7 июль 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

12

Драма артисты Тәслимә Хәләф, Дим буенда үссә дә, озак еллар буе Тинчурин театры сәхнәсен бизәде.

14

Сөн буена тезелеп киткән авыллар арасында шанлы Иске Байсар да бар.

19

Мөслим районының Усы авылында туып-үскән Никон Егоров – беренче космонавтларга гыйлем биргән остаз.

Ил-көнгә иминлек теләп, Печәнгә төшкән халык!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Кемерово өлкәсендә XXIII Федераль Сабантуй һәм III Шахтерлар Сабан туе булып узды.
- Малмыж каласында Киров өлкәсенең өлкә Сабан туе булып узды, һәр бәйрәмдә дә Татарстан Республикасы Рәисе Р. Миңнеханов катнашты.
- Россиядә игълан ителгән Парламентаризм көнендә Татарстан Республикасының Дәүләт Советы рәисе Ф.Мөхәммәтшин котлау белән чыкты.
- Татарстан хокук саклау органнары ел башыннан әйләнештән 230 килограммнан артык наркотик матдәләр алган.
- Идел елгасында 2 километр да 200 метр арага йөзү буенча ярышларда Чуаштан Республикасы прокуроры Андрей Фомин батып үлгән.
- Әгерҗе районында юл һәлакәтендә Кырынды авыл җирлеге башлыгы Альберт Нәфыйков һәлак булган.
- Пенза өлкәсендә Россиядә иң зур татар авылларының берсе булган Урта Әләзән авылында 7 балада кызамык авыруы ачыклану сәбәпле, өлкә хөкүмәте карары белән әлеге авылда карантин игълан ителгән.
- Түбән Камада яшәүче 65 яшьлек ир, эчеп алгач, малае белән ачуланышкан һәм мылтыктан аның аркасына аткан, шуннан соң үзүзенә кул салган.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Римзил ВӘЛИЕВ, журналист:

«Татарлар ел саен 1,5 процентка кимесә (10 елда 600 мең кимүне 10 елга бүләбез), ел саен якынча 60000 кеше «югала» дигән сүз. Ай саен 5000, көн саен 480 кеше. Бу саннар иң оптимистик варианттан алына. Татарча белүчеләр 20 ел эчендә 2 миллионга азайса, димәк, ел саен 100 000 татар телсез кала. Бер айда 8220 кеше дигән сүз».

СЫНАМЫШЛАР

8 июльдә эссе булса, чиллә 40 көнгә сузыла ● 10 июльдә яңгыр яуса, әбиләр чуагына кадәр туктамый ● 12 июльдә (Питрауда) яңгыр яуса, печән череп бетә ● Питрау көнне үләннең шифасы тамырга төшә, кошлар сайраудан туктый ● Питраудан соң өч-дүрт көн үткәч сандугач сайраса, тагын биш атнадан көз башланыр ● Питраудан соң бер атна үткәч күке кычкырса, көз озак булыр ● Питраудан соң сандугачның теле бетә, үләннең тәме бетә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 09 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 29 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 20 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **16 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **14 июльдә 17 сәгать 04 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

7 июль – Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Айдар Нил улы Юзиевка 65 яшь (1958).

8 июль – эстрада җырчысы, Татарстанның атказанган артисты Раяз Наил улы Фасиховка 40 яшь (1983).

10 июль – язучы, җәмәгать эшлеклесе, техник фәннәр докторы Зәки Лотфулла улы Зәйнуллинның тууына 90 ел (1933–2021);

– филология фәннәре докторы, профессор Рифгать Газизҗан улы Әхмәтьяновның тууына 90 ел (1933–2018).

12 июль – композитор, профессор, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Татарстан дәүләт бүләге лауреаты Мирсәет Заһидулла улы Яруллинның тууына 85 ел (1938-2009).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июльнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 8, 12, 13 июль.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(3-10 июль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 19 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Әлмәт районындагы 100 еллык тарихлы Яңа Кәшер мәктәбе элеккерәк елларда бик данлыклы иде. Бу мәктәптән сугыштан соңгы елларда бүген Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Клара апабыз Булатова укып чыккан.

ТАТАР МӘКТӘБЕНӘ ХУРЛЫК ҺӘЙКӘЛЕ

Шушы ук уку йортын тәмамлаган һәм озак еллар дәвамында хезмәттә дан алган сәнәгать, авыл хуҗалыгы, нефть тармагында танылган, орден иясләренә әверелгән якташларыбыз да шактый. Элек Яңа Кәшер мәктәбе республика өчен дә бик кадерле, шуның өчендер 1973 елда авыл үзәгендә бөтен район өчен үрнәк булырдай яңа бина да төзеп куйганнар иде.

Ләкин ел артыннан еллар үтә торгач, барча "вак" халыкларның милли йөзе шикелле үк, Яңа Кәшердәге татар мәктәбенә дә дәүләт тарафыннан игътибар бөтенләй юкка чыкты. Милли мәктәп бинасы менә 17 ел буена җимерелгән һәм хурлыкка чумган көенә "ятим" тора. Аның спорт залы, ашханәсе һәм актлар залы җимерек хәлдә, аларга нәни укучы балаларны түгел, хәтта ата-аналарны чакырып кертү дә куркыныч. Балаларны спортка тартуны туктатырга мөмкин булмагач, кечкенә бер мастерской бинасында спортзал әмәлләргә мәҗбүр булдык. Мәктәпнең икенче бинасында ашханә оештырдык. Күк йөзеннән яңгыр яки кар явып торган, тирә-юньдә буран котырган чакларда да балакайларыбыз туклану өчен шул күрше бинага йөреп җәфа чикте. Бәйрәмнәрне, мәктәп линейкасы кебек тантаналы чараларны коридорның сыңар дивары буенда уздырырга мәҗбүрбез. Ләкин андый чаралар барышында да балаларга салкын тию мөмкин, чөнки 1973 елда куелган тәрәзәләрнең агач рамнары күптән череп беткән. Электр, су һәм җылылык бирү системалары тулысынча искерде. Кышкы салкыннарда балалар өсләренә бишмәт, кулларына бияләй киеп утырырга мәҗбүр. Мәктәп диварларында ярыклар.

Бүген мәктәптә 132 бала белем ала, аларга 16 мөгаллим белем бирә. Сүз дә юк, мөгаллимнәр тәрбиядә педагогиканың иң яңа, иң заманча алымнарын кулланып эш итәргә омтыла, шуның аркасында Яңа Кәшер мәктәбе һаман районда иң алдынгы уку йортларының берсе булып санала. Ләкин җимерек бинала мәктәпкә йөрү беркемгә дә дан түгел, шуңа күрә кайбер ата-ана үз балаларын йә Әлмәт шәһәрендәге, йә күршедәге төзек мәктәпкә илтеп бирүне өстенрәк күрә. Шуңа карамастан, үткән уку елында беренче сыйныфта 20 сабый белем алган булса, быел да 15 бала безгә килергә атлыгып тора.

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм әфәнде Миңнеханов агымдагы 2023 елны – Милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне саклау елы, дип игълан итте. Яңа Кәшер урта мәктәбенең укытучылар коллективы татар милләтен алга илтү – иң беренче чиратта, туганнарыбызның гыйлем дәрәҗәсен күтәрү икәнлеген яттан белә. Туган телне, милли мәдәниятне, милли йөзебезне саклап калу да беренче сыйныфтан ук, мәктәпләрдән башлана.

17 ел буе районның күптөрле оешмалары һәм дистәләгән җитәкчеләр алдында йөз суыбызны түгеп йөри-йөри, бездә өметсезлек уянды. Мәктәбебезгә капиталь ремонт үткәрү, аңа янкорма итеп спортзал, ашханә һәм актлар залы төзеп кую өчен Сезнең ярдәм кирәк, Рөстәм Нургали улы?!

Ярдәм өмет итеп, Яңа Кәшер урта мәктәбенең ата-аналар комитеты, мөгаллимнәр.

СЕРЛЕ СӨЙЛӘШҮЛӘР

Күптән түгел (24 июньдә) Копенгагенда (Дания), бик тә яшерен шартларда, Украина тирәсендәге хәлләр буенча бер җитди халыкара очрашу үткәрелүе мәгълүм булды. Украина тәкъдиме белән АКШ ярдәмендә оештырылган ул чарада, Көнбатыш дипломатларыннан тыш, «глобаль Көньяк» дип йөртелгән илләрдән дә (Бразилия, ЮАР, Кытай һәм Һиндстан) вәкилләр катнашкан. Ә алар – Украина тирәсендәге хәлләргә карата бүгенгәчә нейтралитет саклап килгән БРИКС илләре. Шул ук вакытта әлеге очрашуга Россия чакырылмаган. ARD телеканалы хәбәренә караганда, аны оештыручыларның максаты – бу илләрне Украинадагы вәзгыятьне җайга салуда үз якларына авыштыру, имеш. Кайбер мәгълүматлар буенча, анда ЕС вәкилләре, шулай ук Алмания, Бөекбритания, Дания, Италия, Канада, Согуд Гарәбстаны, Төркия, Франция, Япония һ.б. илләрдән дә вәкилләр дәүләт башлыгының милли иминлек, яисә сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе дәрәҗәсендә катнашкан, ә АКШ Президентының дәүләт иминлеге буенча ярдәмчесе Джейк Салливан видеоэлемтә режимында чыгыш ясаган. Украина делегациясен исә президент офисы башлыгы А.Ермак җитәкләгән. Бу очрашуда катнашучыларга ул янә бер кат Зеленскийның 10 пункттан торган «тынычлык формуласы»н тәкъдим иткән. Ә Киевтә фәкать әлеге «тынычлык формуласы» гына Украинада тотрыклы вә гадел тынычлык урнаштыру өчен нигез була ала, дип санайлар.

Искә төшереп үтик, Украина Президенты В.Зеленский үзенең «тынычлык формуласы» дөньякүләм дәрәҗәдә дә яклау тапсын өчен (ә ул атом-төш вә радиация иминлеге, азык-төлек иминлеге, энергетика иминлеге, барлык тоткыннарны да азат итү, Россия гаскәрләрен чыгару, Украинаның территориаль бөтенлеген торгызу, гаделлекне кайтару, экоцидка каршы тору, эскалациягә юл куймау, низаг туктатылуын теркәү кебек пунктларны да үз эченә ала), глобаль дәрәҗәдә тынычлык саммиты үткәрү тәкъдиме белән дә чыккан иде. Дөрес, соңгы айларда андый «тынычлык планнары» инде, аерым-аерым да, төркем белән дә тәкъдим ителә (эчтәлегеннән, алар артында кем торганлыгын да чамалап була). Ә Копенгагенда узган серле очрашудан соң инде ARD телеканалы Украина буенча халыкара сөйләшүләр июльдә узарга мөмкин, дип тә белдергән. Шул ук вакытта ул очрашу төрле илләрдә һәм даирәләрдә төрлечә бәяләнде. Ак йортта, әйтик, аны нәтиҗәле сөйләшү буларак бәяләгәннәр. Максаты – глобаль Көньяк илләренә В.Зеленскийның «тынычлык формуласы»н аңлату һәм, андагы тәкъдимнәр буенча, глобаль саммит җыю. Киев планын алга этәрүдә тәүге адымнар ясалуы турында А.Ермак та әйткән. Bloomberg исә, Киевнең «тынычлык планы» буенча «тынычлык саммиты» җыю идеясе глобаль Көньяк илләрендә әлегә яклау тапмады, дип тә язып чыккан. Ә 27 июньдә кайбер басмалар (mk.ru, dzen.ru һ.б.) Reuters мәгълүматларына таянып язуынча, сугыш хәрәкәтләрен туктату буенча «тынычлык планы»н гамәлгә куюда Украина прогресска ирешкән. Әмма Киев һәм Көнбатыш Россияне «тынычлык саммиты»на да чакырырга теләми икән. Шуңа РФ тышкы эшләр министрлыгы башка илләрне дә анда катнашмаска өндәгән.

Хәлбуки, Копенгагендагы серле сөйләшүләр һәм глобаль сәясәттәге реаль вәзгыять соңгы көннәрдә Мәскәүне дә әлеге хәлләр хакында әйтеп сөйләшергә мәҗбүр итә кебек. Һәрхәлдә, РФ тышкы эшләр министры С.Лавров 28 июньдә Беренче каналда «Большая игра» программасына биргән интервьюсында, бөтен бәлаләрдә дә Көнбатышны гаепләде. Мәгәр В.Зеленскийның «тынычлык формуласы»н да ул Россия өчен капитуляция шарты буларак бәяләде, ә аның үзен, әлеге планын алга сөреп, Көнбатыш ярдәмендә РФ территориясеннән (бирелдә Донбасс, Кырым, шулай ук Запорожье һәм Херсон өлкәләре күздә тотыла) аның үз гаскәрләрен чыгаруына, шулай ук Россиянең репарация түләвенә һәм, үз гаебен тулысынча таныл, халыкара трибунал каршына басуына ирешмәкче дип, үзенчә «фаш та итте». Лавров әйтүенчә, Россия мондый шартларда беркем белән дә сөйләшеп тормаячак. Шул ук вакытта, ул Россиянең җитди сөйләшүләргә һәрчак әзер булуы турында да белдерә (әлбәттә, «җитди» дигәндә, ул югарыда телгә алынган территорияләрнең Россиягә калдырылуын да күздә тота). Шуны ук С.Лавров икенче көнне «РИА Новости» агентлыгына биргән интервьюсында һәм 30 июньдә «Радио и ТВ Португалии» медиатөркемена биргән интервьюсында да кабатлады. Узган җомгада аның тышкы сәясәт буенча онлайн режимда үткәргән брифингы да, асылда, күп мәртәбә әйтелгәннәрне кабатлауга һәм акланырга омтылуга кайтып калды. Чыннан да, кылган эш-гамәлләрең, илаһият кануннарына гына түгел, хәтта камиллектән ерак торган бүгенге халыкара хокук нормаларына да туры килми икән, акланулар инде «кара»ны «ак» итеп күрсәтүгә һәм һаман бер үк «балык башын» чәйнәүгә кайтып кала. Узган җомгада үткәрелгән әлеге онлайн-брифинг та – шуның ачык мисалы.

Фоат УРАЗАЙ.

Яңа ел каникуллары 10 көн дәвам итәчәк

Россиялеләр алдагы Яңа ел бәйрәмнәрендә 10 көн ял итәчәк. Россия өч яклы комиссиясе бу тәкъдимне хуплады, дип хәбәр итә ТР вице-премьеры Татьяна Голикова аппараты. Бу хакта «Российская газета» яза.

Өч яклы комиссия утырышында 2024 елда ял көннәрен күчерү турындагы Хөкүмәт карарын тикшерделәр һәм хупладылар. Аннан күренгәнчә, эшләми торган бәйрәм көннәре – 6 һәм 7 гыйнварга туры килгән ялларр 31 декабрьгә һәм 10 майга күчереләчәк.

Моннан тыш, шимбә, 27 апрельдәге ял көнен – дүшәмбе, 29 апрельгә, ә шимбә, 2 ноябрьдәге ял көнен сишәмбе, 30 апрельгә күчерергә тәкъдим ителгән. Шимбә, 28 декабрьдәге ял көне дүшәмбе, 30 декабрьгә күчереләчәк.

Шул рәвешле, Яңа ел каникуллары быелның 30 декабреннән 2024 елның 8 гыйнварына кадәр дәвам итәчәк. Россиялеләр 1 Май уңаеннан – 28 апрельдән 1 майга кадәр, Җиңү көне уңаеннан 9-12 майда ял итәчәк.

Ватанны саклаучылар көнендә – 23-25 февральдә, Халыкара хатын-кызлар көнендә 8-10 мартта ял итәчәкбез. Россия көне – 12 июнь дә ял көне булачак. Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан яллар ике көн (3 һәм 4 ноябрь) дәвам итә.

1 нче биттә – Авылларда печән әзерләү эшләре бара. Фото «Татмедиа» фотоархивыннан алынды.

Кемерово өлкәсендә Федераль Сабантуй

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов эш сәфәре белән Кемерово өлкәсенә барып кайтты. Төбәктә 22 мең татар исәпләнә.

Р.Миңнеханов биредә 1 июль көнне XXIII Федераль Сабантуйда катнашты. Моннан тыш, Миңнеханов Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилев белән бергә соңгы елларда ачылган яңа объектлар һәм төзекләндерелгән иҗтимагый киңлекләр белән танышты.

Кузбасста XXIII Федераль Сабан туенның төп татар утары Татарстанның Лениногорск районы хезмәтчәннәре һәм иҗат коллективлары тарафыннан оештырылган иде. Биредә шулай ук декоратив-гамәли сәнгать мәйданчыклары һәм татар осталарының кул эшләнмәләреннән торган күргәзмә тәкъдим ителде.

Казанда иртәнге сәгать 5 булганда, Кемеровода халык Сабантуйга агыла башлаган иде инде. Кемеровоның Мәскәү мәйданында XXIII Федераль Сабантуй һәм III Шахтерлар Сабан туе узды.

Сабантуй флагын Кемерово өлкәсе имамы һәм милли-мәдәни мохтарият җитәкчесе Таһир Бикчәнтәев һәм зур стажлы данлыклы шахтер Дмитрий Садретдинов күтәрде.

Сабантуйны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилев ачты.

«Без Федераль Сабантуйны үткәрергә күптән хыялланабыз. Теләгемне әйтеп, Рөстәм Миңнехановка шалтыраттым. Ә ул 2023 елга кадәр барысы да билгеләнгән, ди. Шуннан без халыкара Шахтерлар Сабан туе уйлап таптык. Быел, ниһаять, без Федераль Сабантуй уздырабыз», – диде Сергей Цивилев.

«Безгә борынгы бабаларыбыз бердәм, дус яшәргә васыять итеп калдырган. Без бер гаилә булып яшибез. Без бөтен кеше белән дус яшәргә телибез», – дип дәвам итте ул.

Рөстәм Миңнеханов Сабантуйны кабул итүчеләргә һәм килүчеләргә рәхмәтләрен җиткерде. «Биредә күп халыклар дус-тату яши. Сез барыгыз да ачык кешеләр», – диде ул.

Кемерово өлкәсе губернаторы һәм Татарстан Республикасы Рәисе дәрәҗәле бүләкләр тапшырды. Татарстан Рәисе Кемерово татарлары милли-мәдәни оешмасына «Газель» микроавтобусы бүләк итте.

Кемерово Сабан туе Лениногорск осталары катнашында әзерләнә. Халык уеннарын алар оештырды, Сабантуйда урнаштырылган утарларны да бәйрәм өчен алар әзерләде. Сабантуй кунакларын мич коймагы белән сыйладылар.

Сабантуй уздырырга Татарстаннан 340 лап кешелек зур делегация килде.

Сабантуй кунакларына бушлай пылау, шурпа һәм шахтер кулешын авыз итү мөмкинлеге дә тудырылды. Халык аны озын чиратка тезелеп алды.

Мәйданда Татарстан сәнгать осталары концерты һәм татарча көрәш бәйгесе уздырылды.

Кемеровода узган Федераль Сабан туенда Татарстан егете Радик Сәлахов батыр калды. Асболют батырга ул Башкортстан егете Турал Азимов белән көрәште.

«Бик көчле Сабантуй, көчле көндәшләр. Аллаһ ярдәме белән җиңү безнең якта булды. Җиңү җиңел булмады», – диде ул, мәйданнан төшкәч.

Федераль Сабан туе батырына «Лада» автомобиле һәм 57 мең сум акча, әлбәттә, тәкә бирелә. Батырга ачкычларны Кемерово өлкәсе губернаторының беренче урынбасары Илья Середюк һәм Лениногорск районы башлыгы Рәгать Хөсәенов тапшырды.

Радик Сәлахов – 2023 елгы дөнья чемпионы, Россия чемпионы. Тумышы белән Зәй районыннан. Лаеш районы данын яклап көрәште.

Р.МӨХӘММӘТОВА.
intertat.tatar.

Казанда яңа «Ал таң» мәчете

Татарстан мәчетләрендә Корбан гаете бәйрәмнәре булып узды. Казанның Имәнлек һәм Рихард Зорге урамнары чатында төзелгән Габдрәхим Утыз Имәни исемендәге «Ал Таң» мәчетендә беренче тапкыр Корбан гаете намазы укылды. Мәчет 2018 елда төзелә башлаган иде.

Корбан гаете вәгазен һәм намазын Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин алып барды. Гаеттә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, Казан мәчетләре имам-хатыйблары катнашты.

Вәгазь алдыннан мәчеттә Коръән укылды. Аннары Камил хәзрәт Сәмигуллин мөселман кардәшләрне Корбан гаете белән котлап, Россия Президенты Владимир Путин һәм Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның тәбрикләмәләрен укыды. Мөфти Казанда «Ал таң» дигән яңа мәчет төзелүне матур күренеш дип атады һәм Казанны Россиянең мөселман башкаласы булып танылуын әйтте.

«Казаныбыз – Россиянең мөселман башкаласы итеп танылды һәм елдан-ел ямьләнә, мәчет-мәдрәсәләребез эшли, динебез кысрыкланмый, киресенчә, үсә һәм киң тарала. Менә бүген бәйрәм намазын яңа гына салынган гүзәл мәчетебездә укыйбыз. Беренче намаз. Шәһәребездә тагын бер иман йорты барлыкка килде – бик матур күренеш бит», – диде мөфти.

Ул шундый изге эшләрне эшләүчеләргә рәхмәтле булырга өндәде.

«Бу хезмәтләргә үзебездән өлеш кертә алмыйбыз икән, һичьюгы комачауламыйк. Рәхмәтле була белик. Кешеләргә рәхмәт әйтә белмәгән Аллаһка да рәхмәтле түгел. «Сүзең булса рәхмәт, чикмәссең син зәхмәт», диләр халыкта. Бу сүз – Раббыбызга шөкер итә белмәү турында», – дип сөйләде Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Мөфтинең бәйрәм вәгазе тәнкыйтьнең файдалы һәм тискәре якларын сөйләүгә, тәнкыйтьне ничек дөрес кабул итүгә багышланды. Ул тәнкыйтьнең нәфестән һәм күңелләшүдән килүен әйтте. Тәнкыйтьне дөрес кабул итү өчен сабыр булырга кирәк дип белдерде.

«Тәнкыйть утында калсаң, шуны истә тотарга кирәк: әдәп ул – әдәпсезләрнең әдәпсезлекләренә сабыр булу», – диде мөфти.

Гает вәгазендә Камил хәзрәт Сәмигуллин корбан чалуның мәгънәсен дә аңлатты. Корбан гаетен күз буяу өчен генә корбан чалу бәйрәме түгеллеген әйтте. «Корбан гаете – газаптан куркучыга бәйрәм. Гает бәйрәме – ул яхшы машинага утырып килүчегә түгел, ә гөнаһларны калдыручыга чын бәйрәм», – диде мөфти.

Камил хәзрәт вәгазендә хәзерге вакытта Мина үзәнлегендә хаҗ кылучыларны да искә алып, исән-сау йөреп кайтуларын теләде.

Бәйрәм вәгазеннән соң мәчеттә Корбан гаете намазы укып, дога кылдылар.

Шагыйрә Нурия Измайлова вафат

Танылган шагыйрә, бик күп җырлар авторы Нурия Измайлова вафат. Бу турыда Татарстан Язучылар берлеге сайтында 1 июльдә хәбәр ителә.

Шагыйрә Башкортстан Республикасының Благовар районы Иске Күчәрбай авылында туган. Аннары Татарстанның Ютазы районында һәм Башкортстанның Шаран районында урта мәктәптә укыган. Югары белемне Казанда алган.

Нурия Измайлова «Яратам» (1981), «Алтын тарак» (1984), «Мин зур үскәч» (1986), «Ива на ветру» (1986), «Минем җәй» (1987), «Иң серле әкиятем» (1989), «Җирдә» (1993), «Ак малай – минем энем» (1995), «Адашкан» (2000), «Язылмаган хатлар» (2001), «Тауга карап, таулар булып…» (2011) китаплары авторы.

1982 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 1996 елдан ул Америкада яши иде.

«Татарстан Язучылар берлеге мәрхүмәнең гаиләсе, туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша. Урыны җәннәттә, авыр туфрагы җиңел булсын. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!» диелә хәбәрдә.

Сәидә Мөхәммәтҗанова студиясе ачылды

«Голос» телепроекты финалисты, яшь җырчы Сәидә Мөхәммәтҗанова Казанда үзенең иҗат студиясен ачкан. Шул уңайдан оештырылган иҗат кичәсен ул остазы, укытучысы Венера Гәрәева истәлегенә багышлаган.

«Венера Хәсәновна – Татарстанның халык артисты, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле хормейстеры һәм минем остазым. Нәкъ 25 июньдә Венера апаның туган көне булырга тиеш иде, студиямнең шушы көндә ачылуы бик тә туры килде. Иҗат кичәсендә татар халык җырларыннан торган альбомның презентациясе дә булды, ул альбомны без композитор, аранжировкалар ясаучы, музыкант Искәндәр Мостафин тырышлыгы белән чыгардык», – дип сөйләде ул.

Аның әйтүенчә, Венера Гәрәеваның васыяте буенча альбомдагы җырларны ул классик жанрда башкарган. «Эстрада стилендә түгел, ә нәкъ халыкчан яңгыраштa җырларга тырыштым. Альбомда 10 җыр тупланды һәм без шушы җырларга клиплар да төшерергә өлгердек, тиздән клипларны «Татарстан-Яңа гасыр» телеканалында күреп булачак», – ди җырчы.

Сәидә Мөхәммәтҗанова укытучысы Венера Гәрәева белән 2013 елда танышкан.

«Безне «Су буйлап» җыры таныштырды. Дуслыгыбыз Венера Хәсәновна вафат булганчыга кадәр дәвам итте. Ул миңа халыкчан җырлау буенча дәресләр бирде. Шуны да әйтим: Венера апа дәресләре өчен бервакытта да акча алмады. Ни өчен, дип сорагач: «Сәидә, әгәр дә синe укытып, милләткә файда китерә алсам, миңа шул җитә», – дип җавап биргән иде. Иҗат кичәмне Венера Хәсәновна хакына бушлай үткәрдек: азан әйтү белән башладык, рухына дога кылдык», – диде ул.

Сәидә Мөхәммәтҗанованың студиясе өч өлештән тора: тавыш яздыру студиясе (аның хуҗасы – Искәндәр Мостафин), вокал дәресе бүлмәсе һәм иң зур зал – репетиция, иҗади очрашу, кичәләр үткәрә торган зал, анда якынча 80 кеше сыя.

«Иҗат кичәләрем алга таба да булачак. Хәзерге вакытта үземнең сайтым бар, инде әзер, дип әйтсәм дә була. Сайтта аерым концертлар, иҗади кичәләр турында яңалыклар чыгып торачак. Иҗади планнарым бик күп. Халык җырларыннан торган альбом чыгаруны дәвам итәргә телим. Танылган композитор Луиза Батыр-Болгари белән дә иҗатташлык дәвам итә, Луиза апа белән тарихи җырлар өстендә күбрәк эшлибез, барлык клипларны социаль челтәрләрдә, Ютуб каналымда карый аласыз», – ди җырчы.

Сәидә Мөхәммәтҗанованың иҗат кичәсендә Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Татарстанның атказанган артистлары Ринат Вәлиев, Илүсә Хуҗина һәм баянчы, музыкант Ильяс Фәрхуллин чыгыш ясады.

З.МӨБӘРӘКШИНА.

Ринат Фәхретдинов җиңүе

Татар көрәшчесе, тумышы белән Пенза өлкәсеннән булган Ринат Фәхретдинов катнаш көрәш төренең UFC кысаларындагы өченче бәйгесендә Америка көрәшчесе Кевин Лины җиңде.

Фәхретдинов очрашуның беренче минутында ук Лины нокдаунга җибәрә һәм көндәшен буу алымы (гильотина) кулланып, бирелергә мәҗбүр итә.

Шулай итеп, 32 яшьлек татар көрәшчесенең уңышлары исемлегендә 21 җиңү һәм бер җиңелү бар. Үз чиратында, Кевин Ли 27 көрәшнең сигезендә җиңелгән.

Моңа кадәр Фәхретдинов UFC бәйгеләрендә үзенең ике көрәшендә, шул исәптән, Андреас Михайлидис һәм Брайан Баттлга каршы көрәштә җиңү яулаган иде.

230 килограмм наркотик

Татарстан хокук саклау органнары вәкилләре ел башыннан әйләнештән 230 кг нан артык наркотик матдәләр алган. Алынган барлык наркотик матдәләрнең 180 кг нан артыгы – «синтетика». Бу хакта «Казанские ведомости» газетасында Дамирә Хәйруллина яза.

«Татарстан Россиянең башка төбәкләрен наркотик матдәләр белән тәэмин итүдә транзит төбәк булып тора», – дип белдерде Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының наркоконтроль идарәсе бүлеге башлыгы Әнвәр Кәримов.

Ул безнең республика территориясенә «синтетика»ның, нигездә, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан килүен хәбәр итте. Ел башыннан полиция хезмәткәрләре шундый 24 каналны япкан. «Наркотиклар белән көчле агулану» диагнозы 200 татарстанлыга куелган, аларның 92 сен коткарып кала алмаганнар.

Шул ук вакытта, Татарстандагы наркоситуация «нейтраль» һәм «гомумән алганда, контрольдә тотыла» дип бәяләнә.

«Наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләр өчен быел 770тән артык кеше җаваплылыкка тартылган, – дип сөйләде Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының наркоконтроль идарәсе бүлеге башлыгы Әнвәр Кәримов. – Кагыйдә буларак, алар – даими керем чыганагы булмаган (63%) һәм элек җинаять җаваплылыгына тартылган (58%) 25 яшьтән 40 яшькә кадәрге җирле халык».

Сәяси золым корбаны

Зыятдин Камалиның исеме Ислам һәм татар дөньясында киң билгеле. Быел XX гасырның бөек дин белгече һәм мәгърифәтчесе Зыя Камалиның тууына 150 ел тула. Шушы уңайдан «Башкортстан туган якны өйрәнүчеләр берлеге»нең мактаулы әгъзасы, Шаһит Ходайбирдин исемендәге премия лауреаты Юрий Ергин белән билгеле шәхеснең тормыш юлы һәм дин-мәгърифәт эшчәнлеге турында әңгәмә кордык.

– Ун ел элек «Башкортстанның педагогик журналы»нда Сезнең «Зыя Камали – «Галия» мәдрәсәсенә нигез салучы: фаҗигале 30 нчы еллар» дигән мәкаләгез дөнья күрде. Пәрвәзетдин Камалетдинов 1873 елның 8 декабрендә Уфа өязенең Кара-Якуп волостендагы Келәш авылында күпбалалы ярлы гаиләдә туган. Ни өчен сезне Зыя Камали кызыксындырды?

– 1997 елда Казанда «Иман» нәшриятында басылган күләме буенча кечкенә (барлыгы 50 бит), әмма эчтәлеге буенча саллы булган «Зыя Камали: фикер иясе, мәгърифәтче, дин эшлеклесе» дип аталган китап белән таныштым. Ул вакытсыз вафат булган Т.Камалов (1964-1995) тарафыннан язылган. Китабында ул Башкортстан буенча Федераль иминлек хезмәтендә саклаunion «Камалетдинов Зыятдин эше»нә сылтама ясый. Әмма билгесез сәбәпләр аркасында әлеге тикшерү эшеннән документлар, Зыя Камалиның 1956 елда аклау датасыннан тыш, үзе тарафыннан кулланылмаган. Сез югарыда атаган журналда басылган мәкаләмдә мин бу бушлыкны өлешчә булса да тулыландыруны максат итеп куйдым.

– Пәрвәзетдин Камалетдиновның язмышы турында сөйләп үтсәгезче?

– Ул 6 яшеннән урындагы муллада сабак ала башлый. Аннары укуга сәләтле, тырыш малай белем алуын Уфада «Усмания» мәдрәсәсендә дәвам итә, аны тәмамлаганнан соң, 1898 елда Уфа мөселман хәйрия җәмгыяте акчасына Истанбулга укырга җибәрелә, шуннан Каһирәгә күчә. Анда ул «Әл-Әзһәр» университетында танылган дин белгече-реформатор Мөхәммәт Аббуда (1845-1905) белем ала. Укытучысы йогынтысында Пәрвәзетдин үзен фәнгә һәм мәгърифәтчелеккә багышларга карар итә, Аббу киңәше буенча исемен Зыяга үзгәртә (Зыятдин гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә – «нур, иман яктысы» дигәнне аңлата).

– Мисырдан Уфага кайткач, Пәрвәзетдин Камалетдиновны нинди язмыш көтә?

– 1904 елда Уфага кайткач, З.Камали күпмедер вакыт «Усмания» мәдрәсәсендә философия фәнен һәм Коръән укыта. 1906 елдан Уфада нәшер ителүче «Мөселман дөньясы» газетасында мәкаләләрен бастыра башлый, газетаның мөхәрририят әгъзасы һәм хәтта аның аерым чыгарылышларының мөхәррире була. 1906 елның октябрендә З.Камали яңа укыту ысулы кулланылган «Галия» мәдрәсәсенә нигез сала, ул Россиядә мөселманнарның беренче югары уку йорты була. 1908 елда ул Уфаның Икенче җәмигъ мәчете имамы итеп тә билгеләнә, бу аңа «Галия» мәдрәсәсенең рәсми җитәкчесе булырга мөмкинлек бирә. 1915 елда З.Камали төбәктә мөселман хатын-кызлары өчен педагогик юнәлешле беренче югары учреждение – «Әнәсия»не ача.

– Зыя Камалиның фәлсәфи мирасы да байдыр?

– Ул әле дә аз өйрәнелгән. Аның эшләренең тулы исемлеге дә билгеле түгел, чөнки аларның күбесе басылмый калган. 1909 елда З.Камали Уфада «Шәрык» нәшриятында үзенең төп хезмәте – «Ислам фәлсәфәсе»нең дүртенче өлешен – «Дини хезмәт фәлсәфәсе»н бастыра. Бу Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә зур кызыксыну тудыра. Киләчәктә бу хезмәтнең беренче һәм икенче өлешләре, «Иман фәлсәфәсе» исеме астында чыккан, «Аллаһның гаделлеге» (Уфа, 1910) һәм «Дини тәдбирләр» (Уфа, 1913) беренче өлешләренә кушымталары дөнья күрә. Кискен публицистик стильдә язылган бу хезмәтләрендә З.Камали киң аудитория өчен аңлаешлы татар телендә Исламны модернизацияләү, аның тәгълиматларын заманча фән һәм мәдәният белән берләштерү идеяләрен бәян итә.

Беренчеләрдән булып З.Камали татар теленә мөселманнарның төп изге китабы – Коръәнне, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең вәгазьләр язмасын тәрҗемә итә. Әмма консерватив руханиларның каршылыклы карашы бу ике томлы хезмәткә дөнья күрергә мөмкинлек бирми. З.Камалиның башка хезмәтләре дә басылмый кала. Мәсәлән: «Коръәннең чын юлы», «Безнең рухи мәктәпләр – мәдрәсә һәм мәктәп» һәм «Ислам фәлсәфәсе»нең өченче өлеше, нигездә мөселман юриспруденциясе мәсьәләләренә кагыла. Күрәсең, З.Камали язган «Дин тарихы» да югалган.

– 1917 елның Февраль һәм Октябрь революцияләре арасында Зыя Камалиның эшчәнлеге нәрсәдән гыйбарәт?

– Бу чорда З.Камали сәяси тормышта актив кайный: Мөселман руханилары берлеге әгъзасы итеп сайлана (Уфа, 1917 елның марты), Беренче Бөтенроссия мөселманнар съезды (Мәскәү, 1917 елның мае), Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Милли Җыелышы (Уфа, ноябрь, 1917 – гыйнвар, 1918) эшендә катнаша.

Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, Россиядә тулысынча урнашкан яңа сәяси режим шартларында З.Камали акрынлап актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлектән читкә китә башлый. Шуңа карамастан, 1923 елда ул Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте казые итеп сайлана, аның җитәкчесе мөфти Риза Фәхретдинов була.

● Зыя Камали.

– Зыя Камалиның Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте белән хезмәттәшлеге турында ниләр билгеле?

– 1924-1928 елларда Үзәк диния нәзарәте Уфада дини-әхлакый һәм фәлсәфи җыентык «Ислам мәҗәләсе»н (Ислам җыентыгын) бастыра. Аның мөхәррире казый Кәшәфетдин Тәрҗеманов була. Нәкъ менә шушы җыентык битләрендә З.Камали мөселман космологиясе, Исламның фәнгә мөнәсәбәте мәсьәләләре буенча үзенең төп идеяләрен, революциягә кадәр елларда барлыкка килгән һәм язылган, әмма басылмаган «Хәликәт галәм вә хәликәт бәшәр» («Галәмнең һәм кешелекнең барлыкка килүе») китабының эчтәлеген тәшкил иткән фикерләрен бәян итә башлый. Бу әсәрнең идеяләре 1924-1930 елларда вакытлы матбугат битләрендә Зыя Камали исеме астында барлыкка килгән радикаль-модернист характердагы басмаларның асылын тәшкил итә: болар – Кыямәт көненә, оҗмах, тәмугка ышану, «изгеләрнең» могҗизалы гамәлләре, фәнни хакыйкатьләрне, социаль һәм техник яңалыкларны турыдан-туры Коръәннән чыгару. Әмма З.Камалиның Ислам тәгълиматларын «социальләштерү» буенча омтылышлары ул вакытта Совет Россиясендә инде тулысынча формалашкан тоталитар режим шартларында аны коткара алмый.

– Ни өчен 1936 елда Зыя Камали СССР Эчке эшләр Халык комиссариаты органнары тарафыннан кулга алына?

– 1936 елның апрелендә мөфти Риза Фәхретдинов вафат була. Ул вакытта Үзәк диния нәзарәте, чынлыкта исә, дини мөселманнарга һәм мөселман руханиларына һөҗүм иткән сәяси репрессияләрнең ярсулы океанында ялгыз утрау булып кала. Риза Фәхретдиновның вафатыннан соң бер атна узгач, Мәскәүдә СССР Эчке эшләр Халык комиссариаты органнары тарафыннан «Үзәк диния нәзарәте җитәкчеләренең яшерен килешүе турында эш» кузгатыла. Гаепләүнең асылы түбәндәгечә: мөфти урынбасары казый Кәшәфетдин Тәрҗеманов Диния нәзарәтенең башка җитәкчеләре белән бергә (Зыя Камалетдинов нәкъ шундый билгеләмә белән кулга алына) мөселман халкының дингә ышанган өлеше арасында дин өлкәсендә дәүләт сәясәтенә карата ризасызлык тудыру максатында аны ябу турында карар кабул итә: дингә ышанучыларны Совет властена каршы чыгару. Барлыгы 25 кеше кулга алына, аларның күпчелегенең Үзәк диния нәзарәтенә бернинди дә катнашы булмый: алар Тәрҗемановның Мәскәү, Казан, Пермь һәм Ташкентта яшәүче яхшы танышлары даирәсенә керә. Тикшерү барышында кулга алынганнарны өстәмә рәвештә Кытай, Япония, Германия һәм Финляндиядәге татар эмиграциясе белән бәйләнештә булуда гаеплиләр.

1938 елның гыйнварында Мәскәүдә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе барлык кулга алынганнарны 5-10 елга иркеннән мәхрүм итә һәм РСФСР Җинаять кодексының 58-4 һәм 58-10 статьялары буенча биш елга хокукларыннан мәхрүм итә. Тәрҗеманов – 10, Камалетдинов 7 елга иркеннән мәхрүм ителә. Зыя Камали Беломор-Балтыйк комбинатының Киров тимер юлындагы Медвежья Гора станциясендә НКВД холык төзәтү-хезмәт лагерендә җәзасын үти.

– Зыя Камалига каршы икенче җинаять эше ничек кузгатылган?

– 1938 елның көзендә, Башкорт АССР Эчке эшләр Халык комиссариатының 3нче Дәүләт иминлеге бүлегенә Тәрҗеманов һәм Камалетдиновны «Башкортстан, Татарстан һәм Советлар Союзының башка өлкәләрендә контрреволюцион, исламистик баш күтәрүче оешма булдыруда һәм Ак эмигрантлар, контрреволюцион оешмалар һәм чит ил разведкалары белән элемтәдә» гаепләү турында өстәмә мәгълүмат килгәнгә күрә, икесе дә СССР НКВДсы санкциясе белән Уфага БАССР НКВДсының 3нче бүлегенә яңа җинаять эше кузгату һәм тикшерү үткәрү максатларында кайтарыла. Камалетдинов Уфага холык төзәтү-хезмәт лагереннан 1938 елның 7 октябрендә кайтарыла, ә Тәрҗеманов шул ук елның 14 октябрендә кайта. Тикшерү вакытында икесе дә НКВДның эчке төрмәсендә тотыла.

– Зыя Камалиның икенче җинаять эше ничек тәмамлана?

– Камалетдиновтан унсигез тапкыр сорау алына, әмма 1938 елның гыйнварында тәмамланган Мәскәү процессы белән чагыштырганда, ул бернинди дә яңа күрсәтмәләр бирми. 1939 елның 20 июлендә карар чыгарыла: «Камалетдинов Зыятдинны гаепләү буенча тикшерүне туктатырга, ә аны җәзасын үтү өчен Беломор-Балтыйк комбинатының Киров тимер юлындагы Медвежья Гора станциясенә НКВД лагерена кире озатырга». Бу карар нигезендә Зыя Камали Мәскәү процессы буенча җәзасын үтәүне дәвам итү өчен холык төзәтү-хезмәт лагерена җибәрелә. Әмма юлда ул авырый, поездан төшерелә һәм Куйбышев шәһәрендәге төрмәдә вафат була.

Башкортстан буенча Федераль иминлек хезмәте идарәсендә саклаучы Зыя Камалиның тикшерү эшеннән бары бер документ кына тулысынча тергезелгән. Ул, чынлыкта, 1938 елның март ахырында Уфада НКВДның эчке төрмәсендә язылган автобиография булып тора. Бу документ Зыя Камали тарафыннан фарсы телендә язылган, аннары урыс теленә тәрҗемә ителгән һәм сорау алу протоколы рәвешендә рәсмиләштерелгән, аның өч бите дә гаепләнүченең имзасы белән расланган. Беренче тапкыр ул ун ел элек «Башкортстанның педагогик журналы»нда басылып чыкты.

1956 елның 8 мартында СССР Югары судының Хәрби коллегиясе, 1937 елның 7 гыйнварында Мәскәүдә «Үзәк диния нәзарәте эше» буенча хөкем ителгәннәрнең материалларын тикшереп, (алар арасында Зыятдин Камалетдинов һәм Кәшәфетдин Тәрҗеманов та бар), яңа ачылган шартлар буенча һәм җинаять составы булмау сәбәпле, барлык хөкем ителгәннәргә карата хөкем карарын гамәлдән чыгара (ул вакытка дүрт кеше генә исән була).

Полина ПАВЛОВА.
Ләйсән ЯКУПОВА әзерләде.
«Кызыл таң» газетасыннан.

Депутатлар Тукай образын тикшерә

Татарстан Дәүләт шурасы депутатлары соңгы утырышта сәнгать әһелләрен Тукай образын бозуда гаепләде. Дәүләт сәнгатьчеләр эшенә тыкшынырга тиешме? Белгечләр бу депутатлар эше түгел, дип саный.

Депутатлар бер ай элек Г.Тукай турында әзерләнгән тамашаны тәнкыйтьләп чыккан һәм хөкүмәткә мөрәҗәгать юллаячагы турында кисәткән иде. Сүз 26 апрельдә М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында шагыйрьнең тууына 137 ел тулуга багышланган тантана турында бара.

Тамашаны режиссер Айдар Җаббаров куйды. Анда Тукайның Казанга килүе, татар зыялылары белән танышуы күрсәтелә. Шагыйрь образын Камал театры артисты Эмиль Талипов башкарды.

Тамашада Тукай образы күнегелгән күзаллаудан аерыла. Сәхнәгә ул күзлек киеп, таушалган киемнән чыга. Совет әдәбиятында сурәтләнгәнчә, таза гәүдәле итеп күрсәтелми. Шагыйрь тамашачы хозурына ябык, бераз югалып калган, борчылган һәм авыру хәлендә килеп баса.

Дәүләт Советы сессиясендә бу мәсьәләне КПРФ фракциясе җитәкчесе, депутат Хафиз Миргалимов күтәреп чыкты, Тукайдан көлгәннәр, диде ул парламент мөнбәреннән.

– Опера һәм балет театрында Тукайны кем модернизацияләде? Безнең Тукайдан көлмәскә кирәк. Ул – татар халкының Пушкины. Мәдәният министрлыгы, мәдәният комитеты, карагыз, алар ни эшләде! Нинди мәдәният бу? – дип ярсыды Миргалимов.

Коммунистның фикерен депутат Азат Хамаев та күтәреп алды.

– Без бу мәсьәләне депутатлар арасында тикшердек. Тукайны төзелеш аяк киеме кигән итеп күрсәткәннәр, – диде ул.

– Без мәдәният министрлыгы белән бу мәсьәлә турында фикер алыштык инде, – дип Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин бәхәсне туктатырга да тырышып карады.

– Әйдәгез, бу мәсьәләне ахырына кадәр эшләп бетерик, – дип Хамаев аерым карар кабул итәргә чакырды.

Ә менә Язучылар берлеге рәисе, депутат Ркаил Зәйдулла Җаббаровны яклап чыкты.

– Бу – Дәүләт шурасында карала торган эш түгел. Без совет вакытында милли каһарманнарны күз алдына һәйкәл сыман китерергә өйрәнгән. Ул төрлечә булырга мөмкин. Режиссер Җаббаров Тукайны үзенчә күргән. Хамаев киләсе елга әзерләр дә Тукайны үзенчә күрер, – диде ул.

Моңа җавап итеп, Хамаев урыныннан берничә тапкыр канәгатьсезләнеп кычкырды. Парламент рәисе Мөхәммәтшин «Егетләр!» дия-дия аны тынычландырды һәм Тукай образы тудырган сорауларны рәсмиләштереп, хөкүмәткә, мәдәният министрлыгына мөрәҗәгать итәчәген белдерде.

Яшь режиссер Айдар Җаббаров Тукай тормышын өйрәнеп, аның образын үзенчә сәхнәләштерүе турында ачып салды: «Тукайны пөхтә киенгән, таза һәм тук итеп күрсәтсәм, мин режиссер буларак алдаячакмын».

Татарстан мәдәният министрлыгы киләчәктә Тукай образын депутатлар кушканча гына күрсәтерме, инде сәнгати алымнарга да дәүләт тыкшына башлармы – вакыт күрсәтер. Шулай да, Украинада махсус операция башланганнан соң Россиядә дәүләт органнарының сәнгатькә тыкшынуы, спектакльләрне тыюы, сәнгать өлкәсендә цензура кертелүе, сугышны һәм патриотизмны гына яклаган әсәрләрне хуплавы Татарстанга да кагылмасмы?

Әдәби тәнкыйтьче Нияз Игъламовның үз фикере:

– Депутатлар фикере киңәш итү рәвешендә булса – яхшы. Әгәр бу боерык икән, ул сәеррәк. Депутатларны сайлап куйганнар бит, аларның хөкүмәткә, министрлыкка мөрәҗәгать итү хокукы бар. Инде катнаштырмаска, фәлән эш эшләргә дип боерык кушу булса, аларның моңа хакы юктыр. Әгәр мин спектакльгә рецензия язам икән, ул миңа ошамады, аны тыярга кирәк, димим. Мин үземнең тәнкыйтемне әйтәм. Ә инде депутатлар күрсәтергә ярамый дисә, монда цензура башлана.

Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла депутатларның сәнгать әсәрләрен тикшерергә хакы юк дип саный:

– Башка эшләре юктыр инде. Бер мәкаль бар: эше булмаган эт койрык астын ялый ди. Тукай образын Җаббаров ничек күргән, шулай куйган. Ибраһим Нуруллинны да Тукайны түбәнәйткәнсең дип тәнкыйтьләп маташтылар. Ул түбәнәйтмәгән, дөресен язган. Бүгенгә кадәр Тукайны идеаллаштырып, алла-лаштырып карау яшәп килде. Тукай – ул кеше, ул фәрештә дә, әүлия дә, пәйгамбәр дә түгел. Бөтен җитешсезлекләре, бөтен бөеклеге белән кеше. Аның ялгышлары да булырга мөмкин, ләкин Тукайның тәмәке тартканлыгы бөеклеген киметә алмый... Юк әйберне казып чыгарып, Җаббаровка бәйләнәләр. Бер дигән спектакль ул. Беренчедән, Тукай мескенлек чире белән чирләгән. Ул үзенең бөек икәнен дә белгән, кимсенгән дә. Аның күзе сукырая. Үлеменә кадәр үпкәсенең дүрттән бер өлеше белән генә сулап тора алган. Анда нинди баһадирлык булсын? Бичара авыру, мескен кеше. Аны мескен итеп күрсәтеләре килми. 27 яшьтә аны туберкулез ашап бетерә. 7 ел гына иҗат итә. Хәзер 70 ел аның җылысында җылынабыз. Менә нәрсәсе белән бөек ул. Тукай кимсенгән, хатын-кызлар арасына чыкмаган. Бер күзе сукыр. Бүлмәдә бергә яшәгән Вафа Бәхтияровның хәтирәләрендә көлке чыганак итеп дөресен яза. Юньле кием кигәне булмады, ди. Бер-берсенә ярашмый торган төсләр сайлый иде, ди.

Бу – театр, әдәбият белгечләре шөгыльләнә торган эш. Дөрес күрсәтелгәнме, юкмы – депутатлар моның өчен театр һәм әдәбият белгечләре дә түгел. Депутатлар үз эшләре белән шөгыльләнсен иде. Эш бик күп. Ана теле куркыныч астында, мәгариф системы какшады, мәктәпләр ябылды, татар теле дәресләре кимеде. Менә нәрсә хакында уйларга кирәк. Җаббаровның бер спектакленә бәйләнәләр. Адәм көлкесе. Халык санын алган саен ярты миллионга кимибез. Халык алай кими алмый бит. Җанисәптә ялган, алдау хөкем сөрә. Оятсыз рәвештә. Менә нәрсә хакында уйларга кирәк парламентка! Тукайда казынып ятарга кирәкми. Тукайны идеаллаштырып күрү бик зур ялгышлык. Ленинны, Сталинны идеаллаштырдык. Хәзер тагын берәүне идеаллаштырабыз, – ди ул.

Заманында Р.Батулланы «Колакчын Тафи» әкияте өчен Татар обкомына чакыртып, ТАССРның элекке беренче секретаре Фикрәт Табиев образын сурәтләүдә гаеплиләр. Хәзерге вәзгыять шул чорны хәтерләтәме, дигән сорауга Батулла: «Озакламый бу Табиев чорын хәтерләтер. Кайбер әйберләрне кычкырып әйтергә, тәнкыйтьләргә ярамый. Ирекле иҗат итү һәр кешенең үзеннән тора. Сталин вакытында да дөресен әйтергә тырышучылар булгалады. Читләтеп, каптырып, суктырып булса да. Кинаяләр белән әйтергә тырышып карадылар», – диде.

Татарстанның халык артисты Гөлзада Сафиуллина дәүләт сәнгать эшенә тыкшына дип саный:

– Дәүләт турыдан-туры тыкшынмый, моны театрларның мөдирләре аша эшли. Аларның башларына сугып торалар. Анда әзер тәнкыйтьчеләр бар. Барысы да оешырылган. Иҗат кешесе күпме көч салып чыга, ләкин туктаталар, яки башка юнәлеш алуны сорыйлар. Әнә, «Идегәй» спектакле турында күпме бәхәс булды. Өстәгеләр тыкшына, аларга балансны сакларга, Мәскәү кушкан юлны дәвам итәргә кирәк. Безнең бит юлыбыз Мәккәгә төбәлсә, дөресрәк. Әгәр сәнгать кешесе үзен ирекле итеп хис итми икән, ул Аллаһ Тәгалә биргән сәләтен чын күңелдән тормышка ашыра алмый. Минем архивымда йөзләгән җыр ята. Мин аларның күбесен җырламадым, чөнки алар минем ирегемә, дөньяга карашыма, яшәү рәвешенә туры килми. Мин һәрвакыт ирекле булдым. Дистә еллар телевизордан күрсәтмичә, зур концертларга чыгармыйча йөрттеләр. Бары үз концертларым белән генә йөрдем. Анда да күпме концертларымны уздырмадылар. Әгәр син ирекле булмасаң, башкаларга хезмәт итәсең. Иганәчең булса, син аның идеясен тормышка ашырасың, дәүләт театрларында булса, аларның җырын җырларга тиешсең. Мин дәүләт филармониясендә эшләгәндә программаны тикшереп, бу композиторның, шагыйрьнең әсәрен кертмәскә, фәлән кешене җырлатмаска дигән боерыклар бар иде, – дип сөйләде.

Шул ук вакытта Гөлзада Сафиуллина Тукай образын йомшарту бара дип саный. Ул шагыйрьнең «батырлыгын, кыюлыгын, реформаторлыгын» башка яктан күрсәтү барлыгын да әйтте. «Бүген каһарманнарыбызны якларга халыкның хакы бар», – диде ул.

Эльвира САФИНА

Сабый булып яткан идек, Картлар булып уяндык...

ТОЛСТОЙ ЭЗЛӘРЕ

Бу бинада Толстой яшәгән бит!
Бу юллардан Толстой йөргән!
Уку-язуыннан арып китсә,
Чыгып кергән «Черек күл»енә.

Толстой йөргән сукмакларны урыйм,
Толстой гамен тоеп җанымда.
Ниләр уйлап йөргән икән димен
Казанында яшьлек таңында?

Толстой көндәлеген кулга алам,
Болыт кунса аяз күгемә.
Фикерләрне җайга салыр өчен,
Чыгып керәм «Черек күл»емә.

Толстой рухы анда, Толстой тыны,
Толстой сабырлыгы һаман да.
Шау-шу арасыннан тынлык эзлим
Толстой моңы сеңгән Казанда.

УЛЫМ БИИ

Сәхнә уртасында улым бии!
Минем күзем бары аңарда.
Йөрәккәем, аягына кушылып,
Бии гүя утлы табада!

Ялгышмасын, абынмасын диеп,
Дулкынланып карап торамын,
«Сөбханаллаһ! Булдыра бит!» – диеп,
Белгәнемне укып куямын.

Нинди шатлык, нинди горурлык бит!
Аңлатырга җитми сүзләр дә.
Әниләрнең өзелеп яратуы –
Баласына баккан күзләрдә!

Һәр биюең, һәрбер хәрәкәтең
Кабатланмас бүләк бит, балам!
Мәмнүн булып карап торып, шушы
Манзарадан күпме көч алам!

Очып-очып биегәндә, улым,
Арыса да аяк-кулларың,
Бию көйләредәй җиңел булсын,
Матур булсын барыр юлларың.

Бии-бии күңелләрең үсә,
Бии-бии рухың ныгый бит!
Шатлансаң да биеп җибәр, улым,
Сынауны да биеп уза бел!

Җыр-биюләр безне көчле итә,
Җыр-биюләр безне яшәртә!
Насыйп булсын, улым, гомер буе
Җырлап-биеп матур яшәргә!

ҖӘЙ ТӘМЕ УЛ – ҖИЛӘК

Минем өчен җәй тәме ул – җиләк,
Туган якта үсә торганы!
«Балакаем кайтыр әле» диеп,
Кызарыплар пешеп куйганы.

Минем өчен җәй яме ул – җиләк,
Саф һавасы туган ягымның!
Җиләк вакытлары җитү белән,
Ничек түзим канат кагынмый?!

Минем өчен җәй төсе ул – җиләк,
Ел да килә шуны күрәсе,
Һәр җәемнең җиләкләрен җыеп,
Такыялар итеп үрәсе!

Минем өчен җәй җыры ул – җиләк,
Сайрар кошлар отып алганы,
Җиләк җыйган чакта җанны назлап,
Күңелемә кереп калганы.

Минем өчен җәй исе ул – җиләк,
Аңа торыр исләр юктыр шул.
Тәмләп сулап, җыеп кала торган
Ел буена җитәр көч бит ул!

ҮЗЕҢ ЯРАТ

Яратканнарын көтмә әле,
Тот та син үзең ярат,
Бүләк тә көтеп утырма,
Бүләкне үзең тарат.

Матур сүзләр өмет итмә,
Ихластан үзең макта.
Рәхмәтеңне әйтми калма,
Әйтсәсе килгән чакта.

Наз-игътибар җитми димә,
Игътибарлы бул үзең.
Йөрәкләренә май булсын
Яратып әйткән сүзең.

Кадер-хөрмәт юк бит, диеп,
Күңелеңне төшермә.
Кадерлә дә, хөрмәтлә дә,
Хисләреңне яшермә.

Үзеңә кирәк нәрсәне
Башкаларга бир шулай.
Күңелең саф, ихлас булса,
Күрми калмый ул Ходай!

ЯРАТМАСАҢ – БЕТТЕ БАШ

Бөтен нәрсә үз-үзеңне
Яратудан башлана.
Ярата белмәгәннәргә
Юк бернинди ташлама.

Буй-сыныңны, күз-кашыңны
Яратмасаң – бетте баш!
Яхшы чакта башкаеңны
Берәр кая ал да кач.

Тик качып котылып булмас –
Уйларың баш эчендә,
Элеккеге яман уйлар
Калалар үз көчендә.

Өстең-башың, күз-борының
Бар да үз урынында.
Начар уйлый күрмә берүк
Һич тә алар турында.
Башыңны комга яшермә,
Җиңелрәк юлны сайла:
Үзеңне яратмый торып
Яшәп булмавын аңла!

* * *

Бер җылы сүз көтә күңел
салкын бозны
эретерлек,
җан үзәген
чеметерлек.
Л.Шәех

Бер җылы сүз көтә күңел,
көтә бары,
белмим, кемнәндер...
Бәлки, синең яктан
хәбәр китеручә
җилдәндер,
Бәлки, ерак яшьлегемдә калган,
күктә очып йөргән көннәндер...
Бәлки, җан үзәген чеметтереп,
бүгенге көн миннән көлгәндер?!
Тик шулай да...
өметләнеп,
ялынып һәм ялварырдай булып,
ике күзем яшьләремә тулып,
бер җылы сүз көтәм
кемнәндер...

САУМЫ, ДИҢГЕЗ

Саумы, диңгез, мин дә килдем сиңа,
Сөйлә әле, сөйлә хәлеңне.
Әллә синең бар дөньядан качар,
Үз-үзеңнән ташар мәлеңме?

Син дә безнең кебек ярсыйсыңмы,
Бәргәләнеп эчең-тышыңда?
Һәр халәтең сизелә бит юкса,
Сизелә бит, әнә, тыныңда.

Бер шаулыйсың ярсып, ачуланып,
Үз-үзеңә сыя алмыйча.
Ярларымнан ташам, дия-дия,
Тирә-якка күз дә салмыйча.

Бар ачуың, үпкә, нәфрәтләрең
Дулкын булып ярга бәрелә.
Күз яшьләре синдә дә бар икән –
Күндек инде тозлы тәмеңә.

Үртәгәндәй, бәлки, үртәлгәндәй,
Көч-гайрәтле булып аласың.
...Һәм тынасың, берни булмагандай,
Шундый сабыр булып каласың.

Могҗиза син, аңлап булмый торган,
Беркем белми – ниләр уеңда...
Күңел халәтеңне гөманлап мин
Йөрим менә ярың буенда.

ҖЫЛЫ ӨЕ БУЛГАНДЫР

Казан үзәгендә... кеше яшәми торган йорт баскычларына кием-салымнарын, төргәкләрен тезеп куеп... өстенә иске юрган ябынып йоклап яткан олы яшьтәге абыйны күргәч...

Кайчандыр бит җылы өе,
Караваты булгандыр,
Тәмле ашларын пешереп,
Кемдер көтеп торгандыр,
Матур киемнәрен киеп,
Өйдән чыгып киткәндер,
Ипи-сөтләр ала-ала,
Эштән кайтып кергәндер,
Бик күп китап укыгандыр,
Әллә ниләр белгәндер,
Чибәр булып, бик күпләрнең
Төшләренә кергәндер.
Туганнарга, дусларына
Кунакларга йөргәндер,
Шаяргандыр, уйнагандыр,
Эче катып көлгәндер.
Нәни кызын тирбәткәндер,
Улын күккә чөйгәндер,
Сөеклесе кочагына
Татлы йоклап киткәндер...
...Үз җаена аккан тормыш
Үзгәрепләр куйганмы,
Кичермәслек гөнаһлары,
Ялгышлары булганмы?..
Ни булса да булган инде:
Ташландык өйнең баскычын
түшәк иткән. Туңадыр...
Кайчандыр бит җылы өе,
Караваты булгандыр...

КАРТЛАР БУЛЫП УЯНДЫК

Мал артыннан куа-куа
Бигрәкләр дә вакландык,
Кирәксә-кирәкмәсә дә
Адым саен зарландык.
Бернигә дә сөенмибез,
Боекландык, тарландык,
Көн саен юына торып,
Кергә баттык, тапландык,
Ярыкларны каплый-каплый,
Кәбестәдәй катландык,
Күршебез абынган чакта
Җүләр кебек шатландык.
Башкаларны буйыйм диеп
Үзебез үк буялдык,
Сабый килеш яткан идек,
Картлар булып уяндык.

ҮЗГӘРӘСЕ КИЛӘ

Үзгәрәсе килә кайвакытта:
Чәчне бөтен төрле итәсе,
Өс-башларны үзгәчәрәк итеп,
Бөтәнчәрәк атлап китәсе.

Үзгәрәсе килә кайвакытта:
Икенчерәк күлмәк сайлыйсы,
Көзгедәге чагылышка көн дә
Елмаебрак килә карыйсы.

Үзгәрәсе килә кайвакытта:
Бөтән ислемайлар сөртәсе,
Сүлпән генә аккан тормышыңа
Башка төрле ямьнәр кертәсе.

Үзгәрәсе килә кайвакытта:
Күмеләсе ачык төсләргә!
(Соры киемемә төренгәндә,
Сокланамын кыю кешеләргә).

Ымсынам да, кабат тынып калам,
Чәчем дә шул, керфек-кашлар да...
Күнегелгән. Соңдыр инде хәзер
Яңа төсле тормыш башларга.

Төркияле Бәһиҗә Боранның

Төркия җөмһүриятенең сәяси тарихында әһәмиятле роль уйнаган галимә һәм дәүләт эшлеклесе Бәһиҗә Боран ханымның татар асыллы булуын төрекләр үзләре дә белеп бетерми, безнең дә бүгенгәчә шундый олы шәхес турында берни ишетми яшәвебез гаҗәп. Төркиядә социализм идеяләрен фәнни нигезгә куйган һәм аларны тормышка ашыру өчен гомеренең соңгы көннәренә кадәр көрәшкән, Төркия эшчеләр партиясенең (ТЭП) көчле лидеры Бәһиҗә Садыйка Боран, әти-әнисенең Казан татары булуын, 1890 елларда күченеп килүен танылган журналист Угур Мумҗуга (1942–1993) биргән интервьюсында үзе сөйли: «Казаннан... Кырымнан түгел», – дип тә төгәлли хәтта. Әти-әнисенең гаиләләре Төркиягә төрле юллар белән аерым-аерым килеп урнашуын, әнисенең Истанбулдан Бурсага «килен булып төшүен» дә әйтә.

Бәһиҗә Боран шәхесе хакында татар укучыларына да берникадәр мәгълүмат бирү кирәкледер.

Бәһиҗә 1910 елда Бурса шәһәрендә Садыйк әфәнде белән Маһирә ханым гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Урта хәлле сәүдәгәр Садыйк әфәнде ашлык алып-сатып көн итә, үз заманы өчен шактый укымышлы булган әти кеше, Бәһиҗәнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Казан татарларына хас булганча», кызларының белемле булуына, чит телләр өйрәнүенә аеруча игътибар бирә, мәсәлән, олы кызын Бурсадагы француз мәктәбендә укытырга тели, ул ябылгач, дарелмөгаллимәткә бирә. Лицей бетергән улын да Истанбулда югары сәүдә мәктәбендә укыта.

Беренче бөтендөнья сугышы бетеп, Төркиядә милли-азатлык көрәше барганда, Бурса шәһәре греклар кулына күчә, Садыйк әфәнде гаиләсе белән Истанбулга күченергә мәҗбүр була. Башлангыч белемен Бурсада алган Бәһиҗә монда француз мәктәбенә керә, ул ябылгач, Американ кыз колледжына күчә, 1927 елда урта мәктәп, 1931 елда лицей программасын уңышлы тәмамлап, Истанбул университетының фәлсәфә бүлегендә белем ала башлый. Шул ук вакытта илдәге наданлыкны бетерү эшенә үзеннән өлеш кертү өчен, ватанпәрвәр кыз педагогик хезмәт юлын да башлап җибәрә. Балаларга чит телләр өйрәтеп йөргән Бәһиҗә Садыйканы, университетны тәмамлавын дә көтеп тормыйча, Маниса якларындагы авылларның берсенә укытырга җибәрәләр. Озак та үтми, көтелмәгән куанычлы хәл була: аның исеменә Америкадан махсус чакыру килеп төшә. Әле колледжда укыган вакытта ук аның бик тырыш булуын аңлап алган америкалы педагогларыннан берсе, аның исемен Мичиган университетында ачылган стипендияле уку курсларына яздырган була, һәм шулай итеп ул АКШка юл тота. Мичиган университетының социология бүлеген тәмамлый, 1939 елда исә фән докторы дәрәҗәсен ала, Америкада мондый югары гыйльми дәрәҗә алучы беренче төрек-татар хатын-кызы була. Марксизм-ленинизм, социализм идеяләре белән якыннан кызыксынуы шул студент чорларында көчәя. Төркиягә кайткач, Әнкара университетында социология фәне буенча доцент дәрәҗәсе алып, фәнни-педагогик хезмәт белән шөгыльләнә башлый. Дәресләрендә студентларны мөстәкыйль фикер йөртергә, мәгълүматны тәнкыйть күзлегеннән кичереп кабул итәргә өйрәтә, аның лекцияләрен тыңлау өчен хәтта башка уку йортларыннан да килүчеләр күп була. Анадолу авылларындагы иҗтимагый тормышны анализлаган китап һәм мәкаләләр бастыра, социология өлкәсендәге фикерләре халыкара күләмдә кызыксыну уята. Шул елларда әдәби тәнкыйть мәкаләләре дә күп яза, Европа әдәбиятының күренекле шәхесләрен (Шарлотта һәм Эмили Бронте, Уильям Теккерей, Джеймс Джойс, Вирджиния Вульф һ.б.) беренчеләрдән булып төрекләргә таныта. Төрек авторларының әсәрләрен исә «сәнгать – сәнгать өчен түгел, сәнгать – җәмгыять өчен» принцибыннан чыгып анализлый һәм әдәбиятта реализм агымы хакында үзенчәлекле, социология фәне югарылыгыннан чыккан карашларын тәкъдим итә. Шигырьләр дә язган Бәһиҗә Боранның әдәби тәнкыйть язмалары вафатыннан соң аерым бер китап булып басылып чыга [Boran].

Бәһиҗә Боранның зур сәясәт белән актив шөгыльләнә башлавы Икенче бөтендөнья сугышы чорына туры килә, 1942 елда ул Төркия коммунистлар партиясенә (ТКП) керә һәм төрек идарәчеләренең нацистлар Германиясе белән хезмәттәшлек итүенә каршы оештырылган протест чараларында катнаша. Төркия яшьләр оешмасы һәм Прогрессив демократ яшьләр оешмасы кебек органнарда әйдәп баручы була, илдә антифашистлар хәрәкәтен куәтләгән чыгышлар ясый. 1941–1943 еллар арасында, Пәртәв Наили Боратав, Ниязи Бәркәс, Шәриф Башоглу кебек күренекле төрек галимнәре белән берлектә, Бәһиҗә ханым «Ватан һәм дөнья» (Yurt ve Dünya), аннан соң «Адымнар» журналларын чыгара. Мәкаләләрендә сәяси карашларын фәнни теорияләргә нигезләп аңлата. Төркиядә ул чорда даими үзгәреп торган сәяси шартлар тәэсирендә бу матбугат органнары ябылгач, «Милли шеф» режимына каршы оппозициядә торган «Таң» газетасы һәм «Карашлар» (Görüşler) журналында, үз фикерләрен ачыклап, язмалар бастыра. Идеяләре рәсми хакимият ияләренең карашлары белән туры килмәү аркасында, «коммунизм пропагандасы таратуда» гаепләнеп, 1945–1946 елларда эше мәхкәмәләрдә тикшерелә һәм 1948 елда сәяси бер карар нәтиҗәсендә педагогик хезмәтенә чик куела. Аның белән бергә көрәшкән ир-атлардан Боратав, Бәркәс чит илгә качарга мәҗбүр була, Бәһиҗә ханыма да төрле илләрдән укытырга чакырулар килсә дә, ул туган җирен ташлап, беркая да китәргә теләми, мәхкәмәдә үз-үзен яклый алачагына ышана. Тормышында шушындый туктаусыз мәхкәмәләр, эзәрлекләүләр булып торган чорда, 1946 елда Бәһиҗә ханым кияүгә чыга: ире чиркәс (адыгей) асыллы Невзат Хатко (1911–1982) – Грециядә политехника университетында авыл хуҗалыгы бүлемен тәмамлаган, Греция коммунистлар партиясенең яшьләр оешмасында эшләгән кеше. 1938 елда Төркиягә кайткач та, төрек коммунистлар партиясе әгъзасы була, «Анадолу агентлыгында» тәрҗемәче булып эшли һәм грек теленнән Аристофан, Корнарос, Н.Казандзакис, С.Миривилис һ.б.ларның әсәрләрен тәрҗемә итә. Өйләнешкәч, алар дүрт кеше – икесенең дә әниләре белән бергә яши. Сәяси карашлары аркасында, тиздән ирле-хатынлы икесе дә эшсез кала, матди проблемалар башлангач, Истанбулга күчеңә һәм хосусый тәрҗемә бюросы ача. Рәсми документлар белән берлектә, Бәһиҗә ханым инглиз теленнән әдәби әсәрләр дә тәрҗемә итә. 1946 елда төзелгән Төркия социалист эшче һәм крестьяннар партиясенә якын тора, бу партиянең баш органы сыйфатында чыккан «Сүз» газетасында мәкаләләр бастыра. Кызыл Армиянең фашизмны җиңүе, Советлар Союзының сугыштан соңгы эчке һәм тышкы сәяәте аның карашларының дөреслеген исбатлый, шуңа күрә фикердәшләренең саны да көннән-көн арта бара. Бу чорда күренекле шагыйрь Назыйм Хикмәт, язучылар Орхан

нәселе – Казаннан

Кәмал, Абидин Дино, Суад Дәрвиш, Решад Фуад Баранер, журналист Сәртәл һәм тагын бик күп зыялылар буржуазия диктатурасына һәм империалистик изүгә каршы көрәшүчеләр сафында була.

1950 елның җәендә Бәһиҗә Боран, иптәшләре белән берлектә, Төрек тынычлык сөючеләр җәмгыятен оештыра һәм җитәкли, бу җәмгыять хакимияттәге Демократлар партиясенең, парламент карары булмаган килеш, АКШ тарафын яклап, Кореяга гаскәр җибәрүенә каршы чыккан бердәнбер оешма булып тарихка кереп кала. Рәсми протест текстын бастырып таратучылар, «милли мәнфәгатьләргә зарар бирүләре өчен», хәрби-сәяси суд тарафыннан хөкем ителә, бу мәхкәмәдә Бәһиҗә ханым ялкынлы чыгыш ясап, илдәге тынычлык яклы кешеләрне берләшергә чакыра, Кореяда барган сугышка чит илләрнең катышуын тәнкыйть итә. 15 айга ирегеннән мәхрүм ителгән Бәһиҗә икенче баласы Дурсунны 1951 елда төрмәдә таба (беренче баласы – кызы Әлиф бик кечкенә вакытта вафат була). Бу елларда хөкүмәт илдә коммунистлар идеологиясен һәм хәрәкәтен юк итү өчен аяусыз чаралар үткәрә, төрмәдән яңа гына чыккан Бәһиҗә исә үзе сайлаган юлдан баш тартмый һәм, ТКП оештырган чараларда катнашкан өчен, 1953 елда тагын биш айга кулга алына. 1954–1960 еллар арасында гына ул, сәясәттән бераз читләшеп, өйдә утыра: улын тәрбияли, әнисен һәм каенанасын карый, буш вакытларында әдәби әсәрләр һәм тарихи хезмәтләрне төрекчәгә тәрҗемә итү белән мавыга. Гомумән, кечкенә гәүдәле, әмма көчле рухлы Бәһиҗә ханымны якыннан таныган кешеләр аның гаять гаилә җанлы булуын, тәмле камыр ризыклары пешерүен, ә соңрак, ире Невзат-бәйне паралич суккач, аны яшь бала кебек каравын искә ала.

Авыр икътисади кризис хәлендә булган Төркиядә демократия аерата кысрыкланган, протестлар кискен бастырылган, хөкүмәткә каршы язган матбугат аяусыз тыелган дәвер 1960 елның 27 маендагы гаскәри түнтәрешне китереп чыгара, нәтиҗәдә, Аднан Мендерес хөкүмәте бәреп төшерелә. Илдәге вакыйгалар, бигрәк тә яңа Конституция язу өстендә алып барылган эш Бәһиҗә ханымны бик өметләндерә. 1961 елның февралендә Төркия эшчеләр партиясе (ТЭП) корыла, аның сафына ватанпәрвәр интеллигенция әһелләре тартыла, партия рәисе Мехмет Али Айбар Бәһиҗә ханымны да үз партиясенә керергә өнди. Чакыруны кабул иткән Бәһиҗә Боран ТЭПнең уставын төзүгә зур өлеш кертә, 1964 елдан башлап, партиянең җитәкче органнарында урын ала һәм, 1965 елда Шанлы Урфа шәһәреннән депутат итеп сайланып, Төркиянең Бөек Мәҗлесенә керә. 1965–1969 елларда ул парламентта, ТЭПнең тышкы сәясәте спикеры буларак, күп мәртәбә ялкынлы чыгышлар ясый. Аның эшсезлекне бетерү, эшсезләрне социаль яклау, ихтыяҗы булган крестьяннарга җир бүлеп бирү, авыл балаларын бушлай укыту, авыл мәктәпләрен арттыру кебек мәсьәләләрне күтәреп чыккан чыгышлары халык арасында теләктәшлек таба.

«Кара син минем шул хәлемә, – ди ул үзенең яшьлек дусларыннан берсенә. – Минем, кафедрада калып, дәрес биреп, укучыларым белән шөгыльләнеп, тар бер даирә кешеләр белән генә дус булып яшисем килә иде. Хәзер исә сәяси көрәшнең нәкъ уртасында торам, ничек бу эшне башкарып чыгармын, кем белсен» [Urgan,125]. Чынлап та, аның сәяси эшчәнлеге илдәге тотрыксыз хәләткә бәйле рәвештә, гаять тынгысыз һәм авыр була. 1966 елда ул эшчеләр партиясенең Икенче конгрессында мәркәз идарә бюросына керә, 1970 ел башында ТЭП секретаре итеп билгеләнә, шул ук елның октябрендә узган Дүртенче конгресста партиянең рәисе итеп сайлана. Бу елларда Бәһиҗә Боран сыйнфый көрәштә демократик методларны куллануны яклый, НАТО члены буларак Төркиянең Көнбатыш мәнфәгатьләренә тулысынча буйсынуын тәнкыйтьли, илдәге «көрд халкы проблемасын» хәл итүдә тар миллиятчелек сәясәтенең ни кадәр зарарлы булуын аңлатып чыгышлар ясый.

1971 елның 12 мартында исә илдә тагын түнтәрелеш була һәм шул елның июлендә ТЭПнең эше рәсми рәвештә туктатыла, Бәһиҗә ханым һәм партия идарәсендәге көрәштәшләре кулга алына, бу юлы да Б.Боран мәхкәмә барышында үзен хөкем ителүче түгел, хөкем итүче кебек тота, кыю чыгышлар ясый. 15 елга хөкем ителсә дә, 1974 елның июлендә амнистия буенча азат ителгәч, ТЭПне яңадан коруга ирешә, мондый кыюлыгы нәтиҗәсендә илдәге демократик хәрәкәтнең куркыту белән генә бастырылмаячагын раслый, көрәшнең яңа юлларын һәм ысулларын эзли.

1979 елгы сайлауларда эшчеләр сыйныфына таянган ТЭП элеккеге кебек күп тавыш җыя алмый, шуңа Бәһиҗә ханым партиянең стратегиясе өстендә аналитик эш алып бара, буржуазиягә каршы көрәштә социалист сул көчләрне берләштерү юлында яңа адымнар ясау, коммунистлар белән берләшү фикерен куәтли. «Бер фронт, бер партия!» девизы белән көрәшкә чакырган уртак бер китап бастырыла, ләкин бу идеяләрне тормышка ашырырга насыйп булмый, 1980 елның 12 сентябрендә чираттагы хәрби түнтәрелеш илдәге бөтен социалистик хәрәкәткә богау сала. Күпмедер вакыт үз өендә тоткын булган Бәһиҗә Боран бик көчле йөрәк өянәге кичерә, аның авыр хәленә бик кайгырган иптәшләре, сәяси эзәрлекләү беткәнче, аңа чит илдә яшәп торырга киңәш итә, ватанын бер дә ташлыйсы килмәсә дә, ул Бельгиягә китәргә мәҗбүр була. «Сәясәт эшенә керешкәндә, бар нәрсәне күз алдында тоткан кебек идем: төрмәләрдә ятасымны, басым ясалачагын һәм башкаларны... ләкин 76 яшемдә чит илдә сөргендә яшәвем уема да кереп чыкмаган иде», – дип ачыклый ул үзенең соңгы интервьюсында.

Бәһиҗә ханым, партиясе һәм үзе турында мәхкәмә эше тикшерелгәндә, ватанына кайтырга боерык ала, кайтмагач, 1981 елда рәсми рәвештә Төркия гражданлыгыннан чыгарыла. Сәяси качак вәзгыятендә яшәгәнгә, Бельгия хөкүмәтеннән аз булса да айлык акча ала, шуңа бик тыйнак тормыш алып бара. Дөнья сәясәте белән якыннан кызыксынып, көндәлек газеталарны укып бара, чит илдән торып, партиясендәге бердәмлекне сакларга тырыша, ике партияне (ТЭП һәм ТКП) берләштерергә омтыла, ләкин моңа ирешү бик җиңел булмый: ике якны да инандыру өчен Бәһиҗә ханым шактый күп көч сарыф итә. Ике партия бары тик 1987 елда гына берләшә һәм Төркия Бердәм коммунистлар партиясе (ТБКП) исемен ала, аның рәисе итеп, олы яшьтә булуына да карамастан, тагын Бәһиҗә Боран сайлана. Тик шул вакыйгадан соң ике көн узгач, 10 октябрьдә Брюссельдә Төркия эшчеләр сыйныфының сәяси көрәшендә ару-талуны белмичә, гомеренең соңгы көннәре кадәр әйдәп барган Бәһиҗә ханымның йөрәге тибүдән туктый.

Ул улына үзен ватанында, әгәр ул мөмкин булмаса, ире янында Болгариядә күмәргә васыять иткән була, Дурсун Хатко әнисен Төркиягә алып кайтырга рөхсәт ала, Әнкарада Бөек милләт мәҗлесе каршында һәм Истанбул мәркәзендә киң күләмле хушлашу чаралары үткәрелә. 45 ел буена тынычлык, сыйнфый һәм җенси тигезлек өчен көрәшкән, кеше хокукларын яклаган социалист Бәһиҗә Боран бүген дә галимнәр һәм сәясәтчеләр тарафыннан даими искә алына, хезмәтләре буенча диссертацияләр, монографияләр языла. 2006 елда «Бәһиҗә Боран: соңгы сулышына кадәр» исемле документаль фильм төшерелде, Төркия иҗтимагый тарихын өйрәнү вакыфы (TÜSTAV) тарафыннан мәкаләләре, чыгышлары, әңгәмәләре, мәхкәмәләрдә сөйләгән сүзләре өч томлык китап рәвешендә нәшер ителде. Җәмгыять белеме өлкәсендә Төркиянең иң көчле аналитикларыннан берсе саналучы Бәһиҗә Боранның гыйльми хезмәтләре, экпедицияләрдә ясалган күзәтүләргә нигезләнгәнгә, бүген дә актуальлеген җуймый, ә фикердәшләре, көрәштәшләре аның якты истәлеген кадерләп саклый.

Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы,
профессор.
«Фәнни Татарстан»
журналыннан

Мәдәни җомга
7 июль
№26, 2023

Төрки әдәбият дөньясында азәрбайҗан шагыйре Әкбәр Кошалы исеме яхшы таныш. Ул озак еллар буе Төрки яшь язучыларының бөтендөнья шурасын җитәкләде, хәзер дә аның шәрәфле рәисе булып тора. Әкбәр әүвәл техник университет тәмамлаган, аннары Дәүләт идарәсе академиясендә икенче югары белемен алган. Ләкин шигъриятькә балачакта ук бөреләнгән мәхәббәте барыбер җиңеп чыккан, бүген аның чатыры түбәсендә, гасырлар җиленнән әсәренеп, шигырь әләме җилферди. Дөрес, мәртәбәле уку йортларында ирешкән белемнәре дә әрәмгә китмәгәндер, ул, Тукай әйтмешли, коеп куйган шагыйрь генә түгел, Азәрбайҗанда танылган җәмәгать эшлеклесе дә... Бүген ул Милли Мәҗлеснең Мәдәният комитетында эксперт булып эшли.

Шагыйрьләр өлкәнлек бусагасын атлагач, гадәттә прозага күчә. Әкбәр дә хикәяләр язу остасы. Аның хикәяләрендә кискен сюжеттан бигрәк психологизм, мистика гонсырлары өстенлек итә. Тиздән татар телендә бүгенге азәрбайҗан язучыларының «Хәзерге заман хикәяләре» антологиясе дөнья күрәчәк. Әкбәрнең шул китапка керәсе хикәясен сезгә дә тәкъдим итәбез.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА.

Әкбәр КОШАЛЫ

ИРАДА



Бары да көтелмәгәндә, ниндидер ыгы-зыгы арасында килеп чыкты. Әле хәзер дә, вакыт узуга карамастан, мин, киеренкелектән чыга алмыйча, кыенлык белән генә бу вакыйгаларны бөтен нечкәлекләре белән искә төшерергә маташам.

Дөньясына төкереп, бөтен эшләрне ташлап, Тәбризгә барып кайтырга булдым. Инде күп еллар анда булган юк иде. Бу баруга зур өметләр багладым. Минемчә, Тәбриз рухымны ныгытырга тиеш иде. Аракcның бу ягына мин яхшы кәеф белән кайтырмын, бөтен борчуларны Аракс аръягында калдырырмын, дип уйладым. Моңа ышанычым зур иде.

Чынлап та, андагы дуслар мине таможнядан каршылап, кая теләсәм шунда йөрттте, кирәкле кешеләр белән очраштырды. Барысы да кунакчыл, ачык йөзле, шат күңелле, җор иде. Бөтен сәфәр буе күңел күтәренкелеге хөкем сөрде.

Тик атналык сәфәрнең соңгы көнендә кинәт кенә дусларымның, алар моны миңа күрсәтмәскә бик тырышсалар да, кәефләре китқәнен тоеп алдым. Ниндидер борчылу хисе. Башка төрле уйлар килде, ләкин кире юлда, таможняда гына мин хәлнең бик куркыныч икәнен аңладым.

Кире кайтканда мин күп кенә үзгәрешләргә шаһит булдым. Ләкин бу үзгәрешләр минем өметләремә капма-каршы иде. Чикне үтеп чыгуга мине башкалар белән бергә Әстәр хастаханәсенә алдылар. Бөтенебезгә дә битлек кидерделәр. Һәрберебезнең башында җавапсыз сораулар өере. Һавада бер генә сүз эленеп тора: коронавирус, коронавирус. Дөресен генә әйткәндә, мин үземдә ниндидер авыру билгеләре тоймадым, сәламәт хис иттем. Ләкин мине хастаханәдән чыгармадылар. Табибләрдәге авыз-борынны каплап торган битлекләр кара чадраны хәтерләтә башлады. Дәүләт чигеннән тыш районара тикшерү пунктлары барлыкка килде.

Ярый ла, ул теге яктагы чиновниклар сиңа, таныш түгел кешегә, шикләнеп карый, ә монда танышның да, таныш түгелнең дә шулай ук еректан гына, ара саклап исәнләшүе ниндидер салкынлык тойгысы уята. Еш кына температура үлчәүче ак халатлы, кара битлекле табибләрнең сөйләшергә атлыгып тормавы бу тойгыны тагын да көчәйтә. Бәлки, бу миңа гына шулай тоелгандыр. Бәлки, тәкәббердерләрем, уңга да, сулга да үпкәм шулай җанымны талыйдыр? Бик мөмкин. Бәлки, кунакта, сәфәр вакытында ялгышлыклар җибәргәнмендер, бәлки югарыдагы кодрәтле көчләргә ошамаган сүзләр ычкындыргандырмын?! Бәлки, мине сихерләп бозганнардыр? Җитмәсә, туктаусыз телефон чылтырый, әйтерсең, бөтенесе дә шушы көнне көтеп торган. Кирәге дә, кирәкмәгәне дә.

Бу мәхшәрдә нәрсә эшләгәннәрдер, ләкин күпмедер вакыттан күпләрне чыгардылар, ә мине Бакуның махсус медицина үзәгенә җибәрделәр. Турысын гына әйткәндә, үземнең акрын гына хәлсезләнүемне тоеп тордым, ләкин моны коронавирустан түгел, ә арганлыктан диеп уйладым. Бар да без уйлаганча килеп чыкмый шул. Әстәрдән Бакуга барганда ук минем баш әйләнә, күз аллары караңгылана, бигрәк тә сулыш алуы кыенлаша башлады. Үземне тынычландырырга тырыштым – бу бары климат алыштырудан, йокысызлыктан, режим бозылудан... Ләкин тоеп торам – бу бөтенләй башка халәт. Бакуга килеп җиткәндә инде һава җитми, аң югала башлады. Кем әйтмешли, баш китте – «Син инде һавага аштыңмы, яисә әле җирдәме?» – дигән уй бимазалады. Тоям, миңа әле күпне күрергә туры киләчәк.

Томанда кебек кенә хәтерлим, кемдер паспортны карап: «Юлчы Кадерлене – доктор Ирада Кыяматдинлегә», – диде. Кемгә, кемгә? – Ирада Кыяматдинлегә?! Ходаем, үзең сакла! Бу кадәр туры килү мөмкин түгел. Анысы кебек сирәк фамилияне бүтән беркайда да ишеткәнем булмады. Кабатлап сорарга хәл юк. Хет егыл, хет үл. Бу хәлемдә Ирада белән очрашасым килми иде. Ләкин хәлем мөшкел. Хәлсезләнә барам, еш-еш сулыйм, туктаусыз йөткерәм, саташам да бугай. Монда инде шәхси ихтыярымнан берни дә тормый иде. Мине палатага кертеп салганнар.

Ярым ачык күз белән керфек арасыннан гына «скафандр» эченнән Ираданың минем баш өстендә нидер эшләгәнен күреп калдым. Ә мин табутка ошаган савыт эчендә ятам. Бу аңыма килү бары бер мизгел генә булды. Анысы өчен дә Ходайга рәхмәтлемен. Күп еллар көрешмәгәннән соң Ирада миңа гадәти авыруга караган кебек карый. Күрергә өлгермәдем – нәфрәт беләнме, яратыпмы, җәлләпме? Эх беләсе иде!

Бик гүзәл көннәр кичергән идек заманында Ирада белән. Ә аннары язмыш безне төрле якларга ташлады. Аның Төркиядә яшәвен белә идем. Ул анда табиб булып танылган, фәнни эш белән дә шөгыльләнгән. Һәм менә күп еллардан соң, Бакуның махсус үзәгендә очраштык. Ул – табиб, мин – авыру. Шунысы гаҗәп, теге елларда да шулай иде бит – мин аның белән авырый идем, аның пациенты идем. Ләкин бер зур аерма – ул вакытта мин бу Таҗлы бикәгә үлеп гашыйк идем, ә хәзер мин коронавирустан үлеп ятам.

Ирада, Ирада...

Бу аерылышу минем аркада булды. Тирә-юньдәгеләр безне гашыйклар дип саный һәм бу дөрес иде. Төннәрен аерым булсак та, бер түбә астында яшәмәсәк тә, туганнар булмасак та, бергә эшләмәсәк тә, без һәр иртәне бер төрле каршылый идек һәм мөмкин кадәр бергә булдык...

Көннәрдән беркөнне Ирада Төркиягә укырга барырга җыенуын әйтте. «Вай, ханым-әфәндем, каян килде сиңа мондый уй?» – дидем мин, көтелмәгәнлектән. Ул үзенең дәлилләрен китерде – белем баскычының югарырак этабына күтәрелү кирәклеген, ә иң яхшы университет Җараһпашада икәнен. «Бөтен отличниклар да шунда бара. Мин дә бит отличница» (мин һәрвакыт «тәзәтмә» кертә идем – син отличница түгел, син «отличная», бу юлы эндәшмәдем). «Җитмәсә әллә кая еракка китмим бит, үзебезнең Төркиягә генә».

Әйе, Төркиягә бару проблема түгел иде, ләкин ничек инде ул бу карарны миңа әйтми генә кабул иткән? Бигрәк тә иң ошамаганы – аның белән Төркиягә, бер үк шәһәргә, бер үк университетка группадаш егете баруы. Әллә мин Ирадага ышанмадыммы? Ышандым, билгеле. Ләкин һәрбер ирдә көнчелек хисе ята. Кемдә көчлерәк, кемдә азрак. Ә акылым да, хисем дә мин яраткан кызның мине озакка калдырып китүен кабул итә алмады. Димәк, ул миңа кияүгә чыгарга җыенмый. Ә нигә соң алайса күпме вакытлар без агылый белән тагылый булдык?!

Безнең сөйләшү эт эчәгесе кебек озын булды. Бер-бербезне бүлдерә-бүлдерә, йә ул, йә мин сөйләдек, бер-беребезне йөдәтеп бетердек. Акыл юкка чыкты. Ниндидер газаплану. Ул көннәрдә бер-беребезгә нинди аяусыз булдык! Аңлашу мөмкин түгел иде. Йә Алла! Күпме «аргументлар» өскә калыкты. Кире чигенүгә урын калмады. Моңа берьюлы ике сәбәп булды. Беренчесе – Ирада белән укыган егет һәм минем көнчелегем булса, икенчесе – минем тормышыма кинәт кенә килеп кергән Ирада белән укыган кыз. Элек мин бөтенләй игътибар итмәгән кыз соңгы көннәрдә нык үзгәрде, карашында мутлык барлыкка килде. Ни булды? Моңарчы минем күзләр Ирададан башка берәүне дә күрми иде бит. Бу кыз элек тә чибәр булгандыр, мин генә күрмәгәнмендер. Ниндидер шашкын «бию» үзенә иртте. Мөнәсәбәтләрнең «квант физикасы». Якынлашу, ераклашу, сөешү, читләшү. Әйтерсең, бер чор бетеп, икенчесе башлана. Һәм ябылу ноктасы ачылу ноктасына әйләнә.

«Ах бу озын сөю юлы,
Баралырмы ахыргача күңел?»

Йә Алла! Чынлап та бик нык, дип санаган мәхәббәтебез кирмәне җимерелер микәнни? Алай мөмкинме? Шулай кинәт генә аерылырбызмы? Ә башкалар бу очракта нишләгән? Белмим. Мондый очракка эләккәнем булмады. Аерылышып карарга да, шөкер, туры килмәде. Бу ачы хакыйкать, бу чынбарлык.

Ә Ирада, минем аның толымнарын ятарауымны белә торып, чәчен кистерде.

Гардеробындагы бөтен кызыл төстәге киемнәрен, аксесуарларын (миңа үч итеп?) төрле төстәге, чуар күлмәкләргә алыштырды. Мин әчтән генә «Теләсәң ни эшлә, миңа барыбер», дип йөрдем.

Ә аннары инде безнең тәкәбберлек бер-беребезне эзләргә мөмкинлек бирмәде. Кем әйтмешли, йөрелмәгән сукмакка мүк үсә. Халык дөрес әйткән, күздән ерагайган җаннан да ерагая... Ә аннары күпме сулар акты, күпме болытлар агылды. Ул арада минем бер сабакташ кыз белән кыланган кыланышлар нәтиҗәсе булып бер кечкенә кыз туды. Ләкин ул туганчы ук аның әнисе белән безнең ара бозылган иде инде. Аннан соң килгән хәбәр миңа яшен суккандай тәэсир итте – әнисе кызына Ирада дип исем кушкан! Моны бөтенләй аңламадым. Нәрсә өчен, ни өчен?! Нәрсә бу? Шәфкатьме, мәрхәмәтме, газапмы, янумы, танумы? Чишеп кара син бу серне.

Ираданың берничә елдан Төркиянең табибләр төркеме белән республикага кайтуы ковидка каршы көрәш чараларына бәйләнгән иде. Эпидемияне җиңгәннән соң ул кире китәргә тиеш.

Беләсе иде, кияүгә чыкты микән?...

Чәчләре озын (миңа ошаганча), үзе ап-ак. Бөтен рәвеше белән әйтә кебек «Мин ай түгел, мин йолдыз, хатын түгел – мин бит кыз». Үзен тотуы да бик сөйкемле.

(Дәвамы киләсе санда.)

Корбан бирү йоласы

Нурихан ФӘТТАХ

Корбан бирү йоласы барлык йолалардан да борынгырак. Корбан бирүнең төрләре бик күп. Ыру, кабилә, халык тарафыннан күмәк рәвештә корбан бирү йоласы елның билгеле бер вакытында гына, билгеле бер урында гына башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аерым гаилә яисә аерым бер кеше тарафыннан бирелә торган корбаннар да була. Кайбер төр корбаннар көн саен бирелә, кайберләре көненә берничә мәртәбә бирелә ала. Мәсәлән, борынгы Мисырда кояшка көненә өч мәртәбә төтен корбаны биргәннәр: кояш чыкканда сумала яндырганнар, көн уртасында мирра, кояш баеганда – куфа яндырганнар.

● Биләрдәге изге таш.

Корбан Җир, Су, Күк аллаларына, айга, кояшка, утка, тауга, ташка, агачка һ.б. күп төрле ияләргә багышлап бирелә. Монотеистик дин тотучылар (мәсәлән, мөселманнар) Аллага, пәйгамбәрләргә, изгеләргә атап корбан бирә.

Корбанга барлык җанлы-җансыз бирелә дип әйтергә була. Ләкин бу гомумән әйткәндә генә шулай. Корбан таләп итүче аллалар, ияләр шактый талымчан һәм нәзберек. Гадәттә һәрбер алланың, һәрбер иянең «яраткан» корбаны була. Корбан бирү йоласы башкарганда һичшиксез аларның шул «яратканнарын» бирергә кирәк. Ләкин бер үк аллага, бер үк иягә төрле халыкта, төрле кабиләдә төрлечәрәк корбан бирелергә мөмкин.

Мәсәлән, кояшка ат, үгез, куй сыман итлерәк, туклыклырак корбаннар бирелә. Ләкин бер халыкта кояшка бары атны корбан итеп бирүне генә дөрес дип, ә икенче бер халыкта үгез яисә куй бирүне генә дөрес дип санарга мөмкиннәр. Массагетлар, Спарта кешеләре, борынгы фарсылар кояшка корбан итеп ат бирә. Борынгы кытайлар кояшка – үгез, айга – тәкә (куй) яисә кабан дуңгызы корбан итә. Борынгы Мисырның Фива шәһәре кешеләре Кояш алласы Амонга багышлап елына бер мәртәбә куй корбан итә.

Җир, Су, Күк аллаларына бирелә торган корбаннар да төрле халыкта, төрле төбәктә төрлечә булырга мөмкин. Сөннәр 5 нче айда Лунчэнда зур җыенга җыела, ата-бабага, Күккә, Җиргә, әрвахларга һәм күк ияләренә багышлап корбан бирәләр. Алтай төрекләре каганы һәр елны бишенче ай уртасында, башкаларны үз янына җыеп, елга буенда күк ияләренә корбан бирә. Борынгы кытайлар б.э.к. VIII гасырда Олуг хакимгә (ягъни Күккә) кара яллы өч җирән колын, өч коба үгез бозау, өч куй бирә.

Утка корбан көн саен һәм әледән-әле бирелә. Тувада утка багышлап пешерелгән коба кәҗә тәкәсен (серкә) корбан итәләр. Төркиядәге йөрүкләрнең кара-кечили кабиләсендә учакта ут тергезгән саен, бер кашык май утка корбан итеп бирелә. Алтайлылар һәм телеутлар ашар алдыннан утка азыктан өлеш чыгара. Алтайлыларда утның иң яраткан корбаны – җылкы мае, аракы һәм чәй карасы, телеутларда – чиста май, аракы, кайчагында сөт дип исәпләнелә.

Төньяк Америкадагы гуроннар утка корбан итеп тәмәке ташлый һәм башларын югары күтәреп: «Аронгиатэ (Күк), кара әнә мин биргән корбанга, кызган мине, ярдәмеңнән ташлама!» – диләр. Төньяк Америкадагы алгонкиннар бәйрәм вакытында азыкның беренче кабымын утка ташлый. Якутлар беренче кашык ашны (ботканы һ.б. азыкны) утка бирә. Ашаганнан калган азыкны да утка ташлый.

Изге саналган тауларга корбан бирү дә киң таралган. Тувада тува-кыргызлар Бурун-Хан дигән тауны изге саный. Ашарга утырган саен, ашар алдыннан һәр гаилә кешеләре тау ягына азык кисәкләре ташлый, чәй сибә һәм: «Ашаганда, йоклаганда шәфкатеңнән ташлама, Бурун-Хан!» – дигән келәү сүзләре әйтә. Монголлар тау башларына, тау сыртларына тау иясенә багышлап таш өемнәре өя. Ул обо дип атала. Шундый оболар яныннан үткәндә, тау иясенә корбан рәвешендә әлеге өемгә берәр таш, чүпрәк-чапрак яисә берәр уч дөя йоны ташлап китәләр.

Җиргә атап бирелә торган корбанны гадәттә җиргә күмәләр. Мәсәлән, Төньяк Америка кабиләләрендә шулай эшләнелә. Агым суларга, күлләргә, чишмәләргә дә корбан бирелә. Шри-Ланкада, Һиндстанда суга корбан бирү киң таралган. Борынгы заманнарда суга корбан итеп кеше бирү гадәте дә булган. Татарда кайбер чишмәләр, күлләр изге санала. Суга гадәттә көмеш акча ташлыйлар. Майалар Яңгыр һәм Су алласы Чакага корбан итеп, Чичен-Ица коесына кешеләр һәм төрле әйберләр ташлый торган булган. Татарстанда корылык килгән елны «яңгыр боткасы» пешерү һәм кешеләрне елгага төртеп төшерү гадәте дә менә шул суга корбан бирүнең бер калдыгы булып тора.

Борынгы халыкларда аллаларга һәм ияләргә корбан итеп кеше бирү шактый киң таралган булган. Әле генә без шуларның кайберләре белән таныштык. Гадәттә коллар яисә сугышта әсир төшкән ирләр корбан итеп бирелгән. Мәсәлән, скифлар сугышта әсир төшкән ирләрнең йөздән берен корбан иткән.

КОРБАН БИРҮНЕҢ МӘГЪНӘСЕ

Корбан бирүнең мәгънәсе беркемгә сер түгел. Корбан бирүче һәркем үзе биргән корбан бәрабәренә нәрсәдер алырмын дип өмет итә, Аллага ышанучы кеше аңа багышлап берәр терлеген чала икән, ул Алладан шәфкать көтә. Әйтик, авыру кеше чирдән терелүне өмет итеп ут иясенә, тау иясенә корбан бирә икән, аның нәрсә теләве үзеннән-үзе аңлашыла: тиешле корбанын алгач та, ут иясеме, тау иясеме авыру кешене борчымаска, ягъни кеше сәламәтләнергә тиеш. Корылык килгән елны кешеләр яңгыр боткасы пешереп корбан чала икән, моның да мәгънәсе бик ачык: бирелгән корбан бәрабәренә күктән яңгыр таләп ителә.

Шул рәвешчә, кеше күзгә күренмәгән, ләкин һәрвакыт кайдадыр якында гына сыман тоелган көчле, куркыныч, кодрәтле җан ияләренә ашарга биреп, шуның өчен үзенә иминлек, саулык, тынычлык һәм муллык алырга тели. Корбан бирү йоласының төп мәгънәсе менә шуңа кайтып кала.

Тик шулай да «Кеше нигә адым саен, теләсә кемгә шул кадәр күп корбан бирә соң?» – дигән сорау куйсак, моңа гади генә итеп: курыккан өчен, дип әйтергә туры килер иде.

Кешенең үлемнән, тәмугтан куркуы болай да аңлашыла кебек. Ләкин кеше җирдәге, судагы, күктәге һәр нәрсәдән курка. Кеше кинәт чыккан кара болыттан курка, коеп яуган яңгырдан курка, яшеннән, күк күкрәвеннән курка, моржа башында җил сызгыруыннан, ерткыч хайваннардан, сәеррәк тоелган ташлардан, агачлардан, тирән судан курка. Барыннан да бигрәк ул караңгылыктан курка. Без монда шуны да искә төшерә алабыз: караңгыдан аеруча балалар курка. Димәк, караңгыдан курку кешедә «генетик» куркуга әйләнгән.

Корбан бирү йоласы турында сөйләгәндә гадәттә шундыйрак аңлатма бирелә: борынгы заманда кеше табигать серләрен белмәгән. Шунлыктан ул табигатьтәге барлык җансыз нәрсәне җанлы дип уйлаган. Табигатьтәге барлык нәрсә җанлы булгач, кешегә адым саен аны дошманнар сагалап торган шикелле тоелган. Бу дөрес фикер, әлбәттә. Ләкин шулай да бу бик үк дөрес тә түгел. Куркуның һәм шул нигездә барлыкка килгән корбан бирү йоласының иң беренче сәбәпләрен аңлау өчен, безгә моннан берничә миллион ел элекке кыргый хайваннар дөньясына борылып карарга туры килә.

Маймул-кеше яисә кыргый кеше, яшәү өчен, исән калу өчен, үзен төрле яктан чолгап алган ерткыч хайваннар белән берөзлексез көрәш алып барган. Маймул төнне агач башында йоклап уздыра, көндез активлаша. Аның дошманнарының күбесе, киресенчә, көндез йоклый, төнлә активлаша. Маймул өчен иң хәтәре, иң куркынычы менә шул төнге йоку булган да инде. Төнлә сиздермичә генә агач башына шуышып менгән дошман маймул төркеменнән берәрсен эләктереп алган да, шуның белән канәгатьләнгән. Төнге югалту маймул яисә маймул-кеше төркемендә, әлбәттә, шау-шу, ыгы-зыгы куптарган һәм менә шундый югалтулар, шау-шулар маймул-кешеләрдә, исән калган маймулларда чиксез курку һәм кайгы-хәсрәт тудырган.

Икенче бер очракта, әйтик көн яктысында маймул яисә маймул-кеше төркеменә икенче бер дошман һөҗүм иткән һәм гамьсезрәк яки авыру, карт, гарип берәрсен эләктереп алып киткән. Бер корбанын эләктерү белән көндезге дошман да башкаларны эзәрлекләп тормаган. Төркемнең бер вәкилен югалту бәрабәренә бөтен төркем исән калган.

Шул рәвешчә маймулны яисә маймул-кешене төнлә дә, көндез дә адым саен үлем сагалап торган. Ләкин кайбер очракта маймул яисә маймул-кеше төркеме, үзеннән көчлерәк, куркынычрак дошманыннан котылу өчен, үзе теләп төркемнең, гаиләнең берәр вәкилен ташлап киткән булырга да мөмкин. Иң беренче корбан бирү шул рәвешчә барлыкка килгән.

Ләкин кыргый кеше (иң беренче кеше) үзен эзәрлекләүче дошманыннан һәрвакытта да корбан биреп качу белән генә котылгандыр дип әйтеп булмый. Бер очракта ул корбан биреп котылса, икенче бер очракта, кулына таш, таяк күтәреп, дошманына каршылык күрсәткән һәм аны чигенергә мәҗбүр иткән. Һәм, шулай итеп, каршылык күрсәтү йоласы барлыкка килгән.

Кешенең барлык йолалары бер-берсенә капма-каршы эчтәлектәге ике төргә бүленә: аның берсе корбан бирү булса, икенчесе каршылык күрсәтү. Бу йолаларның икесе дә кешенең үлем авызына эләкмичә, исән калуын тәэмин итәргә тиеш булган.

ДИМ БУЙЛАРЫ СИНЕ ЮКСЫНА

(Татарстанның халык артисты Тәслимә Мөхетдинованың тууына 70 ел)

Башкортстанның данлыклы Бишбүләк якларында заманында бөтен дөньяны шаулаткан дипломат Кәрим Хәкимов туган, гүзәл Дим елгасы ярларына сыенып утырган Дүсән дигән татар авылы бар. Тәслимә Мөхетдинованың да кендек каны шушы изге җирдә тамган. Ул авылда мин дә күп тапкырлар булдым. Шулай, җәйнең матур бер мәлендә, Тәслимәнең туган йорт-ихатасында үскән бәбкә үләннәреннән дә атларга насыйп булды. Бирендә аның балачак, яшьлек эзләре сеңеп калган...

Ни күрим:Тәслимә әнә шул бәбкә үләннәре өстенә әнкәе — Нәсимә апаның, күз явын алырлык матур паласларын җәеп куйган иде. Янәшәдә самавыр «җырлап» утыра. Ара-тирә кошлар сайравы да әкияти, сихри дөньяны хәтерләтте. Әнкәсе пешергән, күпереп торган калачы, кыстыбый, коймагы, башка ризыклар Казан кызына бик тансык иде. Билгеле, тәмле чәй янында хәтер йомгагы да сүтелә. Нәсимә апа заманында озак еллар колхоз эшчеләренә икмәк пешергән, хуҗалык сыерларын да сауган. Төннәрен бизәкле паласлар тукыган, алар төрле күргәзмәләрдә үз бәясен алган. Тормыш иптәше Хәләф ага данлыклы «Марс» колхозының механигы вазыйфасын башкарган. Тик аның гомере кыска була. Сугышта, Курск дугасында авыр контузия алу нәтиҗәсендә, ул 41 яшендә дөнья куя. Шунысы шатлыклы: әткәй-әнкәй йорты бүген ятимсерәп утырмый, биредә төпчек уллары Рузат гаиләсе белән мул тормышта яши.

Туган-үскән җирләрен һәрдаим юксынып яшәгән Тәслимә Мөхетдинова (Фәйзуллина) һәр елның җәйге айларында үзенең Дүсәненә Казан тарафларыннан очар коштай сагынып кайта иде. Ни үкенеч, Тәслимә нибары 65 яшендә, моннан 5 ел элек, каты авырудан соң бакыйлыкка күчте. Ярый әле Казанда инженер-программист булып эшләгән улы Булат (5 бала атасы) әнкәсенең каберенә гаиләсе белән эзләрен суытмый. Шунысы гына аяныч: Тәслимәбез яраткан онныкларын тезләрендә сикертеп, озын-озак сөя алмады...

Тәслимә заманында Уфада сәнгать училищесын тәмамлаган һәм беренче иҗади чирканчыкны Салават театры сәхнәсендә алган. Анда биш ел дәвамында күп кенә төп рольләрне башкарып, шатлыклы мизгелләр кичерә, якты йолдыз булып балкый. Тәслимәнең тәүге уңышлары чит илгә бару өчен туристик юллама белән бәһаләнә. Ә 1976 елда Салават драма театры артистлары труппасы белән ул Казан каласына гастрольгә килә. Монда яшь актриса Кришна Чандраның «Бер кыз һәм мең гашыйк» спектаклендә төп роль – чегән Лачины башкарып, Татарстан тамашачыларының мәхәббәтен яулый. Гастрольләрдән кайткач, Казандагы ихлас алкышлар аның күз алдыннан китми. Шуңа борынгы шәһри Казанга тартыла.

1977 елдан Тәслимә Хәләф кызы язмышын Казан белән бәйли, үзен олы иҗат мәйданында сынып. Башта ул Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы, бер үк вакытта Казан театр училищесында, мәдәният һәм сәнгать университетында актерлык осталыгы буенча режиссер-педагог булып эшли.

Ә шулай да Тәслимәнең тормышы күбрәк сәхнә белән бәйле. Өч дистә елдан артык ул күңелләргә кереп калырлык искиткеч образлар иҗат итә, сәхнәне балкыта. «Без бит авыл малайлары»нда – Мәүлия, «Сөяркә»дә – Тәслимә, «Элмәктәге язмыш»та – Зөлфия, «Сихерче»дә – Сәвия, «Язмышлар ярында» – Дамирә рольләре Тәслимәгә уңыш китерә. Монда актриса үзенчә эшләп, бай фантазиясен эшкә җигеп, профессиональлекнең биек үрләрен яулауга ирешә. Әйтик, Фәнәвил Галиевнең «Элмәктәге язмыш» пьесасында Зөлфиянең трагик язмышын, аның эчке кичерешләрен тамашачыга ихлас җиткерә алганы, актерлык осталыгы өчен аңа «Татарстанның атказанган артисткасы» дигән мактаулы исем бирелә.

Сәхнә – Тәслимә Хәләф кызы өчен җансыз тормыш түгел, ә сихри дөнья. Ул сәхнә тормышыннан ләззәт ала, шатлыклы мизгелләр кичерә, сәнгать сөючеләргә күңелле ял сәгатьләре өләшә. Алда әйтүемчә, Тәслимә Хәләф кызы артистка гына түгел, тәҗрибәле педагог буларак та билгеле. Күп еллар дәвамында актерлык осталыгына өйрәтү барышында шактый сәләтле белгечләрне әзерләүдә һәм олы сәхнәгә чыгаруда зур көч салды. Ул исә Резеда Шәрәфиева, Равил Галиев, Гөлчәчәк һәм Ирек Хафизовлар, Зөлфия Вәлиева, Гүзәл Гайнуллина, Фирнат Нәсибуллин, Алмаз Фаткуллин, Харис Төхвәтуллин һ.б. белән хаклы горурланды. Тәҗрибәле педагог аларның сәхнәгә булган олы мәхәббәте, өметле киләчәге барлыгын тоеп яшәде, кайчакта борчылып та куя торган булды. Ә инде премьераларына барса, аларның уңышларына сөенеп, хәтта канатланып, рухи көч, ләззәт алып кайта. Күңелендәге кичерешләр, сөенечле мизгелләр педагогка тагын дәртләнеп эшләргә канат куя. Укытучы һәр биргән дәресеннән канәгатьләнү алырга тиештер. Шәкертләренең йөрәгенә, бөтен энергиянне биргәндә генә чын педагог була аласың. Тәслимә Хәләф кызы да шулай фараз итте. Янында терәгең булырлык коллегалар – театрның баш режиссеры Рәшит Заһидуллин, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин кебек шәхесләр белән эшләве аңа сөенечле була.

Тәслимә өчен сәхнә дә, укытучылык хезмәте дә – бер-берсеннән аерылгысыз иҗади эш. Шуңа икесе дә аның өчен кадерле тоела. Сәхнәдә берничә сәгатькә булса да чынбарлыктан, тормыш-көнкүреш ваклыкларыннан ары-



нып, ниндидер биеклеккә күтәрелүен дә, җирдә тоеп булмаган хисләр кичерүен дә яшермәде ул. Дөрестән дә, моның нәрсә икәнен сәхнә тормышын төптән, тирән белгән, аның тәмен тоеп караган артист кына беләдер.

Татар-башкорт сәнгать дөньясында Тәслимә Хәләф эзләнүчән, оста режиссер буларак та танылырга өлгерде. Тәслимә башлыча Нәбирә Гыйматдинова әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Райондашым Тәслимә танылган әдибәнең иҗатын да, Нәбирәнең үзен дә тормышының рухи матурлыгы дип кабул итә. Үз чиратында йөгерек телле Нәбирә Гыйматдинова иҗатташ дусты Тәслимә хакында кайчандыр болай дип язып чыккан иде: «Аның белән теләсә кем дуслаша алмыйдыр. Моның өчен ул күтәрелгән биеклекне чамаларга һәм үзең дә шул биеклектә торып калырга кирәктер. Рухына бөтенләй ят кешеләр белән бик аралашырга яратмый бугай ул. Бу затның холкын нинди сүзләр белән билгеләп була? Гаҗәеп дәрәҗәдә сизгер күңелле, кырыс, ләкин ягымлы, ялган-хәйләләрне белми, ясалмалылыкны сөйми, эчкерсез, гадел, нәзакатьле, горур, аз гына тәкәббер һәм, әлбәттә инде, сөйкемле...Театр белән сәхнәне яшәүнең төп мәгънәсе дип саный. Иҗат бәхетен, иҗат ләззәтен бернинди дан-шөһрәткә дә, мал-мөлкәткә дә алыштырмас. Менә шундый кеше ул Тәслимә Хәләф».

Режиссерлык өлкәсенә килгәндә, Тәслимә Хәләфнең әлеге эшчәнлеге Н.Гыйматдинованың «Сихерче», «Ак болытлар иле», «Гөнаһ тажы», «Сер», «Бер тамчы ярату», «Утка очкан күбәләктәй» повестьләренә язылган инсценировкалары белән бәйле. Исән булса, якташым җан авазы, йөрәк каным белән язылган «Әтидәме икән гаеп?» исемле повесть-хатирәгә күңелне тетрәтерлек инсценировка да язган булыр иде, мөгаен.

Шунысы куанычлы: остә аталган «Утка очкан күбәләктәй» исемле сәхнә әсәре 2004 елның язында Г.Камал театры һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» конкурсында «Иң яхшы инсценировка» номинациясе буенча беренче премиягә лаек була. Конкурста 110 пьесаның кабул ителүен искә алганда, бу олы җиңү бит!

Тетрәндергеч язмышларга дучар булып, иҗат ялкынында дөрләгән кеше моңсыз булмыйдыр ул. Тәслимәне җыр-моң балачактан ук озата килә. Тәҗрибәле актриса һәм педагог үзе дә җыр текстлары яза. Гадәттә, иҗат әһелләре иң элек туган-үскән җиренә, әткәй-әнкәйләргә, сөйгән ярларга багышлап нәрсәдер иҗат итә. Мондый «чир» Тәслимә Хәләфне дә урап үтми. Аның сүзләренә язылган «Әй, Дүсән», «Сагынырсың әле Дим ярларын», «Мин яраттым сине», «Яраларың белән яратырмын», «Ал сөюне жаннан, ак болыт!», «Соңгы сөюдер бу», «Сихри мизгел» һ.б. җырлар еллар үтү белән популярлашып китә. Туган авылына багышлап язган «Әй, Дүсән» җырының текстында күңелгә якын юллар бар:

... Китмәскә дип мин дә бер
кайтырмын,
Гел киттем бит синнән, югыйсә.
Бакча башындагы бер каенның
Чакырып алып:«Инде кал», дисә.
Җаннан җуелмаслык хатирәдер,
Ялгыз әнкәй иле, әй, Дүсән.

Күлгә аккош инде төшә микән?
Бәгырьләрен сагыш кисә микән?
Хушлашулар иле, әй, Дүсән...

Әйе, туган-үскән җирләргә кайтып, әнкәй кояштәрен асып йөргән, челтерәп аккан чишмәләрнең шифалы суын уртлавы, Димдә су коену, өзелеп сайраган кошлар җырын тыңлап әсәрләнү, мәтрүшкәләр исеннән хисләнеп туган як болыннарын гизгән чаклар Казанына кайткач та күңеленнән китми. Туганнары сөйләве буенча, 1987 елның ямьле җәендә Тәслимә туган авылына Тинчурин исемендәге театрда бергә эшләгән артистларын да алып кайткан икән. Алар, «Ак күгәрченнәр» спектаклен күрсәтеп, авыл халкын сөендергән. Биредә сәхнә легендасы Хәния Фәрхи дә була. Аңа биредәге кунакчыл халык, хозур Дим буйлары бик тә ошый. Алар күңелләре булганчы җырлап-биегән, таң аттырган. Хәния, гармун телләрен моңга «манып», авылча, озын көйләрне сыздырган. Бормалы Дим сулары бүген дә ярларына тулышып, вакыт-вакыт дулкынланып, ярсып ага. Ни үкенеч, халык артистлары Хәниянең дә, Тәслимәнең дә гомерләре нишләптер гармун күрекләре кебек озын-озак сузылмады шул...

Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ.

ГҮЗӘЛ АВЫЛЫМ БАЙСАР

(Тарихи китаптан өзекләр)

НИГЕЗЛӘНҮ ЕЛЛАРЫ

Сүзне данлыклы авылга исем биргән морза Байсар Күзәшевтан башлыйк. 1653 елның 5 мартында Уфа воеводасы Иван Франзбековка язган үтенеч хатында иң тәүдә Кыргыз, аннары Бүләр волосте составында йөргән Бүләр (Байсар авылының тәүге исеме) авылында гомер итүче ясаклы «башкорт» Байсар үзен 80 яшьлек карт дип күрсәтә. 1653 елдан 80 не алсак, Байсар 1573 елда туган булып чыга. Бүләр авылы фәкать ул вафат булганнан соң, XVIII гасырда гына Байсар исемен ала. Ә Бүләр авылына вотчинаны саклау грамотасын Байсарның бабасы Күккүз-Күгәй-Күзәш би 1586 елда алып бирә. Грамоталарда Күзәш морзаның ясакны 1573 елдан бирле Уфа һәм Казан калаларына түләп баруы да бәян ителә. Димәк ки, Бүләр авылының 1573 елдан 15-20 ел элегрәк нигезләнгән булуы да мөмкин. Чөнки хәтта әле 1816 елгы җанисәп тә Байсар авылының 11 йортында гына Бүләр волосте вотчинниклары яшәвен ачыклый, ә 69 йортта Йәнәй волостеннан килгән «башкорт» типтәрләре «канат җәеп» ята. Йәнәйлеләрнең әүвәл Шәбез елгасы ярындагы Әҗби авылында нигез корып, аннары гына Байсар-Бүләргә күченүе турында да хәбәр бар. Бар мәгълүматны да бергә җыйсак, Бүләр авылы 1550 яки 1560 елларда ук тамыр җибәрә, ә Байсар исеме белән XVIII гасырда таныла.

Башкортстан галиме Әнвәр Әсфәндияров ни өчендер Кыргыз волостена һәм андагы авылларга тиешле вотчинная грамотаны Күккүз бинең игезәк уллары Кылчан белән Тонуз (Тәнеч) бары тик 1632 елда гына алуга ирешә, дип бара. Әмма 1632 елгы грамота 1613 елда Михаил Романовны патша итеп утыртканнан соң, кыргызлылар тарафыннан яңа хакимдардан яңартып алынган икенче грамота бит ул! Ә Уфа провинциясе карамагында булган һәм Сөн белән Ык елгаларының ике як ярлары буенча сузылып урнашкан барча «башкорт» волостьларының 1620 елга кадәр үк үз җирләре өчен вотчина грамоталары алып бетерүе билгеле, моны башкорт галимнәре дә раслый. Өстәвенә, Карабәк-Габдулла хан нәселенә кагылышлы шәҗәрәдә Байсар авылына һәм Кыргыз волостена тәүге вотчина грамотасын Күгәй-Күзәш алып бирә, дип ачыктан-ачык языла. Карабәк шәҗәрәсенең 30 варианты Уфа архивларында да тупланган, Ә.Әсфәндияров «шәкертләре» шуны ачып та моңа инана ала.

Кыргыз волостеның чикләрен күзаллау һәм волость крестьяннарының 1653 елгы дәгъвасы урынлы икәнлеген раслау өчен, без сезнең игътибарга 1632 елда Уфа воеводасы кенәз М.Ю.Трубецкой тарафыннан Кылчан Күккүз би улы аша Кыргыз волостена бирелгән грамотаның эчтәлеген тәкъдим итәбез. Ә волость чикләре 1604 елда ук ачыкланган була.

«Дали... грамоту башкирцам Уфимского уезда Киргизской волости деревни Старый Киргиз Кулчанке Куккузеву с товарищи на землю, на сенные покосы, озера, истоки и на лес и вотчину и на всякие угодьи и на бортной ухожий для того в нынешнем во РМ (140) году били челом они Кулчанка с товарыщи: доносят, что дедам и отцам их по грамоте в Уфимском уезде в Киргизской волости (даны во владение) пашни и сенные покосы и всякие угодьи и бортные ухожьи и (за это) платят де они с той вотчины и со всех угодьев в казну ясаку 82 куницы, кроме медвяного с бортных ухожей, озера, истоки и всякие угодьи Киргизской волости д. Старый Киргиз з башкирцами Чегиром Кулчановым с товарыщи, всего 15 человекам, по разделу отцовскому владеть по межам: по течению Белой реки по правую сторону от деревни Старый Киргиз чрез реку Белую на устье речки Маништы и вверх с той речки по правую сторону до Мяны Буруны по степям и до устья Кичю и чрез речку Кичю по лугам Базыев вверх по тому логу чрез речку Ляязды (?) по степи ж до речки Чекурчи и вверх по той речки по правую сторону речки Маты, а по речке Мате по обе стороны до вершины по течению той речки... сторону...ману и по течению Писаману по правую сторону к деревне Малой Маты чрез Мату до устья речки Балчиклы и до вершины Телгазы и вниз по течению по обе стороны до речки Тигану (?) и по той р. Тигану до вершины, идучи к верху по правую сторону чрез лес Куза по горе до вершины Суходолу, а с вершины и до устья того же долу по склонам ево по правую сторону до речки Зюни (Сюнь) и по Зюне вверх по течению левой стороны до устья Зарзасу (Сарсаз?) и вверх по той речки до вершины по течению правой стороны, от вершины Зорсас до вершины речки Сагыны и по течению оной по правую сторону до речки Узянь, а по Узеню до реки Ик, чрез Ик реку до речки Кривой Туб и вверх по речке Ику половина левой стороны до устья речки Ютазы и чрез Ютазу до устья речки Дымской и чрез устья речки Дымской до той прямо Маклаку по бугру до вершины речки Клану (?) и до вершины речки Бавлы, а от вершины Бавлы до устья речки Нижний Усоюрт и вверх и до вершины речки Дымской, от вершины Дымской до вершины речки Степнаго Заю и по Заю до речки Зирыклы чрез речку Лесной Заи до устья речки Имашу до вершины речки Ютазы, до истоку Кугует (Кичуй?) до Каптубы чрез Ик до Каинлы…»

(Әлеге грамота тексты тарих фәннәре кандидаты Таһир Кәримовның «Ябалак авылы» атлы язмасыннан алынды).

«Сары, Сарый» аты борынгы төрки телдә «бәхет» дигән мәгънәне аңлаткан, авыл исеменең хуҗасы Байсарга да этисе Тәнеч һәм бабасы Күккүз-Күзәш бәхет теләп кушкан. Тарихына керик.

Байсарның берничә буын түбәндәге бабасы Коркыт би, 1382 елда Карабәк-Габдулла ханга ияреп, Кавказ тавы итәгеннән күчеп килә. Алтын Урда таждары Туктамыш хан фәрманы буенча, Карабәк әүвәл Кырым ярымутравындагы Гәрәйләр кабиләсеннән берничә мең арбага тезелгән татар гаиләләрен алып кузгала, аннары Кавказ итәгеннән, Идел, Җаек, Сакмар елгалары тамагыннан татар, угыз, кыргыз, казах, кыпчак вәкилләрен җыя-җыя, үз кәрванын 17 мең арбага тутыра һәм ахыргы нокта – элеккеге Болгар ханлыгы җирләренә килеп төпләнә. Гәрчә үзен Бохара тарафында туган кыргыз (казах), дип күрсәтсә дә, Коркыт би күчеп йөри-йөри Иделне кичкән, аннары Хәзәр (Каспий) белән Кара диңгез арасында гомер иткән була һәм Карабәк кәрванына шул төбәктә кушыла. Коркыт бинең Әхмәт би һәм Мөхәммәт би атлы малайлары туа. Мөхәммәт нәселен Җәнәй би (әлеге исем «Йәнәй» рәвешен алып, олы бер олыс атына әверелә), аннан соң Кушык би дәвам итә. Кушык би әүвәл Агыйделдән ерак булмаган Тәтеш күле буенда (бүгенге Тәтешле районында) гомер итә, аннары Сөн елгасы ярына Кыргыз авылын төзеп утыра. Аның уллары Аккуш белән Күккүз дә шул тирәдә яши (Өгерҗе районында элек Татар Күккүзе атлы авыл да булган, юкка чыккан инде). Күккүз нәселен дәвам итеп, дөньяга Кылчан һәм Тәнеч атлы игезәкләр туа. Тәнечтән Байсар атлы угыл пәйда була. Ә бу төбәкне үз итеп яши-яши, Коркыт би дәвамчылары кыргыз-казахларның үзләре өчен якын булган Текәй һәм Кадыкай ыруларын да онытмый, бераздан безнең туфракта да Төкәй һәм Кәзкәй авыллары үсеп чыга. Байсарның этисе Тәнеч элек Йәнәй волостеның, бүген Өгерҗе районының бер почмагына әверелгән Тугыз-буй түбәсенә хуҗа булып ала. Мазар һәм Көтмәс елгалары буенда 1600 елларда Мазарасты-Дивәтирнә (1622 елда нигезләнгән), Нарат, Касай, Үтәгән, Кодаш, Исәнбай, Эсләк (соңгы ике авыл вәкилләре Башкортстанның Яңавыл, Илеш, Әлшәй районнарында да шундый ук исемдәге яңа авыллар нигезли), Кадыбаш атлы авыллар үсеп чыга. 1810 еллар тирәсендә Үтәгән авылы «вотчинниклары» Байсарның күршесе-иярчене булган Мәчти авылыннан да 9 ирне үз җирләренә төпләнергә кертә, алар анда Яңа Мәчти авылын нигезли, әмма 1842 елда юкка чыга («Аулы...», 42 б.).

● **Иске Байсар авылында революциягә кадәр үк төзелгән 4 мәчетнең берсе – Ак мәчет.**

Менә шушы Коркыт би нәселеннән Кыргыз авылында «башкорт вотчиннигы» булып гомер итүче Күккүз би үз кул астына кергән волость авыллары өчен 1586 елда ук Уфадан «жалованная грамота» алып кайта. 1604 елда Кыргыз волостеның чикләрен яңадан билгеләп, межалау үткәрәләр. Күккүз би 1630-1632 елларда үз улы Байсар морзаны Кыргыз волостеның баш старшинасы итеп раслатуга да ирешә. Ә Байсар инде күптән Сөн буендагы Бүләр авылында гомер итә, волость башлыгы вазыйфаларыннан бушагач, авыл старшинасына әверелә. Байсар старшина вафатыннан соң Бүләр авылы үз исемен Байсарга яңарткач, ул Кыргыз олысындагы түбә үзәгенә әверелә, аңа Сөн буендагы Аеш, Иске һәм Әлем авыллары буйсына башлый...

Инде аңлашылгандыр, Күккүз би 1586 елда ук үз төбәген волость итеп раслата, Бүләр авылына җир белән файдалануга хокук грамотасын аның уллары Кылчан белән Тәнеч яңартып ала. Бүләр авылы әле Уфада крепость төзелгән һәм махсус воевода китереп утыртылган 1576 елга кадәр үк нигезләнгән була. Ә Башкортстан галимнәре безнең төбәктә Бүләр исемен йөртүче 7-8 авыл булган, дип раслый. Алар арасыннан Бүләр-Байсар, Татар Бүләре, Мари Бүләре булып яшәп калганнары, бүгенге Илеш районында да Бүләр авылы булуы (анда шагыйрь һәм

рәссам Хәмит Латыйфи туып-үскән) һәм аның 1980 елларда юкка чыгуы мәгълүм, ә калган 2-3 се исемнәрен башкага үзгәрткәнме, әллә бөтенләй юкка чыкканмы – гөманлавы читен...

Кабат раслыйк: Байсар авылы 1586 елга кадәр үк нигезләнгән. Ә без шуны ачыклый алмыйча күпме иза чиктек! Казанның кабинеттан чыкмыйча утырган «галимнәр»е «Татар энциклопедияләре»нә Байсар авылын әүвәл – 1754, аннары 1713 ел белән бәйләп кертте, ә элекке документны нишләп тапмаганнар? Уфа архивына барып чокынсалар, окладларын кисәләр дә, фәнни дәрәҗәләрен йолкып алалармы әллә? Кабинеттан чыкмыйча да акча «яугангадыр», әнә, алар Минзәләдәге Бикбау авылын да 1729 елгы, дип яза, ә авылга нигез салган Бикбау картның улы Йосыф истәлегенә 1657 елда куелган кабер ташы авылдан ике чакрымда бүген дә, «галимнәр» битенә төкергәндәй, исән-сау көенә басып тора...

● Иске Байсар авылының бүгенге мәчете.

Дөрес, Казанныкылар гына түгел, Уфа галимнәре дә шактый бутый. Старшина, морза Байсар Күзәшевны да, әнә, Байсар авылына нигез салучы, дип атаганнар бит, ә авылның 1700 елларга кадәр, бер гасыр буена Бүләр исемен йөртүен искә алмаганнар. Ни Казанныкылар, ни уфалылар шушы Байсардан дистәләгән гаиләнең 1860 елларда Яңавыл районындагы Биз елгасы буена күчеп, янә шушы ук исемдәге өр-яңа авыл нигезләвен дә, аның 150 ел буе күкрәп яшәвен дә белми!.. Явыз, мәкерле Сталинның Уфа губернасында вәгъдә ителгән референдумны үткәрмичә, 1922 елда аның волостьларын башкалары белән Кече Башкортстанга кушып куюы һәм большевиклар төзегән «Берлин стенасы» аркасында Яңавыл районында кардәш авылыбыз барлыгын без дә ишетми-белмичә яшәдек, ни үкенеч!..

Старшина Байсарның бабасы Күккүз би исеме Күгәй рәвешендә авыл шәҗәрәсендә ярылып ята. Тарихи документларга Кузяшев булып кергән Байсар старшинаның 1658 елда, үзенә инде 85 яшь тулганнан соң язган хаты Уфа архивында саклана. Менә, 1653 елның 5 мартында воевода исеменә язылган хатын сезгә дә тәкъдим итәбез.

«Семь тысящь сто шестдесять перваго году (7161-5508=1653 г.) марта пятого дня бил челом государю царю и великому князю Алексею Михайловичу (царствовал в 1645-1676 гг.) всея Руси, а на Уфе в съезжей избе воеводе Ивану Андреевичу Франзбекову (воеводствовал в Уфе 1653-1655 гг.) подал челобитную (т.е. прошение) Уфимскаго уезду Казанской дороги деревни Буляр и Булярские волости ясашной башкирец Байсарко Козяшев, в челобитко ево написано: платить де он Байсарко Государева ясаку в Казань по пяти батман меду да по две куницы да на Уфу по десяти куниц на год; тому де лет с восемдесять и шесть де он Байсарко стар и увечен и без детей... здал он Байсарка половину своего жеребия тое ж Казанской дороги деревни Тюршевы гулящему (т.е. без места жительства) башкирцу Айтугану Сабакову и государь бы пожаловал ево Байсарку велел записать в книги половину ево ясака, а то он Байсарка в государеву казну платить в Казань и на Уфу, чтоб де ему Байсарке в том государеве в большем ясаке вконец (не погибнуть ?) и по государеву и великого князя Алексея Михайловича всея Руси указу воевода Иван Андреевича Франзбеков, слушав Байсаркин челобитной, велел платить ево Байсарина жеребья половину в Казань по полутретья батмана меду да по кунице да на Уфу по пяти куниц на год гулящему башкирцу Айтугану Сабакову и велел ево написать в Уфинские в ясашные окладные книги, что ему платить на Уфу государева окладного ясаку по пяти куниц да в Казань по полутрети батмана меду» (ЦГИА РБ. Ф. 172. Оп. 1. Д. 20.).

Башкорт галимнәре өстәп куйган: «Исходя из того, что в XVII в. названия деревень в основном исходили из этнонимов, названий тюб–аймаков и родов (волостей), как Тамьян, Табын, Буляр, Байляр, Еней, Киргиз, Сарайли, Мин, Юрмий, Ирэкте, то вполне уверенно можно сказать, что одна из 5-7 деревень под названием Буляр впоследствии называлась Байсарово. Поэтому Байсар Козяшев (Кузяшев) был основателем одноименного поселения».

Инде әйттек: бүген Байсар исемен йөрткән авылны старшина Байсар Күзәшев нигезләмәгән, ул аңа кадәр бер гасыр буе Бүләр исемен йөрткән, Уфа галимнәре дә тарихны нык бутый!

Йәнәй волостеның Исәнбай авылында бөек кенәз Алексей Михайлович Романов тарафыннан 1659 елда бирелгән грамота белән яшәүче дистәгә якын вотчинник, 1713 елның 16 маенда төзелгән килешү буенча, инде Бүләр түбәсе үзәгенә әверелгән Байсар авылы җирләренә килеп урнаша. 1738 елда төзелгән яңа бер килешү нигезендә Йәнәй волостеның Тугыз түбәсеннән (әлеге түбәдә 9 татар авылы тупланган) икенче партия «башкорт» типтәрләре дә күчеп килә. Беренче елларда алар үзләрен Бүләр волостендагы җир хуҗалары белән бертигез хокукта тоеп яшәсә дә, Оренбург конторасы 1816 елдан соң килмешәкләргә бер ир-атка 15 дисәтинә исәбеннән генә җир бүлеп бирү турында карар чыгара, чөнки Байсар авылына тиешле җирләр элек 586 кешегә генә исәпләп бирелгән була. Йәнәй волостеның күчеп килгәннәр имана җирен һичьюгы 30 дисәтинәгә җиткерүне үтенеп хатлар юллап карый. Власть ияләре тарафыннан бернинди миһербанлык авазы да ишетелмәгән, 1852 елда килмешәкләр үзләрен янә Йәнәй волостена кайтаруны һәм аларга анда 40 ар дисәтинә имана җире бүлеп бирүне таләп итә башлый. Әмма хәзер йәнәйлеләргә бу чорда инде Вятка губернасының Сарапул өязе составына күчерелгән якташлары хыянәт итә, алар Байсардагы туганнарын кабул итүдән баш тарта. Ә Байсар гаҗәеп зур тизлек белән үсеп баручы авыл бит. 1859 елда ук анда яшәүчеләр саны 1331 «башкорт»ны һәм 84 татарны тәшкил итә. 1860 еллар барышында инде бер төркем крестьяннар Сөн елгасы буйлап югарырак урынга, Яңа Байсар авылын нигезләп күченә. Икенче төркем бүгенге Яңавыл районы территориясендәге Биз елгасы буена күчеп урнаша. Ул Биз башланган урыннан алып Буй елгасына кадәр сузылган җирләр һәм андагы Болан күле әле 1605 елда ук Йәнәй волосте вотчинникларына беркетелгән була (История башкирских родов. Гирей. 86 бит). Моны «Аулы мензелинских башкир» китабында (287 бит) галим Ә.Әсфәндияров та раслый: «Поля начинаются у селения Байсарово и кончаются в Бирском уезде». Икенче урында ул «Йәнәй волосте вотчинникларының җирләре Оса елгасына кадәр сузыла», дип тә өсти (25 бит).

Тагын шунысын да искә төшерик: 1738 елда Сикия елгасы буенда Мәчти авылын корган чакта, аңа Байсардан да берничә гаилә күченә, алар янына Башкортстанның бүгенге Бакалы районындагы Киләй авылыннан Мәсәгуть-Мәчти Абызаев кебек йөзбашы, Шаран районындагы Шыгай авылыннан 8 гаилә килеп өстәлә. Шулай ук XVIII гасырда Агыйдел буенда Идел Каентүбәсе исеме астында яшәп яткан, ә бераздан Тат.Әҗбигә әверелгән авылга да 1800-1808 елларда Исәнбай (Әгерҗе районында), Байсар, Апач, Сикия, Кадермәт, Кәлтәү (Актанышлылар) авылларыннан күченгән 20 шәр гаилә килеп өстәлә. 1870 еллар башында ике чакрым читтә Яңа Байсар, бүгенге Яңавыл районындагы Биз елгасы буенда тагын бер Байсар үсеп чыга. 1910 елда янә 15 ләп гаилә, Столыпин хөкүмәте вәгъдә иткән ссудаларга алданып, Омск өлкәсенә тикле күченә һәм Байсар исемендәге яңа авылны нигезли, әмма тора-бара урыслашып бетә һәм исемен дә җуя... Без Байсар авылыннан төрле якка күчеп киткән төркемнәрне махсус рәвештә саныйбыз, чөнки ул авылның әледән-әле халык санын югалтып торуын дәлилли, ә үзе тау чишмәсе кебек, һаман ургылып тора, кипми...

(Байсар турында бәян итүне туктатып, 240 ел буена аның иярчен булып яшәгән Мәчти авылы турында өстәмә ясарга мәҗбүрбез. Әле бер ай чамасы элек кенә Мәчти авылы урынына таш дивар корып куйганнар да, «үтә белдекләр» авыл 1720 елларда ук яши башлаган, дип өстәргә батырчылык иткән. Иллә мәгәр Мәчти авылына үз исемен бирәчәк Мәсәгуть Абызаевны һәм Шаран районының Шыгай авылыннан килгән 8 гаиләне Сикия елгасы буендагы Байсар вотчинасына кертү турындагы килешү Уфа провинциясе канцеляриясендә 1738 елның 9 сентябре көнендә генә төзелгән бит, нинди хокук белән теләсә нинди бәндәләр тарихи документларга ревизия ясый башлады соң?)

АВЫЛ КӨРӘЙГӘН ЕЛЛАР

1738 елгы тарихи документ Байсар авылы халкының кайсы кавемнәрдән булуы, ничек килеп төпләнүе хакындагы мәгълүматлары белән кызыклы.

«1738 г. сентября 19. Запись доверенного от башкир (Казанской дороги, Гирейской вол. Мряся Солтанаева башкирам Енейской вол. старшине Ирмяшу Урмашеву с товарищами о припуске их для поселения на своей вотчинной земле.

Писана запись под гербом четыре копеешным: Уфимского уезду, Казанской дороги, Гирейской волости, Бюляры тож, деревни Байсариной башкирец Мрясь Солтанаев, будучи в Уфе, дал сию запись от крепостных дел с повеления тое же волости, деревни Илак башкирца старшины Кадыргула Касимова, Муртазы Сююшева с родственники своими, в чем от старшины Кадвергулы товарищи между ними имеютца татарские письма, тое Казанской дороги, Енейской волости башкирцом старшине Ирмяшу Урмашеву до сотнику Масегуту Абызаеву, Иштыку Иткинину с родственниками кое в том: припустила, Мрясь, с повеления показанного старшины Кадыргула Касимова с товарищи их, Ирмяша с товарищи, для поселения на водченную свою землю 30–ти дворами, а именно – по речкам Сюне да Сикие, которою вотчинною владеем мы, Мрясь с товарищи. И в той нашей вотчине им, Ирмяшу с товарищи, пашню пахать, и сено косить, и в показанных речках по Сюне и Сикие и в других речках и в озерах, которыми мы владеем, рыбу ловить, токож в тех урочищах на речке Секие мельницу строить, где они похотят. А по тем речкам и в лесах им, Ирмяшу с товарыщи, бесспросу ево Мряся с товарыщи, никакого зверя не ловить, и в вотчине их бортей не делать, и никакого насимство не чинить, такмо в той нашей вотчине им, Ирмяшу с товарищи, з детьми и с родственники, в лесах бревна и дрова рубить, и лубье снимать, и хмель щипать про свой обиход, сколько пожелают. А ежели они, Ирмяш с товарищи, где на степях или в лугах и в лесах какого зверя увидят, а токого зверя им, Ирмяшу с товарищи, ловить повольно самим, но токмо до лесной звериной гоньбы им, Ирмяшу с товарищи, дела нет и никакими снастями не бить и не ловить. А ежели я, Мрясь или показанный старшина Кадыргул с товарыщи, з детьми и родственники своими с тое вотчины станем их ссылать или в чем какое будем чинить утеснений и им. Ирмяшу с товарыщи, взять на нас, Мрясе и на Кадыргуле с товарищи, по сей записи за неустойку 50 руб...»

Уфимская провинциальная канцелярия, д. №158, Записные книги г.Уфы, 1738 г., лл.76–77. – (Материалы по истории Башкирской АССР, III том).

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Татарның игелекле улы

Роберт Фәйзи улы Гыйләҗиев (1938) – Татарстан Республикасында ягулык-энергетика комплексы ресурсларын рациональ һәм сыйфатлы файдалануны тәэмин итү буенча Дәүләт бюджет идарәсе башлыгы, Башкортстанның атказанган химигы һәм атказанган нефтьчесе, Россия Федерациясенең нефть һәм газ промышленносте атказанган хезмәткәре, өстәвенә «Россия федерациясе энергетика министрлыгының мактаулы нефтьчесе», Россия Федерациясе ягулык-энергетика комплексының мактаулы хезмәткәре», «Россия энергетика министрлыгының мактаулы энергетигы. Ул Биектау районының Ташлы Кавал авылында туган.

Озак еллар буе Башкортстанда «Уфанефтехим» берләшмәсенең генераль директоры булып эшләдә. Аның Татарстанга күченеп кайтуына да 25 елга якын вакыт узып бара. Бактың исә, якташым Роберт Фәйзи улына 85 яшь тулып килә икән!

Роберт абый хакында күпмедер беләм дә кебек. Ул җитәкләгән Биектау районы якташлык җәмгыятендә аның урынбасары булып эшләп алырга да туры килде. Җәмәгать оешмасы гына булса да, кешенең холык-фигылен ачарга, кемлеген ачыкларга шактый ук мөмкинлек бирә торган җитди эш. Үз өстенә йөкләнгән бу вазыйфага зур җаваплылык белән карый торган, үзе генә түгел, башкалардан да шундый ук мөнәсәбәт таләп итә торган кеше булды Роберт абый. Якташлык җәмгыятьләре һәр районда бар. Ләкин аларның юридик оешма булып рәсми рәвештә теркәлгәннәре бармак белән генә санарлык. Ә менә Роберт Фәйзи улы «Биектау якташлыгы»н җиренә җиткереп, рәсми рәвештә теркәтте. Җәмгыятьнең башкарган эше дә һәркемнең күз алдында: ел саен октябрь башында өлкәннәр көнен үткәрү матур традициягә керде. Казанда Биектаудан чыккан күренекле кешеләр һәм бүгенге көндә район авылларында көн күрүче хезмәт ветераннары ел саен шулай бер җыелып аралашалар, күңел ачалар, ял итәләр. Роберт абый җәмгыять әгъзаларының берсен дә тыныч кына тотмый: телефоннан шылтыратып хәлләрен белешә, район өчен нинди хезмәт күрсәтергә мөмкинлекләре булуын ачыклый. Язучы, журналист, «Салават күпере», «Сәхнә» журналларының баш мөхәррире Зиннур Хөснияр Роберт абый инициативасы белән Биектау районы мәктәпләрендә укучы балалар белән бию конкурсы үткәрде. Минем үземә дә районыбыз балалары арасында шигырь яза белү осталыгын ачыклау өчен үз исемемдәге конкурс үткәрергә туры килде. Җиңүчеләрне дә ачыклап, акчалата призлар да өләштек. Язучылар берлегенең Тукай исемендәге клубында якташ язучыларыбызга багышланган кичәләр үткәрү, якташыбыз, Россия Федерациясенең һәм Татарстанның халык артисткасы, халыкара конкурслар лауреаты, Казан консерваториясе укытучысы Клара Хәйретдинованың юбилей кичәсендә катнашу – болар барысы да якташлык җәмгыятенең Роберт Гыйләҗиев инициативасы белән оештырылган чаралары. Бу эшләр барысы да аның төп эшеннән тыш, аларга бернинди дә хилафлык китермичә башкарылып килә. Ә төп эше башка.

Бүген һәр эш кешесе шәхси автомобиль иясе, шуңа күрә аның хезмәте автомобиль ягулыгына бәяләр көннән көн күтәрелә барган бу заманда барыбызны да социаль яктан кайгыру булып бәяләнергә хаклы. Дөньяда барган сәяси һәм икътисади тотрыксызлык, бәяләрнең кискен үзгәреп торуы ул беренче чиратта бензин бәяләре белән уйный. Рус акчасының долларга карата мөнәсәбәте арту нәтиҗәсендә бензин бәясе кискен рәвештә күтәрелә, ә инде доллар арзанайганга карап бер күтәрелгән бензинның бәясен аның хуҗалары киредән төшерергә беркайчан да ашыкмый. Роберт Фәйзи улы җитәкләгән оешма ягулык сатучыларның аның бәясен нигезләнмәгән килеш күтәрүдән тоткарлау чараларын күрә, шулай ук ягулыкның сыйфатын төшермәүне контрольдә тота. Автомобиль моторының гомер озынлыгы нәкъ менә ягулыкның сыйфатына бәйле. Бүгенге көндә экология, әйләнә-тирә мохит, һаваның чисталыгы да автомобиль ягулыгының сыйфатына нык бәйләнгән.

Р.Гыйләҗиев Биектау районының Ташлы Кавал авылының җидееллык мәктәбендә белем ала. Ташлы Кавал безгә таныш язучы Альберт Хәсәнов өчен дә чит-ят түгел. Аның да сугыш елларына туры килгән бала чагы шушы авылда үтә. Альберт Хәсәновны без Кече Кавал авылында туган дип беләбез. Аның әтисе Барый абый шул авылда укытучы булып эшләгән. Альбертның әнисе Шәрәфелбанат улы туганда вафат була, әтисе Гөлсем исемле икенче укытучы кызга өйләнә. Ә Гөлсем Ташлы Кавал кызы була. Сугыш башлангач, Барый Хәсәновны фронтка алалар. Хатыным һәм улын ул Гөлсемнең әти-әниләре янына, Ташлы Кавалга кайтарып, үзе сугышка китеп бара. Менә шулай итеп, безнең Альберт Хәсәнов белән Роберт Гыйләҗиевкә 1945 елда Ташлы Кавал мәктәбенә беренче класска бергә укырга керергә, бер парта артында утырып әлифбадан хәреф танырга өйрәнергә туры килә. Альберт Хәсәнов Казанга килеп чыккач, без аның белән еш кына хәлләрен белешергә Роберт абый янына барып чыга идек. Ике сабакташ, ике ветеран, дөньяларын онытып, бик озаклап, бергә уйнап үскән малай чакларын искә алып утыра иде ул көннәрдә. Әллә ничә чынаяк чәйләр эчелә, өч-дүрт мәртәбә самавыр кайнатыла.

Менә шулай, туган авылында җидееллык белем алганнан соң, Роберт Гыйләҗиев 1952 елда, бергә укыган дус кызы Фирая белән Казанга чыгып китә. Ә Альберт Хәсәновлар инде, әтисе сугыштан кайткач, Дөбьязга күченәләр. Роберт Казанда К.Маркс урамында урнашкан 18 нче татар мәктәбендә укып, аны көмеш медальгә тәмамлый. Алтын медальлек тә була белеме, тик урыс телен белеп бетермәве комачаулый – рус теленнән укытучысы «дүрт»ле куя. Ташлы Кавал авылыннан мәктәпне медальгә тәмамлаучы һәм югары уку йортына укырга кергән беренче егет була ул. Ә Фирая 80 нче татар мәктәбендә укый. Мәктәптә укыганда Роберт Островский урамында яшәүче туганнарында яши. «Үзләренең өч балалары бар иде Гыйззәт абый белән Маһирә апаның. Шулар өстенә биш егетне фатирда тоттылар. Ун кеше 24 квадрат метрлы кысан гына квартирада яшәдек», – дип искә ала бүген Роберт абый авылдан килеп, мәктәптә укып йөргән көннәрен. Мәктәпне тәмамлагач, Роберт Казан химия-технология институтына укырга керә. Ә Фирая медицина училищесенда белем ала. Укып бетергәч, аларны икесен дә юллама белән Башкортстанга, Уфага җибәрәләр. Ләкин язмыш аларны аера. Бары тик 23 ел үткәч кенә кавышу насыйп була. Бу вакытта инде Роберт абыйның кызы үсеп, егерме яшькә җиткән була.

1960 елда институт юлламасы белән Башкортстанга килгән Р.Гыйләҗиев Уфада нефть эшкәртү заводына эшкә урнаша. Гади механиктан җитештерүнең барлык баскычларын үтеп, илдә икътисади һәм сәяси үзгәрешләр вакытында – 1993 елда – «Уфанефтехим» Акционерлык Җәмгыяте дип атала башлаган зур нефть эшкәртү берләшмәсенең генераль директоры дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Аның Башкортстандагы 39 елга сузылган бөтен хезмәт юлы шушы предприятиядә үтә, үзгәртеп корулар чорында тәмам таркалып баручы шушы оешманы кабат торгызу, аякка бастыру белән бәйле була. Шуңа күрә Р.Гыйләҗиев турында язма, аның Башкортстанда үткән хезмәт юлы хакында сөйләнмәсә, һич кенә дә тулы булмас иде. Дөрес, Роберт Фәйзи улы 1998 елда Казанга әйләнеп кайткач та республика өчен, җәмгыять өчен файдалы хезмәт белән шөгыльләнә һәм матур күрсәткечләргә дә ирешә. Казанга кайткач ул башта нефть инспекциясе оешмасы, дәүләт энергия күзәтчелек оешмасы җитәкчесе булып эшләде. 2005 елдан бирле ягулык-энергетика комплексы ресурсларын рациональ һәм сыйфатлы файдалануны тәэмин итү буенча дәүләт бюджет идарәсе башлыгы булып торды. Түбән Камада ТАНЕКО нефть эшкәртү заводын төзегәндә, аның беренче чиратын сафка бастырганда Роберт Фәйзиевичнең 34 ел буе Башкортстанда нефть эшкәртү заводы җитәкчесе булып эшләгән чорда туплаган тәҗрибәсе зур әһәмияткә ия булды. Республика җитәкчелеге ТАНЕКО заводын төзү штабына җитәкчелек итүне аңа тапшырды. Роберт Фәйзи улының хезмәтләрен югары бәяләделәр. Ул дүрт тапкыр дәүләт бүләкләренә лаек булды. Татарстанда Р.Гыйләҗиевне танып белмәгән, бигрәк тә туксанынчы елларда җитәкчелек иткән, бер генә район башлыгы да юктыр. Нәкъ шул узган гасыр азагында Татарстанда авылларны газлаштыру киң колач белән алып барылды. Ә газ үткәрү өчен, әлбәттә, инде трубалар кирәк. Татарстанда шулай ук автомобиль, авыл хуҗалыгы машиналары өчен ягулык-майлау материаллары, юллар төзелеше өчен файдаланыла торган битум һәм ашламалар эшләнелми иде. Боларның барысын да күрше Башкортстанда аягында нык басып эшләүче һәм безнең Роберт Фәйзи улы җитәкләгән «Уфанефтехим» җәмгыятеннән һәм Уфаның башка заводларыннан табарга була иде. Аның Татарстан егете икәнен белеп алган район башлыклары берәмләп тә, төркем-төркем булып та аның янына агыла. Якташлары һәрвакыт ачык йөз белән каршылый ул. Гозерләрен максимум үтәргә тырыша. Үз предприятиесендә булмаган нигъмәтне (әйтик, ашламаларны) күрше заводлардан юлап таба. Ул вакытта барысы да әйбер өчен алдан түгел, ә ахырдан түләү шарты белән бирүне сорый. Бик еш кына соңыннан түләү өчен дә акчалары булмыйча, бартер юлы белән, авыл хуҗалыгы продуктлары яисә башка товарлар белән түләргә тырышалар. Биектау районыннан бер хуҗалык хәтта КамАЗ автомобильләре белән түли. Роберт Фәйзи улы Биектау районы хуҗалыклары өчен аеруча күп ярдәм күрсәтә. Үзенең туган авылына газ кертү өчен трубалар, башка материаллар белән булыша. Аның ярдәме белән туган авылы Ташлы Кавалда мәчет салына, авылга керү юллары, авыл урамнары төзекләндерелә. Ләкин Уфада, Башкортстан малын Татарстанга җүн хакка җибәреп ята дип, Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимовны котыртучылар табыла. Нәтиҗәдә үз вакытында җан дусты булган, хәтта гаиләләре белән аралашкан Р.Гыйләҗи-

ев белән М.Рәхимов арасыннан кара мәче уза. 60 яшен тутырып пенсиягә чыгуга, Роберт Фәйзи улы гариза язып эшеннән китәргә мәҗбүр була. Әбит Башкортстан икътисадын күтәрү өчен аз көч куймый Р.Гыйләҗиев. Туксанынчы елларда нефть эшкәртү предприятиеләрен чит илләр үрнәгендә үстерәбез дип, төп предприятие тирәсенә эреле-ваклы кече яки уртак предприятиеләр белән әйләндереп алу нәтиҗәсендә көннән-көн артка тәгәри барган «Уфанефтехим»ны яңадан аякка бастырып, беренче елларында ук нефть эшкәртүне 7 миллион тоннадан 9 миллионга күтәрүгә ирешкән Роберт Фәйзи улының кадерен күргә дә күрергә кирәк иде, югыйсә. Нәкъ менә шушы акчалар заводка яңа технологияләр кертергә, яңа продуктлар эшләп чыгарырга, булганнарының сыйфатын тагын да күтәрергә мөмкинлек бирә.

Р.Гыйләҗиев кешелеклелек, әхлак ягыннан да хезмәт кешесенең тормыш-көнкүрешен яхшырту, социаль мәсьәләләрне хәл итүгә гаять зур игътибар биргән җитәкче. Ул генераль директор булып эшли башлауга, социалистик җәмгыятьтә зур игътибар бирелгән шушы мәсьәләләрне алгы планга чыгара: мактау такталарын, хезмәт алдынгыларын данлауның төрле юлларын кулланышка кертә. Коллективтагы гади генә эшченең дә туган көннәрен искә төшереп, котлау оештыра. Хезмәт кешесе хөрмәткә лаек икәнен һәркемнең исенә төшереп тора. Хәтта эшчеләрне азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итә, предприятиенең авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүче ярдәмче хуҗалыгын булдыра. Яшелчә, бәрәңге, ит, сөт продуктлары үзләрендә җитештерелә башлый. Илеш районының «Сөн» хуҗалыгы ул чакта завод составына алына. Совхозга чит илләрдән югары продукт бирә торган токымлы сыерлар, казлар кайтарыла. Болар көткән нәтиҗәне бирмичә калмый, нефть продуктлары җитештерү буенча берләшмә Россиядә иң алдынгы алты предприятие арасына керә. Завод 1996 елда Россия промышленностенең 100 лидеры китабына кертелә. Аның турында Россия газета-журналларында языла, радио-телевидениеләрдән сөйләнә.

● **Мортаза Рәхимов гаиләсе белән бергә ял иткәндә.**

Роберт Фәйзи улы халыкның бер икмәк белән генә түгел, бәлки рухи азыкка да ихтияҗы булуын яхшы аңлый. Ул әдәбият-сәнгать кешеләренең хезмәтен дә бәяли белә. Аның бу хезмәтләрен бигрәк тә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин белән дуслыгы яхшы күрсәтә. Алар 1996 елда «Сөн» хуҗалыгы сабан туенда танышалар. Роберт Миңнуллин үзенең илле яшьлек юбилеен нәкъ менә Роберт Фәйзиевичнең ярдәме белән үзенең туган ягында, Башкортстанның Илеш районында зурлап, бөтенхалык бәйрәме – Сабантуй итеп үткәрү бәхетенә ирешә. Бу урында мин Роберт Миңнуллинның әнә шундый кодрәтле адашына багышлап язган шигырен тәкъдим итәсем килә.

Туган җирләр – торган җирләр
Утырабыз Сабантуйда,
Аз гына кымыз уртлап.
Үзебез төрле икән дә,
Язмышларыбыз уртак.

Без туып үскәнбез икән
Төрле-төрле якларда.
Чапканбыз малай чакларда
Төрле-төрле атларда.

Сөйгәнбез үсмер чакларда
Төрле-төрле кызларны.
Күңелләрдә яшьлектәге
Истәлекләр кузгалды.

Икебез дә моңсуланып
Торабыз Сөн ярында.
Син тугансың теге якта,
Мин – Сөннең бу ягында.

Икебез дә ояларны
Читтә корганбыз икән.
Туган җирләрне үзара
Алмаштырганбыз икән.

Мин – синең туган җиреңдә,
Син исә – минекендә.
Нигеземне сагынулар
Саргайта мине көн дә.

Синең дә туган авылың,
Туган ягың асылдыр.
Асыл туган якларыңны
Син дә сагынасыңдыр.

Туры килсә дә яшәргә
Бөтенләй ят якларда,
Бирешкән юк дошманнарга,
Сер биргән юк ятларга.

Ят яклар да якын инде,
Чит түгел читләре дә.
Безгә инде туган җирнең
Юк бугай чикләре дә.

Кендекләр шушы җирләргә
Бәйләнеп беткән инде –
Торган җир дә туган җиргә
Әйләнеп беткән инде.

Әнә шундый кеше ул безнең якташыбыз Роберт Гыйләҗиев. Аның турында мәкалә дә, шигырь дә язарлык. Әнә шул әсәрләр аша аның исемен, аның кылган гамәлләрен киләчәк буыннар да белеп торырга тиеш.

Укучылар Р.Гыйләҗиевнең әти-әнисе, туганнары, гаиләсе турында белми калуы мөмкин. Ул Ташлы Кавал авылында Фәйзерахман ага белән Кәримә апа ишле гаиләсендә, ун бала арасында үсә. Фәйзерахман ага сугыш башланганда Ташлы Кавалда авыл советы рәисе булып эшләгән. Авыр сугыш елларында Ташлы Кавал авылы халкы үзенең колхозда эшләгән хезмәт хакы хисабына җиңүне якынайту өчен Кызыл Армиягә бер самолёт һәм танк бүләк итә. Бу эшләрне оештыручы нәкъ менә Фәйзерахман ага була. Аны, оештыру сәләтләрен күреп, 1943 елда Дөбъяз районы башкарма комитетына райсобес мөдире итеп күчерәләр. 1950 елда Фәйзерахман ага туган авылына колхоз рәисе булып кайта. «Кызыл Байрак» колхозын җитәкли. Фәйзерахман абыйның әтисе Гыйләҗи ага да заманында республикада билгеле җитәкче булган – Ташлы Кавалда аны Татарстан автономияле республикасы оешкан елларда Мүлмә волостеның башлыгы булган дип искә алалар.

Фәйзерахман һәм Кәримә апа ун бала үстерә. Роберт абый – шуларның өченчесе. Үзеннән олыраклардан абыйсы белән апасы вафат инде. Фидарис энесе, җиденче сыйныфны тәмамлагач, Роберт абыйсы артыннан Уфага килеп, ашханәләр системасында эшли, Орджоникидзе районы Җәмәгать туклануы җәмгыятенең генераль директоры була. Сеңлесе Кадрия колхозда баш бухгалтер, председатель, Коркачыкта авыл совете рәисе булып эшли, хәзер лаеклы ялда. Тагын бер энесе Альберт колхозда баш инженер, авыл советы рәисе булды. «Факел» җәмгыятенең директоры булып эшләде, бакыйлыкка күчте.

Роберт абыйның кызы Альбина Уфа төзелеш институтында укып, архитектор белгечлеге ала. Хәзер кызы Илена белән Мәскәүдә яши, архитектор-дизайнер булып эшли.

Роберт абый Гыйләҗиев инде сиксән биш яшен түгәрәкләп килә. Сәламәтлеге нык. Шулай булсын алдагы елларда да.

Рафис КОРБАН.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

8 июль (шимбә). ***Зөлхиҗҗә аеның 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 23.44 сәгатьтә калка, 10.18 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.18 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Башың авыртса, сөт эч

Баш авырта башлауга ук, дару капканчы, 1 стакан сөт яки йогырт эчеп куярга кирәк. Сөт ризыкларындагы B2 витамины баш мие нейроннарын яңартылу процессында катнаша. Сөттәге пептидлар (аминокислота калдыкларыннан җыелган бик вак аксым молекулалары), күзәнәк эченә үтеп кереп, нейрон бәйләнешләрен ныгыта, йөрәк-кан тамырлары системасы эшен җайга сала, авырту хисен баса. Тик аларның тәэсире озакка бармый, чөнки пептидларны ферментлар җимерә.

9 июль (якшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 23.52 сәгатьтә калка, 11.49 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.15 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Һәркайсы сихәт бирә

Кыяр, бәрәңге, торма, чөгендер, кәбестә ашау бавырны яшәртә. Яшел салат, кыяр, кәбестә бөерләр эшчәнлеген яхшырта. Чөгендер, әспе (спаржа), кәбестә канда шикәр микъдарын киметә. Йөзем согын даими куллану кан басымын төшерә. 10-20 көн буе рәттән икешәр алма ашау кан басымын җайга сала. Күрәгә яки өрек төнәтмәсе шешенүне бетерә. Моның өчен 1 литр кайнаган суга 100 грамм күрәгә салып, 6 сәгать төнәтәләр, бал кушып эчәләр.

10 июль (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 13.20 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.13 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Стенокардиядән – җимеш суы

Стенокардия (күкрәк бакасы) интектергәндә, 4әр аш кашыгы гөлҗимеш һәм дуләнә җиләкләрен 2 литр кайнар суга салып, 1 көн төнәтәләр дә, марля аша сөзеп, ашаган саен 1әр стакан эчәләр. Дәва курсы - 2-3 атна.

11 июль (сишәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 23 нче көне. 23 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 0.11 сәгатьтә калка,14.50 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.11 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Чөгендер согы

Чөгендер согы климакс вакытында файдалы. Башта чистартылган чөгендерне, нитратлары чыгып бетсен өчен, 8-10 сәгать салкын суда тоталар. Аннары согын сыгып, аны 2-3 сәгатькә суыткычка куялар. Дәвалау үзлеген арттыру өчен, чөгендер согына шулкадәр үк кишер яки алма согы кушып эчү яхшы. Организмны чистарту өчен исә чөгендер-кишер согын көн саен 200 миллилитр эчәргә киңәш ителә.

12 июль (чәршәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 0.23 сәгатьтә калка, 16.21 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.09 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Уртны ныгыту

Өлкәнәйгән саен, урт утыра, теш муентыклары ялангачланып кала, бик сизгергә әйләнә. Мамыклы таякчыкны йодка манып, көненә бер тапкыр теш муентыкларына сөртеп чыгарга кирәк. Һәр ай саен бер атна буе шулай дәваланганда, теш тукымалары ныгый, ялкынсыну басыла. Авыз куышлыгындагы теләсә нинди ялкынсыну вакытында тозлы кәбестә булыша - аны әкрен генә чәйнәп ашарга, тозлы суы белән авызны чайкарга кирәк. Еш канаганда, марля тампонны канлутнын (чистотел) спиртлы төнәтмәсендә чылатып, уртларга куеп торалар.

13 июль (пәнҗешәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 0.41 сәгатьтә калка, 17.49 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.06 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Колак шауласа

Колак шаулаудан котылу өчен, 1 уч укроп орлыгын ярты литр кайнар суга салып, термоста ярты сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, яртышар стакан эчәләр.

14 июль (җомга). ***Зөлхиҗҗә аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 1.09 сәгатьтә калка, 19.12 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.04 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Ташкабак кайнатмасы

1 кг ташкабак, 1 кг шикәр, 2 лимон, 5 г лимон кислотасы (порошок) кирәк. Төшләре алынган, кабыгы чистартылган ташкабакны шакмаклап турыйлар, шикәр белән күмәләр дә, 1 сәгатькә калдыралар. Лимоннарны юка түгәрәк телемнәргә турыйлар. Ташкабакны кайнатып чыгарып, лимон һәм лимон кислотасы өстиләр, уттан алып, суыталар. 3 тапкыр шулай кайнатып чыгаргач, кайнар килеш банкаларга бүләләр.

ХӘЛИТКЕЧ ОЧРАШУЛАР

Брюссельдә 29-30 июнь көннәрендә Европа Берлегенең (ЕС) Украинадагы хәлләргә багышланган саммиты үтте.

Аның йомгаклау документында Берлекнең Украина иминлеге буенча озак вакытлы йөкләмәләрне үз җаваплылыгына алырга әзер булуы турында әйтелә. Иминлек гарантиясе өчен бары тик ул йөкләмәләрнең ЕС әгъзалары үткәрә торган сәясәткә каршы килмәве һәм аларның хуплавы кирәк. Шулай итеп, ЕС әгъзасы булып торган 27 илнең лидерлары Украинага хәрби һәм финанс ярдәме күрсәтү буенча уртак фикергә килгән булып чыга. Шуның белән бергә, Украинага күрсәтелә торган хәрби ярдәм ЕС илләренең саклану өлкәсенә һәм иминлегенә зыян китермәскә һәм халыкара партнерлар белән берлектә алып барылырга тиешлеге турында да әйтелә. Саммитта НАТО җитәкчесе Йенс Столтенберг та катнашкан. Анда шулай ук Россиянең «туңдырылган» активларын файдаланудан керемне Украина өчен финанс ярдәме итеп куллану турында да сүз булган. Очрашуда катнашучылар Каховка ГЭСын явыз максатта җимерүчеләрне дә гаепләп чыккан. Әлегрәк ЕС җитәкчеләре аны җимерүдә Россияне гаепләгән иде. Саммитта В.Зеленскийның «тынычлык формуласы», аның максатлары һәм төп принциплары хуплап кабул ителгән. Шул ук вакытта документта Украинаның бәйсезлеген, суверенлыгын һәм халыкара танылган чикләрендә территориаль бөтенлеген хөрмәт иткән башка тәкъдимнәрне дә карау мөмкинлеге калдырылган. Кытайны анда, БМО КШның даими әгъзасы буларак, РФ гаскәрләрен кичекмәстән Украинадан чыгару өчен аңа басым ясарга чакырганнар. Әә Украина буенча бүген башка очрашулар да әзерләнә: 11-12 июльгә билгеләнгән НАТО саммиты һәм халыкара сөйләшүләр шундыйлардан.

Узган атнада АКШ Үзәк разведка идарәсе (ЦРУ) башлыгы Уильям Бернсның, июнь аенда Украинага килеп, Президент Зеленский һәм үзенең коллегасы белән очрашуы мәгълүм булды. ТАСС хәбәренә караганда, имеш, анда аңа Киевнең, үз территорияләрен (Кырымнан башка) көзгә кадәр азат итеп һәм авыр сугыш коралларын Кырым чикләренә урнаштырып, ел ахырына кадәр Мәскәү белән сөйләшүләр үткәрү планын чишкәннәр. Әлеге хәбәрдә ЦРУ башлыгының узган атнада РФ тышкы разведка хезмәте башлыгы С.Нарышкинга телефоннан, Россиядәге «мятеж»га АКШның катнашы булмавы хакында сөйләве турында да әйтелә.

Сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да искә төшереп үтик. Кремльдә кораллы фетнә турында җинаять эшенең туктатылуын «вакыйгаларның иң начар сценарий буенча китүенә юл куймау ниятендәге Президент ихтыяры» белән аңлаттылар. Россия Президенты В.Путин ЧВК «Вагнер»ның матди яктан тәэмин ителүе тулысынча дәүләт хисабыннан булуы турында белдерде. Ракеталардан саклану (ПРО) мәсьәләләре буенча Мәскәүдә Россия-Кытай сөйләшүләре үтте. РФ тышкы эшләр министры С.Лавров атом-төш сугышын беркем дә теләми, дип белдерде.

Фоат УРАЗАЙ.

Сөяркәгә ай саен 250 мең

Нотариус бүлмәсендә никах килешүен рәсмиләштерү өчен мөрәҗәгать иткән Чаллы хатыны гыйбрәтле дә, кызык та вакыйганы бәян итә. Ул студент улы өчен 7 миллион сумга фатир сатып алган. Иренә, ипотека алдым, дигән, ләкин бу – дөрес түгел. Әлеге вакыйга хакында «Челнинские известия»дә Лалә Гайфетдинова яза. Чынбарлыкта, бу сумманы 45 яшьлек хатын бай һәм юмарт сөяркәсе ярдәме белән җыйган. Юрист янына килгән көнне аның кәефе искиткеч шәп була һәм ул, шатлыгыннан, язмышыннан ни дәрәҗәдә уңуы турында бәян итә.

8 ел элек Марина (геройларның исемнәре үзгәртелгән – ред.) хезмәттәшләре белән ресторанда Яңа ел бәйрәмен билгеләп үтә, анда тагын бер төркем – ир-атлардан гына торган компания ял итә. Бию вакытында ул үзен ошаткан бизнесмен белән таныша, тегесе аның телефон номерын ала. Шуннан соң алар Равилнең фатирында очраша башлый, хатын сүзләренә караганда, якынларының берсе дә бу хакта белми. Ул ир-ат гаиләле, улы бар. Бизнесының уңышлы баруы аңа, үз гаиләсе өчен чыгымнардан тыш, сөяркәсенә кыйммәтле бүләкләр ясарга да мөмкинлек бирә. Язмышында мондый борылыш Маринаның күңеленә хуш килә, ул рәхәтләнеп күңел ача һәм иренә хыянәт итә, ә хәләле «өй тавыгы» була, хуҗалыкны алып бара, ашарга пешерергә һәм дачада эшләргә ярата.

2 елдан хатынының телефонына килгән СМС-хәбәр аша Маринаның ире очраклы рәвештә хыянәт турында белә һәм тавыш чыгара. Соңрак, ир белән хатын татулаша һәм бергә яшәүләрен дәвам итә. Бу хәлдән соң Марина үзенең мәхәббәт мажараларын ныграк яшерә башлый, Равил белән сөйләшү өчен тагын бер телефон сатып ала.

Аның алдында исә ханым бөтән спектакль уйный. Ул сөйгәненә иренең аерылышу өчен гариза бирүен, фатирны алмаштыруын һәм үзенең бер бүлмәле фатирда калуын хәбәр итә. Бу вакытка Маринаның улы Казанга укырга китә. Сөйгәненең гаиләсе җимерелүдә үз гаебен сизеп, бизнесмен ай саен хатынның банк картасына 200-250 мең сум, кайчакта аннан да күбрәк, акча күчерә башлый.

Шул вакыттан башлап, гади төзелеш фирмасында эшләүче Марина үзенә брендлы киемнәр сатып ала, дуслары белән төшке ашны кыйммәтле рестораннарда ашый башлый. Ире һәм улы белән бик җиңел генә диңгезгә ял итәргә бара ала. Иренең, каян бездә мондый акча, дигән сорауларына: «Яхшы премия бирделәр» яки «Өстәмә әйбәт эш таптым», – дип җавап бирә. Ә дусларына башка төрле экият сөйли, имеш, ире эшендә күптән көтелгән югары вазыйфага күтәрелгән. Һәрхәлдә, акча җитмәү сәбәпле конфликтлар гаиләдә туктый.

«Иганәче» эшмәкәр хәйләкәр сөяркәсенең гамәлләре турында тәки берни белми. Ханым бу еллар дәвамында исемнәрдә ялгышмас өчен тырыша, Равил шәһәр читенә романтик ялга чакырганда ире шикләнмәсен өчен «командировкалар» уйлап таба.

Улына фатир алып биргәннән соң, Марина үз иминлеген кайгыртып, никах килешүен рәсмиләштерә башлый, чөнки аерылышырга туры килсә, күчемсез милекне ире белән бүлешергә туры киләчәк. Ләкин ул ире белән аерылышырга уйламый. Шулай да, Равил хатыныннан аерылырга уйласа һәм үз янына яшәргә чакырса, әле нәрсә эшләячәген белмәвен әйтә.

Мөслим районының Яңа Усы авылы керәшене Никон Егоров, сугыштан соң Берлинның үзәк комендатурасында икътисад бүлеге начальнигы булган, соңыннан Мәскәүдә Юрий Гагаринны һәм башка космонавтларны укыткан.

Космонавтлар остазы

ДАНГА ИЛТКӘН ЮЛ БАШЫ

Никон Егоров 1906 елның 6 ноябрендә Уфа губернасының Бәләбәй өязе Нагайбәк волостена кергән (хәзер Татарстанның Мөслим районы) Яңа Усы авылында туа. Ул Егоровлар гаиләсендәге биш баланың иң олысы була. Авылдагылар сөйләвенчә, әнисеннән өч яшьтә калган Никон үги ана кулында үсә. Авылда башлангыч мәктәпне тәмамлауга, төенчеген алып, җәяүләп Бәләбәйгә чыгып китә. 1922 елда Бәләбәй педагогика техникумына укырга кергән үсмер тырышлыгы, җәмәгать тормышында актив катнашуы белән аерылып тора. Спорт белән шөгыльләнә, җырларга ярата. Иптәшләре аны ярдәмчел, яхшы күңелле булганы өчен дә үз итә. Тиздән техникумның комсомол оешмасы секретаре итеп сайлыйлар.

Оештыру сәләтен күреп, Никонны Югары Троицк мәктәбенә мөдир итеп җибәрәләр. Ул үз вазыйфасын башкару белән беррәттән, сәяси тормышта да актив катнаша. Халык дошманнары аңа хәтта һөҗүм дә оештыра.

Партия өлкә комитеты Никонны Мәскәүдәге Орджоникидзе исемендәге икътисад институтына укырга җибәрә. Егет институтны «5»легә генә тәмамлап, аспирантурада укый башлый. Шул елларда курсташы Еленага өйләнә. Алар Людмила һәм Татьяна исемле ике кыз үстерә.

Ә бу вакытта Яңа Усыда Егоровлар гаиләсендә фаҗигале хәл була. Аның әтисен, 1884 елгы Роман Ивановичны кулга алып, 1929 елның 23 декабрендә 3 елга лагерьга җибәрәләр.

Аның улы Никон Романович 1937 елда партия сафына керә. Ә 1941 елның 26 июненнән хәрәкәттәге армиядә була.

ФРОНТТАГЫ БАТЫРЛЫГЫ

Аның сугышчан юлы турында «Наградной лист» ачык сөйли:

«Кызыл Йолдыз» ордены йөрткән 60 нчы Павлоград укчы дивизиясенең 180 нче гвардия укчы полкының гвардия капитаны, агитатор. 1943 елның ноябреннән III Украина фронтында. 1944 елның 11 мартында җиңелчә яраланган. Полк агитаторы буларак, һөҗүм итеп алга барганда сугышчылар һәм офицерлар арасында сәяси эшне ныгытты. Кишинев өчен барган сугышларда дошман артиллериясе көчле ут ачкач, Егоров «Ватан өчен!», «Сталин өчен!», «Кишинев өчен!» дип сугышчыларны атакага күтәрә. Егоров җитәкчелегендәге сугышчылар һәм офицерлар, күпере шартлатылган елга аша чыгу өчен, кул астында булган кирәк-ярактан, 20 минут эчендә күпер-кичү ясый. Нәтиҗәдә, пехота юлны 3 чакрымга кыскартып, шәһәрнең көнчыгыш өлешенә штурм башлый.

Полк командирының сәяси мәсьәләләр буенча урынбасары (политрук) сафтан чыккач, Егоров аны алмаштыра һәм яралыларны сугыш кырыннан алып чыгуны, аларны җирләүне оештыра. Шәһәр халкы белән әңгәмәләр үткәрә.

Фронтта немец басып алучыларына каршы сугышта командованиенең хәрби бурычларын үрнәк рәвештә үтәгәне, батырлык күрсәткәне өчен, Егоров хөкүмәтнең I дәрәҗә Ватан сугышы орденына лаек.

180 нче гвардия укчы полкының гвардия полковнигы Чайка. 27 август, 1944 ел.

Лаек. Командир 60 нчы укчы дивизия командиры гвардия генерал-майоры Соколов. 28 август, 1944 ел.

«Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнергә лаек. 32нче укчы корпус командиры гвардия генерал-майоры Жеребин. 29 август, 1944 ел.

«Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләргә. 5 нче удар армиянең политотдел начальнигы генерал-майор Кощеев.

1944 елның 1 сентябре боерыгы белән, «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә».

1945 елның 14 гыйнварында Мангушев шәһәре тирәсендә, Висла елгасының сул як ярындагы немец гаскәре ныгытмаларына һөҗүм вакытында Егоров бер төркем сугышчы белән дошманны әйләнеп үтеп, артиллерия урнашкан урынга бәреп керә. Ике немец расчетын юк итәләр, ике пушканы кулга төшерәләр. Контратакага күтәрелгән дошман пехотасын һәм танкларын шул пушкалардан атып юк итәләр. 20дән артык гитлерчыны үтереп, танклар һөҗүмен туктаталар. Хәрби бурычны намус белән үтәгәне өчен, Егоровны тагын «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләклиләр.

БЕРЛИННАН – АКАДЕМИЯГӘ

Демобилизация булганнан соң да ул хәрби хезмәттә кала. Германия башкаласы Берлиндагы үзәк комендатураның икътисад бүлеге башлыгы була. Совет дәүләте вәкиле Никон Романович Германия Демократик Республикасын оештыруда актив катнаша. Ул, турыдан-туры, Берлин коменданты генерал полковник Н.Берзарин кулы астында эшли. Дүрт ел икътисад идарәсенә җитәкчелек итә. Германиядә ул Вильгельм Пик, Отто Гротеваль кебек күренекле кешеләр белән эшли, аларга сүзе белән дә, эше белән дә ярдәм итә.

1949 елда Мәскәүгә кайткач, икътисад фәннәре кандидаты полковник Никон Егоровны Жуковский исемендәге хәрби-һава академиясенең политэкономика кафедрасына җитәкче итеп билгелиләр. Ул, 15 елдан артык, авиациянең булачак инженерларына икътисад нигезләрен өйрәтә. Фәнни хезмәт белән шөгыльләнә, политэкономия курсы буенча дәреслекләр яза.

Болардан тыш, аңа космонавтларны әзерләүне ышанып тапшыралар. Ул галәмне яулаучы беренче космонавтлар – Юрий Гагарин, Герман Титов, Валентина Терешкова, Валерий Быковский, Андриян Николаев, Павел Поповичның остазы була. Хәрбиләрчә кырыс та, шул ук вакытта керәшеннәргә хас киң күңелле булуы белән, ул космонавтлар арасында абруй казана. Күңелсез хәлләр дә булгалый. Берсендә, Кытайдан килгән студентка «3» ле куя. Бу эше өчен аны Сталинның үзенә чакыралар:

– Шундый билге куеп, Сез ничек Ватан намусын пычрата алдыгыз?!

– Бу – аның үз хезмәте өчен алган билге. Әгәр мин аңа «5» ле куйган булсам, бу илебезне оятка калдырмас идеме? – дип, сорауга сорау белән җавап кайтара Егоров.

КӨНЧЕЛЛӘР ҮЧЕ

Никон Романович үз туган авылын онытып бетерми, җае чыгуга, Усыга кайтырга тырыша. Матур җырлый, көрәш белән дә шөгыльләнә. Аның һәр кайтуында авылдашлары киңәш сорап та килә. Ул беркемне дә борып җибәрми. Әмма арада көнчелләр дә була...

Нәкъ шул елларда партия билетын яңа үрнәктәгесенә алмаштыру башлана, коммунист исемен йөртергә лаеклы булмаганнар төшеп тә кала. Ерак бер чыбык очы туганы Мәскәүдәге хәрби академиягә партия оешмасына шикаять юллый: «Ул партия члены була алмый, ул – халык дошманы улы». Андый шикаятьләрдән соң Егоров зур уңышларга ирешә алмый инде... Аның «халык дошманы» ярлыгы тагылган әтисе Роман Иванович 1997 елда гына аклана. Үзеннән 12 яшькә кече бертуган энесе кече лейтенант Борис Егоров 1941 елның сентябрендә Новгород өлкәсенең Боровичи станциясе тирәсендәге сугышларда һәлак булган.

Авыл халкы сөйләвенчә, Никон Романович авылга бер кайтуында җыелышка туры килгән, аның үзен тикшерә башлагач, чыгып торуын сораганнар. Ә ул чыга да, борылып керә. Ул кергәндә, арадан берәүнең Егоровлар, аларның җирләре, маллары турында сөйләгән чагы була. Моны ишетеп торган Никон Романович, үз гаиләләрен гаепләүчедән: «Җирең безнекеннән дә күбрәк түгелме?» – дип сорый. Җире күп булып та, ялкаулыгы аркасында анда иген игеп уңыш җыя алмаучының авызы томалана. Әмма буласы булган, Никон өстеннән әләк тиешле урынга киткән инде...

Усының инде дөньядан киткән картлары сөйләвенчә, аның күңелендә туган ягы белән бәйле тагын бер юшкын кала. Анысы соңгы кайтуына бәйле. Аны алып кайткан шофер, Никонның үз энисе авылы Ясная Коммуна урынына, икенче бер Коммунага алып китә. Шул көнне Мәскәүгә билеты алынган Никонның инде әнисе авылын урарлык вакыты калмый...

Өч «Кызыл Йолдыз» ордены һәм күп санлы медальләр иясе, тыйнаклыгы, хезмәттәшләре хәленә керә белүе, коллектив туплый алуы белән башкалардан аерылып торучы Егоровны каты чир 1966 елның соңгы аенда, 60 яшендә мәңгегә алып китә.

Фирая МОРАТОВА.

638 тапкыр үлемнән калган

Фидель Кастро Рус бай гаиләдә туган – әтисенең берничә мең гектар җире булган. Университетта юридик белем алганда, марксизм белән мавыга башлаган. Үзенә тугры нибары 82 кеше генә булган килеш тә 1959 елда 33 яшьлек Фидель Куба республикасының Премьер-министры итеп куелган. Ул хакимлек итү озынлыгы буенча дөньяда өченче урындагы дәүләт башлыгы – королева Елизавета белән Таиланд короле генә аннан да озаграк вакыт идарә иткән. Кастроны барлыгы 638 тапкыр үтерергә маташканнар. Алты тапкыр чыннан да үлә язып калган, әмма 2016 елга кадәр яшәп, 90 яшендә генә бакыйлыкка күчкән. Гомере буена Америкага каршы көрәшкән, алар да командантены бәреп төшерү өчен ни генә эшләмәгән. Бервакыт дәүләт сәясәтеннән канәгать булмаган кубалыларга Америкага күчеп килергә рөхсәт иткәннәр. Фидель моннан бик оста файдаланган: төрмәләрдәге бөтен куркыныч җинаятьчене АКШка мәҗбүри депортацияләгән. Кастро иң озын чыгыш ясаучы буларак Гиннесснең рекордлар китабына кертелгән – Гаванада компартиянең өченче съездында ул 7 сәгать 10 минут буе тоташ сөйләгән. 59 яшендә тәмәке һәм сигара тартуын тулысынча ташлаган. Илдә җитештерелгән сигараларның күпчелегенең Америкага сатылуы күңеленә аеруча рәхәтлек китергәндер, чөнки командантe: “Сигара тартмасын дошманыңа бирү – иң яхшы гамәлдер”, – ди торган булган. Иң яраткан шөгыльләреннән берсе – су астында балык тоту. Океанның иң матур җирендә, хатыны һәм биш баласыннан кала беркем дә булмаган оҗмахтай матур утрауда ял итәргә яраткан ул. Су астында күп йөзгәнгә, үпкәсенә зыян килгән, нәтиҗәдә тукымаларны кислород белән тәэмин итү начарайган, шунлыктан Фидель гел махсус термокостюм киеп йөрергә мәҗбүр булган. Американың Үзәк разведка идарәсе әллә ничә тапкыр командантенең башы өчен 100 мең доллар бүләк вәгъдә иткән. Эрудицияле хаким теләсә кем белән теләсә нинди темага өчәр сәгать буе рәхәтләнеп акыл сата алган.

(“Интересно.сс”).

Ютәл сәбәбе ...сөяк

Кытайның Гуандун провинциясендә 22 яшьлек студент кызның үпкәсендә тавык яки үрдәк сөяге табылган, ул аны моннан 14 ел йоткан булып чыккан. Бала чагында кыз бик каты ютәл өянәге кичергән, аннары ул хроник ютәлгә әйләнгән. Томография ютәл сәбәбен ачыклый алмаган. Антибиотиклар булышмаган. Ютәл һәм тын кысудан тыш, кыз гипергидроз китереп чыгарган бик каты тирләүдән дә интеккән, операция ясатыр өчен, кабат тикшерену үтәргә туры килгән. Бу юлы компьютер томографиясе аның уң үпкәсендәге сөякне ачык күрсәткән. 30 минут эчендә аны алып та ташлаганнар, кыз ютәлләүдән дә туктаган. Ә менә шул ук Кытайда 76 яшьлек фермер 26 ел буе башына пычак кадалган килеш йөргән. Ун сантиметрлы пычакны аны талаганда кадаганнар. Бик әһәмиятле әгъзаларга якын урнашканга, аны югары квалификацияле хирург кына алырлык булган, ул шәһәрдә андыйлар табылмаган. Нәтиҗәдә ир-ат 26 ел буе авыртуны баса торган дарулар эчеп яшәгән. Бермәлне әлеге катлаулы медицина очрагына ике яшь хирург игътибар иткән, бу вакытта инде ирнең уң күзе күрмәгән, сул аягы һәм кулы параличланган. Медиклар фермерны Шаньдун провинциясендәге клиникага салган һәм ике сәгатьлек операция вакытында аның башындагы пычакны алганнар. Аның күзе күрә, аяк-куллары хәрәкәтләнә башлаган, баш авыртуы да басылган. Хэнань провинциясендә исә сигез яшьлек малай алты ел буе муенында энә йөрткән, җиде сәгатькә сузылган операция вакытында аны да алып ташлаганнар.

(“The Daily Star”).

Йә үлә, йә кала

Әле бүген дә күп ата-ана, төрле өзлегүләрдән куркып, баласына вакцина кадатудан баш тарта. Унсигезенче гасырда исә бу шарык медицинасында гына билгеле була, аннан соң үлеп китүчеләр дә шактыйга җитә. Эдвард Дженнер – прививканы көнбатышта иң беренче сынаучы буларак тарихка кергән инглиз табибе. Әмма аның бу кешелексез тәҗрибәсен безнең көннәрдә беркем дә кабатларга җөрьәт итмәс иде. Табиб 8 яшьлек Джеймс исемле малайны башта сыер чәчәге (оспа) вирусы белән йогышландыра, нәтиҗәнең уңай булуын күргәч, малайга чын, үлемгә китерә торган чәчәк вирусы кертә. Әгәр бала үлсә, фаҗига Дженнерның карьерасына нокта куяр иде. Әмма, бәхеткә, малай исән кала, табибнең фаразлары дөрес булып чыга, Җир шарының төрле почмакларында прививка ясала – чәчәк салына башлый. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, әлеге куркыныч авыру егерменче гасырда җиңелә, 1978 елдан исә тулысынча юкка чыккан санала.

(“Медновости.ру”).

Пыяласыман, тик уалучан түгел

Суның ничә агрегат халәте бар әле? Әгәр өч кенә – сыеклык, газ һәм боз, дип уйлыйсыз икән, димәк, ялгышасыз. Чынлыкта, сыек суның кимендә 5 төрле фазасы, ә бозның хәзергә галимнәр ачкан 14 төрле фазасы бар. Ничек кенә тырышсаң да, хәтта идеаль чистартылган су да минус 38 градуста шундук бозга әйләнә. Тагын да суытканда, сәер хәлләр күзәтелә башлый. Температура минус 120 градуска төшкәч, су патока (бәрәңге балы) кебек ябышкак һәм куега әйләнә. Ә инде минус 135 градуста су пыяласыман халәткә керә – катылана, әмма кристалл структуралы булмый.

(“Мир науки”).

Тимер ашаучы

Франциядә эстрада артисты Мишель Лотитоны (1950-2007) “Бөтен нәрсәне ашаучы мсье” дип йөрткәннәр. Беренче пыяла стаканын ул 9 яшендә чакта татып караган. 1959 елдан алып 1997 елга кадәр Мишель көн саен 900 грамм чамасы – барлыгы 9 тоннага якын металл яки пыяла предметны кабып йоткан, шул исәптән 1 “Сессна” самолеты (моңа 2 ел вакыт киткән), 7 телевизор, 18 велосипед, 15 арба, 2 суыткыч, 1 әр табут, компьютер, тырма, чаң, казан һәм Эйфель манарасының бер өлеше белән “сыйланган”. Әлеге гаҗәеп феномен медицинада “пикацизм” буларак мәгълүм һәм ашарга ярамый торган матдәләрне ашау теләгән аңлата. Әлеге чир һәм ашказаны тышчасының башкаларныкыннан ике тапкырга калынрак булуы Лотитога тимер ашау мөмкинлеген биргән дә инде, ул металлны вак кисәкләргә турап, үсемлек мае сипкән дә, су белән йотып җибәргән. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, мсье Мишель үз үлеме белән – йөрәк өянәгеннән үлгән.

(“Dzen.ru”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

10 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.00 «Җырлыйк әле!» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
13.00 «Ком сәгате». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Гаилә учагы». 16+
0.00 «Соотечественники». 16+
0.25 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 16.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Сәгыйть Хәбибуллин турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башватчыч». 12+
9.50 Спектакль «Безнең подъезд төбе». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Янар чәчәк». Мирсәет Яруллин турында телеочерк. 16+
14.00 «Муса батыр очкан чакта...» Муса Гәрәев турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30, 0.40 «Калеб». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «МУЖСКАЯ ЖЕНСКАЯ ИГРА». 12+
11.00 «Культурное наследие России». 12+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Загадки цивилизации. Русская версия». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ДОКТОР ТЫРСА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+
0.00 Подкаст.лаб «Обязательно к прочтению». 16+
0.40 Подкаст.лаб «Произвольная программа». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СЫН». 16+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

КУЛЬТУРА

6.30 "Пешком...".
7.00 "Театральная летопись".
7.55 Роман в камне. "Мальта".
8.20 "Жизнь и судьба".
8.45 "КОРТИК". 1-я серия.
10.00 Новости культуры.
10.15 "Наблюдатель".
11.15 "Забытое ремесло".
11.35 Линия жизни.
12.30 Новости культуры.
12.45 "Отцы и дети".
13.15 Ступени Цивилизации.
14.00 "Уроки рисования с Сергеем Андриякой".
14.30 Острова. Элем Климов.
15.05 "ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ, ИЛИ ПОСТОРОННИМ ВХОД ВОСПРЕЩЕН".
16.20 Репортажи из будущего.
17.00 Новости культуры.
17.15 Русский симфонизм.
18.25 "Забытое ремесло".
18.40 Ступени Цивилизации.
19.30 Новости культуры.
19.45 Невский ковчег.
20.15 Абсолютный слух.
20.55 "Спокойной ночи, малыши!".
21.15 "Я в дверях вечности стою".

«НТВ»

5.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
7.00 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
0.25 «Основано на реальных событиях». 16+

Сишәмбе

11 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тәймә».
16.00, 0.50 «Соотечественники». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Гаилә учагы». 16+
21.00 «Ватандашлар». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.45 «Йөрәктән-йөрәккә». Әнвәр Бакиров турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30 «Заман көзгесе». 6+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДОКТОР ТЫРСА». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Загадки цивилизации. Русская версия». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+
0.00 Подкаст.лаб «Легкие деньги». 16+
0.40 Подкаст.лаб «Все хотят летать». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СЫН». 16+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

КУЛЬТУРА

6.30 "Пешком...".
7.00 "Театральная летопись".
7.30 "Конец эпохи негатива".
8.20 "Жизнь и судьба".
8.40 Цвет времени.
8.45 "КОРТИК".
10.00 Новости культуры.
10.15 "Наблюдатель".
11.15 "СПРУТ".
12.30 Новости культуры.
12.45 Пряничный домик.
13.15 Ступени Цивилизации.
14.00 "Уроки рисования с Сергеем Андриякой".
14.30 "БАЯЗЕТ".
16.05 "Забытое ремесло".
16.20 Репортажи из будущего.
17.00 Новости культуры.
17.15 Русский симфонизм.
18.10 "Книги, заглянувшие в будущее".
18.40 Ступени Цивилизации.
19.30 Новости культуры.
19.45 Невский ковчег.
20.15 Абсолютный слух.
20.55 "Спокойной ночи, малыши!".
21.15 "Я в дверях вечности стою".

«НТВ»

5.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
7.00 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Чәршәмбе

12 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем…». 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Гаилә учагы». 16+
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА.

6.00, 13.45 «Янар чәчәк». Мирсәет Яруллин турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 16+
8.00 «Бәйрәмнең дә бәйрәме». 16+
8.40, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
9.40 «Сәхнә күрке - сүз». Рәшит Сабиров турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

1.30 «Культурное наследие России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДОКТОР ТЫРСА». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Загадки цивилизации. Русская версия». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+
0.00 Подкаст.лаб «Психика». 16+
0.40 Подкаст.лаб «Письма». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СЫН». 16+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

КУЛЬТУРА

6.30 "Пешком...".
7.00 "Театральная летопись".
7.30 "Великие фотографы великой страны".
8.10 Цвет времени. Рене Магритт.
8.20 "Жизнь и судьба".
8.45 "КОРТИК".
10.00 Новости культуры.
10.15 "Наблюдатель".
11.15 "СПРУТ".
12.30 Новости культуры.
12.45 Пряничный домик.
13.15 Ступени Цивилизации.
14.00 "Уроки рисования с Сергеем Андриякой".
14.30 "БАЯЗЕТ".
16.05 "Забытое ремесло".
16.20 Репортажи из будущего.
17.00 Новости культуры.
17.15 Русский симфонизм.
18.10 "Книги, заглянувшие в будущее".
18.40 Ступени Цивилизации.
19.30 Новости культуры.
19.45 Невский ковчег.
20.15 Абсолютный слух.
20.55 "Спокойной ночи, малыши!".
21.15 "Я в дверях вечности стою".
21.45 "БАЯЗЕТ".

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
7.00 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Пәнҗешәмбе

13 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
10.00, 0.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00, 21.10 «Соотечественники». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+
0.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.45 «Йөрәктән-йөрәккә». Рафаэль Сәхәбиев турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
21.25 «Ай нурында тулган моң». Римма Ибраһимова турында телеочерк. 16+
0.15 «Юлчы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДОКТОР ТЫРСА». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Загадки цивилизации. Русская версия». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.

9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.30 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.20 «СЫН». 16+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

КУЛЬТУРА

6.30 "Пешком...".
7.00 "Театральная летопись".
7.30 "Великие фотографы великой страны".
8.10 Цвет времени.
8.20 "Жизнь и судьба".
8.40 "Забытое ремесло".
8.50 "БРОНЗОВАЯ ПТИЦА".
10.00 Новости культуры.
10.15 "Наблюдатель".
11.15 "СПРУТ-2".
12.15 "Первые в мире".
12.30 Новости культуры.
12.45 Пряничный домик.
13.15 Ступени Цивилизации.
14.00 "Уроки рисования с Сергеем Андриякой".
14.30 "БАЯЗЕТ".
16.05 "Забытое ремесло".
16.20 Репортажи из будущего.
17.00 Новости культуры.
17.15 Русский симфонизм.
18.10 "Книги, заглянувшие в будущее".
18.40 Ступени Цивилизации.
19.30 Новости культуры.
19.45 Невский ковчег.
20.15 Абсолютный слух.
20.55 "Спокойной ночи, малыши!".
21.15 "Я в дверях вечности стою".
21.45 "БАЯЗЕТ".
23.15 "Сергей Прокудин-Горский. Россия в цвете".

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00, 0.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
0.25 «Основано на реальных событиях». 16+

Җомга

14 июль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Гаилә учагы». 16+
21.00 «Юлчы». 16+
22.00 «ЛЮБОВЬ ПО-ЯПОНСКИ». 12+
23.35 «СТРАШНО КРАСИВ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Рамил Курамшин турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 16+
8.00, 10.30 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Үз җиремдә үз җырым». Гәрәй Рәхим турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДОКТОР ТЫРСА». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «В РОССИЮ ЗА ЛЮБОВЬЮ». 16+
14.30 «Культурное наследие России». 12+
15.00 «Энциклопедия загадок». 12+
15.30 «Четвертое измерение». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.45 «ПОСЛЕДНЕЕ ИСПЫТАНИЕ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.35 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Творческий вечер Алексея Рыбникова. «Через тернии к звездам». 12+
23.30 «Джим Моррисон - Последние дни в Париже». 18+
0.35 Подкаст.лаб «Не лыком шиты». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.40, 21.35 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
15.05 «Веймарская республика». 16+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.50 Торжественная церемония открытия фестиваля «Славянский базар в Витебске».
23.55 «ТАНЕЦ ДЛЯ ДВОИХ». 12+

КУЛЬТУРА

6.30 "Пешком...". Углич дивный.
7.00 "Театральная летопись".
7.30 "Сергей Прокудин-Горский. Россия в цвете".
8.20 "Жизнь и судьба".
8.40 Цвет времени.
8.50 "БРОНЗОВАЯ ПТИЦА".
10.00 Новости культуры.
10.15 "Наблюдатель".
11.15 "СПРУТ-2".
12.30 Новости культуры.
12.45 Пряничный домик.
13.15 Ступени Цивилизации.
14.00 "Уроки рисования с Сергеем Андриякой".
14.30 "БАЯЗЕТ".
16.05 "Забытое ремесло".
16.20 Репортажи из будущего.
17.00 Новости культуры.
17.15 Русский симфонизм.
18.00 "Билет в Большой".
18.40 Ступени Цивилизации.
19.30 Новости культуры.
19.45 "Смехоностальгия".
20.15 Искатели.
21.00 Линия жизни.
21.55 "МЕЛОДИЯ НА ДВА ГОЛОСА".

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Шимбә

15 июль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Искәндәр Биктаһировның юбилей концерты». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Әйдә, шаяРТ!» 16+
16.00 «Уроки истории». 6+
17.00 «Татар халык җырлары».
17.30 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Ватандашлар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «ОДНАЖДЫ В ГЕРМАНИИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00 «Ай нурында тулган моң». Римма Ибраһимова турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 Фердинанд Сәлаховның юбилей кичәсе. 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Челтер чишмә буенда». Асаф Вәлиевнең юбилей концерты. 16+
22.20 «Элэктегезме?..». «Мунча ташы» спектакле. 16+

«ЭФИР»

5.00 «Культурное наследие России». 12+
5.25 «Курская битва. Время побеждать». 16+
5.50 «Легенды кино». 16+
6.30 «Люди РФ». 12+
7.00 «Планета Ай».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты.». 6+
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЖИЗНЬ ОДНА». 12+
14.45 «Эрмитаж. Сокровища нации». 12+
15.45 «МАЧЕХА». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СКРЮЧЕННЫЙ ДОМИШКО». 16+
23.00 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Прерванный полет Гарри Пауэрса». 16+
14.15 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». 16+
17.00 «Султанат Оман. Аравийское чудо».
18.20 «Поём на кухне всей страной». 12+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.05 Концерт «Леониду Агутину - 55». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.30, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.30 «ВОДОВОРОТ». 12+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ИЗ ЧУВСТВА ДОЛГА». 12+

КУЛЬТУРА

6.30 "Библейский сюжет".
7.05 Мультфильмы.
8.15 "НЕ ЖДАЛИ, НЕ ГАДАЛИ".
9.30 "Классная тема!".
10.00 Новости культуры.
10.15 Тайны старого чердака.
10.40 "ПОД КУПОЛОМ ЦИРКА".
12.55 Неизвестные маршруты России.
13.35 "Торжество дикой природы. Национальный парк Биг Бенд".
14.30 Большой балет.
17.00 "Служебный роман" с кинокамерой".
17.40 Иллюзион.
19.30 Новости культуры.
19.45 "Эстрада, которую нельзя забыть".
20.30 "ФАВОРИТ".
22.40 "История в шифрах".
23.20 "СОН В НАЧАЛЕ ТУМАНА".

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Поедем, поедим!» 12+
9.25 «Едим дома».
10.25 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.25 «Секрет на миллион». 16+
21.25 «Просто праздник!» 12+
23.00 «Форум Агутина-2023».

Якшәмбе

16 июль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Фәрештә түгел». 16+
8.30 Мультфильмы.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Искәндәр Биктаһировның юбилей концерты». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.00 «Ватандашлар». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
14.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00 «Эльмир Низамов һәм дуслар». 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
22.00 «ОБРАЗЦОВЫЕ СЕМЬИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Син һәм мин». Салават Миңнехановның һәм Гүзәлем концерты. 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Рамил Курамшин турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп әйрәник». 6+
12.05, 0.50 «Яшьләр тукталышы». 6+
12.35 «Халкым минем». 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Шәрәфле Шәрәфи». Равил Шәрәфиевнең юбилей кичәсе. 12+
16.25 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.20 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.15 «Кәмит Җәвит». 16+
19.10 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе. 16+
22.40 Спектакль «Кадер кичәсе». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Культурное наследие России». 12+
5.25 «Курская битва. Время побеждать». 16+
5.50 «Легенды телевидения». 12+
6.30 «Ученые люди». 12+
7.00 «Планета Ай».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты.». 6+
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «МАЧЕХА». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «НЕВЕРОЯТНОЕ ПЕРЕМЕЩЕНИЕ». 12+
14.35 «Блин. Ком». 16+
15.30 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ХОРОШИЙ ДОКТОР». 16+
22.40 «ЗЕРКАЛА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Произвольная программа». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.10 «Михаил Пуговкин. Житие мое».
15.10 «СВАДЬБА В МАЛИНОВКЕ».
17.00 «Кто, кроме нас». 16+
19.00 «Три аккорда». 12+
21.00 «Время».
22.35 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
23.35 Подкаст.лаб «Гори огнем». 16+

«РОССИЯ»

6.10 «ОТПУСК ЛЕТОМ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.30 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.30 «ВОДОВОРОТ». 12+
17.50 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

КУЛЬТУРА

6.30 Мультфильмы.
7.30 "ФАВОРИТ".
9.35 Диалоги о животных.
10.15 Тайны старого чердака. "Натюрморт".
10.45 "ШЕСТНАДЦАТАЯ ВЕСНА".
12.10 Человеческий фактор.
12.40 Неизвестные маршруты России.
13.20 Страна птиц.
14.00 "Игра в бисер" с Игорем Волгиным.
14.40 "Кошкин дом".
15.50 Звезды театра.
17.25 "Пешком...".
17.55 Линия жизни.
18.45 "Андрей Дементьев. Всё начинается с любви".
19.30 Новости культуры.
19.45 Новости культуры с Владиславом Флярковским.
20.25 Острова.
21.05 "ПОД КУПОЛОМ ЦИРКА".

«НТВ»

5.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.50 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.40 «ПРАКТИКАНТ-3». 16+
23.35 «Маска». 12+

Тик яткан кеше генә ялгышмый, дигән әйтем, гадәттә, уңышсыз чыккан эшләрне аклау йөзеннән әйтелә. Эш кешеләренең хезмәт урынында аяныч хәлләргә китергән ялгышларын аклап булмый. Күп тапкырлар исеме үзгәртелеп, соңгы вакытта «Буа шикәре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять дип аталучы мәгълүм заводта бер эшченең кнопкаларны буташтырып басуы аркасында икенчесе кулсыз кала яза.

«Буа шикәре»ндә шомлы хәлләр



Шикәр җитештерү – басулардан чөгендер кайта башлаудан алып, чимал беткәнчегә кадәр бара торган сезонлы эш. Бу чорда даими коллективка вакытлыча алынган эшчеләр дә өстәлә һәм күпчелеге уникешәр сәгатьле көндезге һәм төнге сменаларда эшли, димәк, конвейер туктаусыз эшләп тора. Берәр агрегат ватылып тоткарлык килеп чыкмаса, билгеле.

Узган елның 3 декабрендә көндез чөгендер түбән (жом) киптерү һәм бөртекләндерү цехында шундый хәл була. Тәҗрибәле слесарь-ремонтчы Мансур Галимов әйтүенчә, конденсат, ягъни су җыелу сәбәпле алдан пар өрдерү, аның артыннан чимал ваклау җайланмалары сафтан чыга, нәтиҗәдә, өзлексез килеп торган чимал ташкыны бункер, элеватор дигән корылмаларга ага, машиналар аны ташып өлгерә алмый, көч килү аркасында йөк күтәрү транспортерының лентасы өзелә, әлеге конвейер белән цех кына түгел, завод бөтенләй туктап кала.

Төзәтү эшләрен башлыйлар. М.Галимов, Р.Мөхәммәтшин, Э.Волков һәм тагын берничә слесарьдан торган бригада ике сәгатькә артыграк та эшли, ләкин транспортерны рәтләп өлгерә алмый. Төнге смена башка эшләрдә булганга, икенче көнне алар лентаны тарттырып ялгыйлар, башка җитешсезлекләрне бетерәләр. Раил Мөхәммәтшин лента астына үрелеп бору - беркетү эшләре белән шөгыльләнгән мәлдә, кинәт транспортер хәрәкәткә килә, аның кулын эләктереп китә. Шөкер, йөк күтәргеч бик тиз туктый, юкса, коточкыч нәтиҗәләргә китергән булыр иде. Шулай да Раилнең уң кулын лента белән ролик арасына кысып өлгерә ул. Р.Мөхәммәтшин кулын үзе тартып чыгара, мастер М.Мөхитов аны медпунктка алып китә. Медпунктка каушаган кыяфәтле Мансур Галимов йөгереп килеп, үзенең гаепле икәнен әйтеп гафу үтенә. Раилне район сырхауханәсенә илткәч, кулын рентгенда карыйлар, гипс салгач республика клиник хастаханәсенә алып китәләр, андагы травматология бүлегендә дүрт көн ятып чыга ул. Әлбәттә, ир кешенең кулы рәтләнде, тәзәлде дигәнне белдерми бу, чөнки кулбаш сөяге сынган һәм тайпылган булып чыга. Бик озак дәваланырга кирәк булганга, эксперт 40 яшьлек ирнең саулыгына авыр дәрәҗәдә зыян китерелгән дип таба. Бу инде ике балалы гаилә башлыгы бик озакка эшкә яраксыз калуны белдерә.

Ошбу бәла ашыгу-кабалану нәтиҗәсендә килеп чыга. 2022-2023 еллар сезонына оператор, икенче төрле әйткәндә, бригадир итеп билгеләнгән Мансур төзәтү эшләре төгәлләнгән агрегатларны эшләтеп җибәрергә тиеш була, шул максаттан, бишенче катка күтәрелә дә, ике кнопкага дөрес баса, ә өченчесендә ялгышып, җиллләтү җайланмасы урынына, ир-егетләр эшләп маташкан транспортерны хутка сала. Ярый әле буталуын аңлап, тиз арада сүндерә ул аны.

Эш урынындагы бәхетсезлек очрагы хокук саклау органнары игътибарыннан читтә калмый. Тикшерү комитетының Буа районара бүлеге җитәкчесе урынбасары Дамир Әскәров җинаять эшен алдан хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозу турындагы 143 нче маддә буенча кузгата. Бу очракта, гадәттә, җитәкче кешеләр җавапка тартыла һәм мәсьәләне хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән норматив документлар хәл итә. Тикшерә торгач, М.Галимовның да бик күп кагыйдәләрне санга сукмавын раслаучы рәсми инструкцияләр булуы ачыклана. Әйтик, слесарь ремонтланган агрегатларны эшләтеп җибәрер алдыннан бүтән кешеләрне читкә озатырга, сигнал бирергә һәм башка таләпләрне үтәргә тиеш булган.

Шул рәвешле, М.Галимовка, кыскартып әйткәндә, хезмәт урынында саксызлык күрсәтеп кеше сәламәтлегенә авыр зыян китерүдә гаепләү белдерелеп, җинаять эше Буа шәһәр суды каравына бирелә. Әлбәттә, явыз рәвештә эшләнмәгән җинаять өчен дүрт балалы эш кешесенә кырыс җәза бирелмәс иде. Суд исә 1980 елгы И.Галимовны җәзасыз калдырырга, ягъни якларның килешүе сәбәпле җинаять эзәрлекләвен туктатырга дигән карар чыгара. Чөнки Р. Мөхәммәтшин хезмәттәшенә дәгъвам юк дип белдерә.

***

Оешма зур, эшләүчеләр күп булгач, ялгышу, такыр юлда абыну очраклары килеп чыгу мөмкинлеге дә арта, күрәсең. Ай ярымнан «Буа шикәре»ндә тагын бер бәхетсезлек очрагы була. Һәр яктан уңай бәяләнүче 48 яшьлек ир бу юлы бик авыр тән җәрәхәтләре ала.

Шул райондагы Түбән Наратбаш авылында яшәүче Фирдүс Һадиев ошбу заводта 2003 елдан бирле эшли дияргә була, чөнки ике тапкыр китсә дә, яңадан килеп урнашкан, 2018 елдан тимер юл транспорты цехында әзер продукцияне, төгәлрәге, терлек азыгы буларак файдаланылучы калдыкларны вагоннарга гына түгел, машиналарга да төяүче булып хезмәт куя. Быел 10 гыйнварда чираттагы ялга чыга, ләкин 22 се якшәмбе көнне эшкә чыга, чөнки ял көннәрендә хезмәт хакы икеләтә түләнә. Иртәнге сәгать 8 тулганда цех башлыгы Рамил Ханбиков аңа һәм 53 яшендәге Ринат Шиһаповка биш вагонга киптерелгән бөртек рәвешендәге түп (жом) төяргә куша. Хоппер дип йөртелүче әлеге биек вагоннар ашлык кебек бөртекле йөкләр ташуда кулланыла. Ир-атлар өчен гадәти эш була бу. М.Шиһапов махсус тимер белән вагонны продукция килә торган лентаны транспортер астына куя, дүрт метр ярым биеклектәге түбәдә Ф.Һадиев эшли, ягъни бөртекле продукция читкә коелмасын өчен люкка улак куя, транспортерны эшләтеп җибәрә, тула башлагач туктата, астагы хезмәттәше вагонны күчергәч, жом икенче люктан агызыла, өченче, дүртенче люклар да тулгач, икенче вагон куела. Шул рәвешле көндезге сәгать өчтә ирләр соңгысын тутырырга керешә.

Ун-унбиш минутка китеп торган Ринат, әйләнеп килгәч тә, югарыдагы Фирдүс күренмәгәч, баскычтан менеп транспортерны үзе сүндерә, аның астагы складта торуын күреп, шунда ашыга. Ф.Һадиев аңа биле авыртудан сукрана, кием алыштыру бүлмәсендәге урыныкка кереп ята. Бу хакта цех җитәкчесе Р.Ханбиковка, йөк төяү эшләре буенча мастер И.Йосыповка хәбәр итә. Ял көнендә алар икесе дә өйләрендә була.

Эксперт Ф.Һадиевнең берничә җирдән күкрәге, унбиш урыннан кабыргасы, иң хәтәре, бил турысында умыртка баганасы сыну, кайбер сөякләрнең кителүе, читкә тайпылуы, үпкәне зарарлап эчкә һава тулу, кан сарку, башында да бәрелгән җәрәхәтләр булу, ягъни гомеренә куркыныч янавын белдерә һәм, әлбәттә, аның сәламәтлегенә авыр зыян китерелгән дип таба. Һәрвакыттагыча бәла аяк астында булып чыга. Актык вагонга бөртекле йөк ага башлагач та, Ф.Һадиев бер адым артка чигә һәм ачылган люк капкачына абынып егыла, башы белән люк кырыена бәрелә һәм аркасы белән түбәдән вагон идәненә килеп төшә. Әйтүенә караганда, бер мәл өнсез ята, аңына килеп баскычтан югарыга үрмәли башлагач, башы әйләнеп, тагын түбәнгә егыла. Димәк, эксперт санаган җәрәхәтләр өч мәртәбә егылып, бәрелү нәтиҗәсе булып тора. Гөрләп торган заводта кычкыруын ишетеп ярдәмгә килүче булмагач, хезмәттәше Р.Шиһапов та читтә йөргән чак туры килгәч, көч-хәл белән вагон түбәсенә менеп, аска төшәрлек көч таба ул үзендә.

Бәхетсезлек очрагын полиция, тикшерү комитеты гына түгел, җәмгыять директоры билгеләнгән комиссия дә тикшерә. Әлбәттә, моның бер ялгыш адым нәтиҗәсе генә түгел икәне алдан ук аңлашыла. Хезмәт куркынычсызлыгы өлкәсендәге кагыйдә бозу очракларын күпләп санап була. Иң әүвәл бәхетсезлек очрагының югарыда эшләү кагыйдәләрен үтәмәү нәтиҗәсе булу шикләндерми. Мондый биеклектә эшләүче махсус хәзерлек узарга, аның таныклыгы булырга тиеш. Ә монда Һадиев кына түгел, җинаять эшендә шаһит итеп теркәлгән җитәкчеләр дә андый таныклыгым юк дип тора. Күрәсең, заводта ошбу мәсьәләгә бөтенләй игътибар бирелми. Хезмәтне саклау кагыйдәләре буенча түбәдә эшләүче иминият каешы белән элэктерелгән булырга тиеш. Күрсәтмә биргән җитәкчеләр ошбу цехта ике каеш бар, дип гаепне аннан файдаланмаган зарар күрүчегә аударырга тырыша. Ф.Һадиев исә цехта андый әйбер бар икәнен белмәдем, күргәнем дә булмады дип сөйли. Шунысын да өстик, медицина тикшерүе Фирдүс канында этанол булуын, димәк, аның эш урынында салмыш килеш йөрүен күрсәтә. Бусы да җаваплы һәм җитәкче иптәшләр тарафыннан контрольнең түбән дәрәҗәдә булуын исбатлый.

Юстиция полковнигы Дамир Әскәров җинаять эшен, кыскача әйткәндә, җаваплы кеше саксызлыгы нәтиҗәсендә кеше сәламәтлегенә авыр зыян китерү очрагы буенча кузгата. Кул астында утыздан артык йөк төяүче эшләгән һәм бу өлкәдә барысы өчен дә җаваплы мастер И.Йосыпов ул көнне ялда була. Күрәсең, шул сәбәпле гаепләү йөк төяүчеләргә эш биреп киткән цех җитәкчесе Р.Ханбиковка белдерелә. Гаебен таный эш кешесе. Шул ук вакытта гаепнең үзендә генә булмавын күрсәткән нигезле дәлилләр дә китерә. Килешмичә дә булмый, әгәр бөтен заводта биектә эшләүчеләрне куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтмиләр, аларга таныклыклар, шәхси саклану әйберләре, әйтик, хәвефсезлек каешлары бирелми һәм кулланылмый икән, моны цех җитәкчесе генә оештыра алмый бит инде. Гомумән, саклык, хәвеф-хәтәрне кисәтү чаралары турында эш узгач кына искә төшерәбез.

Күрәсең, гаепнең үзендә дә булуын зарар күрүче Ф.Һадиев тә аңлыйдыр. Юкса, суд утырышында хөкем итәлүче хезмәттәшен яклап сөйләмәс, аңа дәгъвам юк дип белдермәс иде. Аннан соң цех башлыгына кырыс җәза бирү аның нык какшаган саулыгын яхшыртмый бит. Әлбәттә, күп дәваланырга, биленә корсет киеп йөрергә дә туры килә аңа. Судья аның соравы буенча Р.Ханбиковка карата җинаять эзәрлекләвен туктатырга карар кыла.

Кызганыч, хезмәт урынында хәтәррәк бәхетсезлек очраклары да еш була. 16 майда шул райондагы Килдураз авылы янындагы басуда «Коммуна» җәмгыяте механизаторы 1962 елгы Ф.Абейдуллов авыр ашлама төргәге астында калып дөнья куйды. Фаҗигале вакыйганы тикшерү, гаепләне ачыклау буенча тикшерү эшләре төгәлләнмәгән әле.

Наил ВАХИТОВ.

Сәнгать аша сәяхәт

«Хәзинә» милли картина галереясында уңыш белән баручы «Безнең адрес – Советлар Союзы!» ретроспектив күргәзмәсе совет чоры сәнгатен пропагандалауга юнәлдерелгән. Биредә узган гасырның икенче яртысында иҗат ителгән бихисап картиналар һәм сыннар урнаштырылган. Күргәзмә экспозициясе ил рәссамнары эшләре һәм шул ук вакытта 2010 елда Россиядә Елена һәм Геннадий Тимченколар тарафыннан оештырылган «Тимченко фонды» биреп торган 100 әсәр хисабына ачылган.

Күргәзмә совет кешесе тормышының бербәр ягын ачыклаган унбер тематик залдан гыйбәрәт. Аларның һәрберсендә Советлар Союзында гомер кичергәннәрнең тормышы, көнкүреше чагыла, диварлар исә хәзер дә ошатып каралучы совет кинофильмнарыннан алынган цитаталар белән бизәлгән.

1941-1980 елларда кылкаләм осталары үз иҗатларында Бөек Ватан сугышы темасын да еш күтәргәннәр, әлеге темага багышланган залда сугыш күргән, анда катнашкан рәссамнарның картиналары, график битләре дә урын алган, әйтик, Х.Якупов, Б.Әлменов, Л.Фәттахов һ.б. Тамашачылар күренекле рәссамыбыз Х.Якуповның 1954 елгы җитди хезмәте – «Муса Җәлил. Хөкем алдыннан» картинасы янәшәсендә дә озаклап басып тора. Күргәзмәгә 1932-2004 елларда яшәгән сынчыбыз Нәүфәл Адыловның агачтан уелган, гипстан эшләнгән берничә сыны куелып, бу шәхесебез иҗатына да тиешле акцент ясалган. Аның агач фактурасын тулысынча ачкан «Җинүче» (1985), «Яшь артист» (1965) хезмәтләре аеруча да истә кала. Бирегә башка сынчыларыбыз: В.Маликов, А.Әбдрәшитов тарафыннан ясалган скульптура портретлары да куелган.

Рәссамнар 1960-1970 елларда хезмәт кешеләрен аеруча данлаган. Советлар Союзында спорт белән җитди шөгыльләнүчеләр җитәрлек санда булганга күрә, бу тема да күргәзмәдә яхшы яктыртылган. Моннан кала шәһәр һәм авыл пейзажларына, табигатебезгә дә дан җырланган әсәрләр бар. Рәссам Әмир Мәҗитовның гади генә сюжетка корылып ясалса да, тамашачыларның күңелләренә хуш килүче «Салават күпере» картинасы шушы чордагы балаларның да үз киләчәкләренә салават күпере балкышына карап кебек карауларын, тик якты өметләргә генә таянып үсүләрен искәртә. Күргәзмәдә совет чоры горурлыгы – совет балеты темасы да онытылмаган, ул 1923-1986 елларда гомер иткән Ангелина Филиппованың нәфис эшләнештәге «Рус балеты мәктәбе» (Киләчәктәге балериналар) гипс сыны аша искәртелгән.

Романтика, һәр яклап камиллек, югары идеалларга ышану һәм ашкыну – мондый рухи төшенчәләрне һәм халыктагы шушы сыйфатларны барлау белән шөгыльләнгән рәссамнарның эшләреннән кала биредә нонконформизм юнәлешенә караучы сәнгать мисаллары да бар. Болар – 1950-1980 елларда рәсми совет хакимияте һәм шул ук вакытта җәмгыять күпчелеге тарафыннан кабул ителмәгән, ил мәдәнияте доктринасына туры килмәгән һәм, гомумән, башкачарак идеологияне барлауга юнәлдерелгән картиналар инде...

«Безнең адрес – Советлар Союзы!» күргәзмәсендә шул елларда гы өй җиһазлары, иске типтагы мәктәп партасы, китап-әсбаплар һәм башка төр көнкүреш әйберләре дә бихисап. Тамашачылар, аеруча да XXI гасырда туган балалар аларга ихлас кызыксыну белән күз ташлый, дәү әтиәниләренә, ата-аналарына сораулар да бирә, аларга җавап бирүче олылар өчен дә, сабыйлар өчен дә бу күргәзмә – узган гасырга сәнгать аша сәяхәт.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шаих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип өчен
В. ИМАМОВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны:
(843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек иту федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазлаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юлаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 07.07.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе иркенле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2625

16+